PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 МАРТ № 3

# Сөембикә

ISSN 0869-1398

МИН ЯЗМЫШНЫ ҖИҢДЕМ
*кояшлы балалар еламый*

АЛЬБИНА ШАҺИМОРАТОВА
*Американы яулаган бельканто*

МИНВӘЛИ ГАБДУЛЛИН СЫЙЛЫЙ:
*бәйрәмгә – торт, юк, тарт!*

Римма УСМАНОВА:

## «ИРТӘГӘ КӨН ЯКТЫРАК БУЛАЧАК!»



PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...

# ХАТЫН-КЫЗ БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ!





Шәйхразыевлар гаиләсе.

Казан

Васил Шәйхразыев – ТР Премьер-министры урынбасары, ул көне-төне хөкүмәт эшләре белән мәшгуль. Җыелган стрессны, ирләрчә, спортта чыгара – хоккей, ат, велосипед... Хатын-кызга артыннан һич җитешерлек түгел! Хәләл җефете Гөлнурның үз яраткан шөгыле – ул биергә ярата. Ике кыз үстереп башлы-күзле иткән гаиләнә бүген ни берләштерә дисәң, бәхетле мизгелләре җитәрлек икән – табын артындагы әңгәмәләрдән, җитәкләшеп урамнарны урап керүдән тыш, бу парны уртак иҗтимагый тормыш та якынайта. Чаллы чорыннан килгән матур һәм мәгънәле традицияләре дә бар: алар, башка гаиләләрне дә катнаштырып, хәйрия акцияләре уздыра. «Хатын-кыз бәхетле булырга тиеш – башка ул беркемгә, берни тиеш түгел! Ә аны бәхетле итүче – ир кеше», – ди Васил Габделгаязович. Һәр эшендә иренә терәк булган Гөлнур ханымның, һичшиксез, бәхетле мизгелләре күптер. Балалар үскәндә, дәрес әзерләшергә дә, ата-ана җыелышларына йөрергә дә вакыт тапкан әти, бүгенге җәмгыятьтә ата кешенең роле кими бару белән ризалаша алмый. Быелның март аеннан Васил Шәйхразыев Татарстанның Әтиләр иҗтимагый оешмасын җитәкли.
















Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләнә нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.


Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.




**Директор-баш мөхәррир**
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77
**Директор урынбасары**
Рәмзия Кашапова 222-09-78
**Баш мөхәррир урынбасары**
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова

**Сайт мөхәррире:**
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Дизайн-макет:**
«ASAFIN GROUP»
**Верстка:**
Лариса Маликова

**Тышлыкта:**
Римма Усманова
Фото: Ксения Богданова

**Бүлек мөхәррирләре:**
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
**Фотокорреспондент**
Ксения Богданова
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.02.2016 ел.
Заказ М-486.
Тираж 6629.

**Учредитель:**
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»




ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

**Гомер-гомергә шундый дөрес булмаган фикер яшәп килде: имеш, хатын-кызның эше – өйне карау, балалар үстерү. Ә менә күзгә күренерлек зур эшләр – сунарчылык, сугышлар, илне идарә итү – монысы инде ирләрнеке!**

Феминизм (femina дигән латин сүзеннән хатын-кыз мәгънәсендә) – җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә хатын-кызлар һәм ирләр үсешендә хатын-кызның хокукларын кысуга каршы көрәшүне максат итеп куйган иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. XVIII гасыр ахырында Бөек француз революциясе дулкынында барлыкка килгән. Кеше һәм гражданин хокуклары Декларациясе үрнәгендә хатын-кызның социаль һәм сәяси тулы тигез хокуклылыгын таләп итеп, Олимпия де Гуж хатын-кыз һәм гражданка хокуклары Декларациясен әзерли, ул 1791 елда Милли җыелышка тәкъдим ителәә.

# ЭШЧЕМЕ, КОЛХОЗЧЫМЫ?

«Гаиләнең, хосусый милекнең һәм дәүләтнең килеп чыгышы» дигән хезмәтендә хатын-кызны җәберләү-изүнең борынгы һәм рәхимсез формасы дип бәя биргән Фридрих Энгельсны феминизмга төп нигез салучы дип тә атап булыр иде. Шунысы да кызык: «Феминизм» терминын да ир кеше – Англия социалисты һәм фабриканты Роберт Оуэн уйлап тапкан бит.

«Эшче егет һәм колхозчы кыз» һәйкәле – монументаль сәнгать әсәре ул. Ирләр белән хатын-кызларның һөнәри тигезлеге символы да. 1937 елда Парижда узган Бөтендөнья күргәзмәсендә совет павильонына куелыр өчен Вера Мухина проекты буенча иҗат ителгән. Күргәзмә тәмамланганнан соң, монумент Мәскәүдә – Бөтенсоюз халык казанышлары күргәзмәсендә постаментка куела.




**СССРда (Россиядә), Германиядә, АКШта эшләүче хатын-кызлар (хуҗабикәләр түгел) динамикада**




АКШ президенты Джон Адамсның хатыны Эбигейл Смит Адамс феминизм хәрәкәтенең башында торган. 1776 елда президентка һәм конгресска нәкъ менә ул хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук бирүне, аларны сайлауларда катнаштыруны һәм милек хокукларын тәэмин итүне сорап мөрәҗәгать яза. «Без аларны кабул итүдә үзебез катнашмаган законнарга һәм мәнфәгатьләребезне кайгыртмаган хакимияткә буйсынмыйбыз» гыйбарәсе дә – аныкы.

**Эшләүче хатын-кызлар (хуҗабикәләр түгел) дөньяның төрле илләрендә, %, 2015**

Бүген исә гаиләдә һәм җәмгыятьтә ирләр һәм хатын-кызлар турында «традицион» карашны саклап калу өчен антифеминизм хәрәкәте көчәю күзәтелә. Аны бик күп атаклы хатын-кызлар хуплап чыга (мәсәлән, Ирина Хакамада). Алар фикеренчә, «чамасыз феминизм» шпаллар салучы, армиядә хезмәт итүче хатын-кызларны китереп чыгара, балалар тууны киметә. Болар Татарстан хатын-кызларына карамый, әлбәттә. Безнекеләр барысына да өлгерә – эшендә дә, гаиләсендә дә үрнәк!



# Баш мөхәррир сүзе



Әш тә өй – бар тормышым шул! Хәлдән тайганчы эшлисен дә, кайтып өй мәшәкатьләренә кереп чумасың – ир көйләп, бала карап уза да китә гомерләр... Шулай дип зарланырга яратабыз без. Әмма, уйлап карасак, хәләл ризык бирүче эшең, кайтып керер өең, анда сине көтеп торган гаиләң булуы үзе зур бәхет бит әле ул. Бүгенге ышанычсыз дөньяда бу бәхетнең кадере көннән-көн арта бара түгелме? Акча ягы кысанлангангамы, тансыклагангамы, быел гади шатлыкларның тәмен аеруча тоя башладым. Кызым белән кар бабае әвәләп керү, шугалакка барып тимераякта әйләнгәләп кайту шулкадәр бәхет бирә алганлыгын онытып та бетергәнмен икән ләбаса! Иремнең безнең белән күңел ачып йөрергә вакыты юк, әлбәттә – көннән-көн арзаная барган акчаны ничек эшләп җиткерергә белми ул... Ярый әле мин дә эшлим дип сөенеп куйган көннәрем еш була. Аннары, мин үзем хуҗабикә булып кына яшәргә риза да булмас идем – яраткан эшем, үз галәмем булмаса, тормышым тулы булмас иде. Ярый әле, теләгән һөнәремне алып, күңел тарткан өлкәдә үземне ачарга мөмкинлегем бар – хатын-кыз хокуклары өчен көрәшкә чыккан суфражисткаларга рәхмәт! Бу хокуклардан файдалану-файдаланмау – һәркемнең үз эше, үз ихтыяры, әмма теләгеңчә мөмкинлекләрең булу – нинди бәхет! Илбашы булырга теләмәс идем, анысы – зур сәясәт уены кырында нечкә күңелле хатын-кызга бик авырдыр дип уйлыйм. «Карточный домик» сериалын караганда (Хиллари Клинтонның да яраткан сериалы икән ул), бу фикерем ныгыды гына. Шулай, өйдән чыкмыйча гына да никадәр төрле тормыш белән яшәп була бүген – кино сәнгатенә дә рәхмәт!

Тарихи романнар укырга да яратам мин – һәм алардагы героиняларга да шаккатам! Бер хокуксыз хатын-кызлар, ничек тә җаен табып, үз сүзләрен әйтергә, җәмгыятькә үзгәрешләр кертергә, сәясәтне йомшартырга тырыша! Ил башында торганы да, ир күләгәсендә генә яшәгәне дә – хатын-кыз хатын-кыз булып кала шул. Безнең депутат ханымнарыбызның берләшмәсе дә «Мәрхәмәт» дип атала – аның төп эшчәнлеге дә ятимнәрне җылытуга, авыр хәлдә калганнарның хәлен яхшырту юлларын эзләүгә багышланган.

Әйе, язмыш сынауларына дучар булганнар безнең арада аз түгел. Әмма, бирешмичә, авырлыкларны җиңеп чыгучылар да күп. Шундыйларның батырлыгын күрсәтер өчен без бу санда «Мин язмышны җиңдем» дигән аерым сәхифә ачып җибәрдек. Җиңүчеләр үрнәге башкаларга көч бирер, чарасыз калганнарга юл күрсәтер дип ышанабыз. Сездән дә шундый үрнәкләр көтеп калабыз, укучыларыбыз – сезнең тирәгездә дә бардыр алар! Язмышларын үзгәртә алмасак та, кулыбыздан килгәнне эшләрбез – тиешле игътибар үзәгенә куярбыз, ичмасам! «Ел хатын кызы» бәйгесе Татарстан буенча иң-иңнәребезне барлап, сәхнә түренә чыгарган кебек, без дә республикабызның сокландыргыч туташ-ханымнарын дөньяга танытуны максат итәбез бит.

Әйе, нәфис зат сокландыра белә – чыдамлыгы, сабырлыгы, рухи көче, күңел киңлеге, булдыклылыгы белән дә! Хокукларыбыз өчен көрәштә берләшү көне булып билгеләнә башлаган 8 Март та бүген хатын-кыз алдында баш ию, аңа соклану бәйрәменә әйләнде. Шулай булсын! Котлы булсын, күңелләребезгә бар дөньяны җылытырлык яз, өйләребезгә кочак-кочак чәчәк алып килсен! Бәхетле булыйк!

*Ләйсән ЮНЫСОВА*






## БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





8

**БОЛЫТЛАР АРТЫНДА КОЯШ БАР**
Г. Сафиуллина

## ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





12

**«КЫЗЫМ, БЕЗ ҖИҢӘРГӘ ТИЕШ!»**
М. Авзалова

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24

**«УРТАДАН ЮЛ БИР ХАТЫНЛАРГА!»**
Р. Камалетдинова



20

**ЧИСТАЛЫК ҺӘМ ТӘРТИП КАПКЫНЫНДА**
Л. Әбүдәрова

## МӘДӘНИ ТОРМЫШ





28

**АЛЬБИНА. ТЕХАС. БЕЛЬКАНТО...**
М. Зальцберг

# ЭЧТӘЛЕК


**34** ФӘНИЯ ТӘҮБӘСЕ
С. Зыялы

## ЯШӘЕШ

**46** ЯШЕН КАЙТАВАЗЫ
Р. Гарифуллина



**50** КАЗАННЫҢ КАДЕРЛЕ КИЧЛӘРЕ
Ш. Әхмәтҗанов



## ШУЛАЙ УК:

**16** БЕЗ – ХАТЫН-КЫЗ!
Г. Хәсәншина

**42** БЕР ИЛАҺИ ЗАТ
К. Җамалетдинова

## ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ



**58** КҮЛӘМЛЕ ЯКИ 3D ЧИГҮ


## КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА:


РОЗА СЯБИТОВА — ИЛНЕҢ БАШ ЯУЧЫСЫ
Безнең кавем

ХАТЫН-КЫЗ МУЗАМЫ, КАРИАТИДАМЫ?!

«ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ»:
опера ничек туа

КИТЛАР ҺӘМ ПЛАНКТОН
Булган хәл

ДИЛӘ НИГЪМӘТУЛЛИНА
Мастер-класс. Анар соусы белән бәрән ите

PRESSA.RU

# Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



*Бу көнне – 1956 елның 22 мартын – алар әле икесе дә бүгенгедәй хәтерли. Кичке уенга диңгезче киеменнән бер егет килеп керә. «Гамир кайткан!» – диләр дус кызлары. Озын буйлы, чибәр... «Мин аңа карадым да, шунда ук: «Ул минеке була!» дип уйладым...»*

Әни сөйли моны! Шундый инде ул безнең! Үткен, кыю, чая... Сарманга әнине Бөгелмә техникумын тәмамлагач, бухгалтер итеп җибәрәләр. Искиткеч чибәр кызга әти дә шунда ук гашыйк була – бөтен батырлыгын җыеп шул кичне үк сүз ката. Өч айдан алар өйләнешәләр. Гөрләтеп туй итүләр булмый, әлбәттә. Юклык бит (әни бик ошаткан диңгезче формасын да әти бик озак яңа киемгә алыштыра алмый йөри әле)... Яшь гаиләгә кечкенә генә бүлмә бирәләр. Ятарга карават юк, утырып ашарга өстәл юк... Берни юк! Әти барысын да үзе ясап куя. Мин туам, сеңлем Дамира, энем... Дамир тууга әтине Горький шәһәренә, югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Биш елга! «Бу кечкенә өч бала белән нишләрсең?!» – дип әнидән сораучы булмый, әлбәттә. Партия кушкач, әти дә каршы килә алмый. Көндезләрен ул укый, ә кичләрен йөк бушата. Җәй көне төзелештә эшләп энемә велосипед алып кайтканын хәтерлим әле.

Горькийдан кайтуга әтине Куйбышев (хәзерге Спас) районына эшкә җибәрделәр. Аның белән без дә күчендек: беребез бер авыз русча сүз белми идек әле... Совхоз директоры булып эшләгән әтиебезне без күрмәдек тә: көне-төне эштә иде ул. Директорның транспорты җигүле ат иде ул чакта: җигә дә, чыгып китә... Кышын урманда адашып, таң алдыннан кайтып кергәне дә булды.

Әни яңа җирдә дә, әлбәттә, эшкә бухгалтер булып урнашты. Куйбышев урман хуҗалыгында егерме елга якын эшләде ул. Алсыз-ялсыз! Бервакыт хезмәттәшләре санаган да: «Бөтен җыелган ялларыгызны алсагыз, сез ярты ел өйдә утыра аласыз!» – дип шаккаттырганнар иде аны. Әллә нигә бер ял итсә дә, эшеннән әле бер сорау, әле икенчесе белән гел эзләп торалар иде аны. Әнинең бухгалтериясе – башында. «Шул китап, шул бит, анда шулай дип язылган», – дип кенә җавап бирә иде ул. Төшләренә дә шул саннар керә иде безнең әнинең.

Туксанынчы еллар башында әни Куйбышев урман хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен чын хәзинәгә әйләнде. Хезмәт хакларын түли алмаган чорлар бит: сөйләшер кешеләрен дә тапты ул, барысын көйләде, җайлады, әмма безнең якның урманчылары ул елларда ач та, ялангач та булмады. Каяндыр онын да кайтартты, ярмасын да, суыткычын, телевизорын да... Болар өчен хәзергә кадәр рәхмәт ишетеп яши ул. «Лиюдә Вахитовна», – дип, эшендәгеләр әле дә хәлен белеп торалар. Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау кәгазьләре юкка бирелмәгән инда аңа!

Әни безне бик кырыс тәрбияләде (ә менә бөтен җәйләрен аның янында үткәргән безнең балалар – алты оныгы киресен сөйли!). Башкача мөмкин дә булмагандыр: шундый җаваплы эш алып баруы белән беррәттән, ул бит әле әтиебезгә – озак еллар «Болгар» совхозын җитәкләгән директорга таяныч та иде. Әтиебезнең даны бөтен республикага таралуда, аның «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булуында әниебезнең дә өлеше зур.

Тиздән алар кавышканга, әйткәнемчә, алтмыш ел була. Ярты гасырдан артык! Әти белән әнинең бу бәйрәме безнең өчен дә сөенеч. Тигезлек белән, исән-имин килеш шушы көнгә килеп җитү бәхет бит ул. Тугызынчы дистәне вакласалар да, алар әле икәү генә көн итеп яталар. «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медаленә лаек булдылар: без – балалары, онык һәм туруннары өчен генә түгел, тирә-юньдә яшәгән яшьләр өчен дә һаман да үрнәк алар. Гаилә бәйрәменә җыелгач, әти белән әнигә һәркайсыбызның теләге бер булыр: «Озак яшәгез!»

*Әлфия САБИРОВА.*
*Казан.*



*Безнең әби Гыймранова Гальмаган Гамир кызы 1889 елда Оренбург губернасы Минзәлә өязенең Иске Багражавылында туган. Түбән Абдул авылыннан Дәүләтшин Әхмәтгата Дәүләтша улына тормышка чыккан.*

Бабай бик чибәр, уңган-булган кеше иде. Төп һөнәре җир эшкәртү

булса да, сәүдәгәрлек белән дә шөгыльләнгән, Мәкәрҗәдәге ярминкәләргә тула җыеп барып, аннан тоз, шикәр, чәй, ситсы, манчестерише тукымалар алып кайта торган булган. Сары сатиннан теккән бала итәкле күлмәге белән ефәк шәле әни өчен шул заманнарның кадерле истәлеге иде.

Без үскәндә бабайларның бакча коймасында гел балыкчы ятьмәсе эленеп тора, әби балык киптерергә, тозларга, кыздырырга оста иде. Артып калганын данлыклы Елховой базарында сатканнардыр дип беләм.

Әби искиткеч акыллы хатын булган: бабай сәүдә юлында, урманда йә кырда, балыкта булганда зур йортның бөтен мәшәкатьләрен кулында тоткан. Туып-үскән гаиләсендәге «Хәерче булмаска!» шигарен ул үз гаиләсендә дә саклаган һәм тормышка да ашырган. Биш вакыт намазын калдырмавы, чисталыгы, бик оста пешерүе, уңганлыгы белән данлыклы иде. Гәрчә халык телендә «усал Гальмаган» дигәләсәләр дә, рәхим-шәфкатьле, балаларга игътибарлы, ягымлы иде. Һәрвакыт нәрсәгә дә булса өйрәтте, урысча сүзләр кыстырып кызык итеп сөйләшә белә иде. Сугыш елларында гаделлеге, туры куллы булганы өчен аңа кырда эшләүчеләргә ипи пешерү эшен йөкләгәннәр. Ул әле үтә дә юка итеп җәймә, тәмле бавырсак та пешерә иде. Идән астыннан зур балчык чүлмәк белән йомырка алып чыгып юача пешергәне хәтеремдә.

Кыш көннәрендә Нуридә, Бәнат, Сәйдә, Бәркәтәдән Хайрислам бабай карчыгы Зәйтүнә, Хөснури, Минҗиһан әбиләрнең кумәкләшеп йон эрләве, оек-бияләй, шәл бәйләве истә. «Сине Нуридә әбиең «авызландырды», – дип еш әйтә иде әни. Безнең як мишәрләрендә шундый ышану бар: кем балага беренче мәртәбә бал-май каптырса, бала шул кешенең яхшы сыйфатларын үзенә ала, имеш. Нуридә әбинең күркәм холкы, кул эшләренә, аш-суга маһирлыгы тирә-юньгә билгеле, әнинең шатлыгы шуннан.

Әбинең чисталыгы гаҗәпкә калырлык иде: 90 яшьтән узгач та үз киемен Шушмага алып төшеп чайкый иде. Күзлексез энә күзләп үзенә дә, бабайга да күлмәк-ыштанны, хәтта бишмәтләрне дә үзе текте.

Менә шундый нык иманлы, көчле ихтыярлы, хәләл хезмәт белән көн күрүче Әхмәтгата белән Гальмаганның баласы булган әнием Миннагиан шул кыйммәтле сыйфатларны безгә дә тапшырырга тырышты. Әни балачактан мөгаллимә булырга хыялланган. Ләкин җидееллык мәктәпне тәмамлагач, бабай аны техникумга укырга җибәрмәгән. Чибәр кызы шәһәрдә бәлага тарыр дип курыкканмы: «Укыганың җиткән, хатын-кыз ир-аттан күп белсә, үзенә авыр», – дигән. 19 яшендә авылдагы гүзәлләрнең берсе булган Миннагианны үзе белмәгән, сөйләшеп тә карамаган Габдулла исемле егеткә кияүгә биргәннәр. Бабай ялгышмаган: кияү әнигә карата бик ихтирамлы, ярдәмчел һәм кайгыртучан булып чыккан. Ләкин сигез генә ай яшәп калган ирен 1941 елда сугышка озаткан яшь хатынга тылдагы авыр хезмәтне дә, кайната белән кайнананы да, зур йортның бихисап эшләрен дә, яңа туган кызы Гөлсинәнең үлемен дә кичерергә туры килгән. «Хәбәрсез югалды» дигән кара мөһерле язу килгәннән соң да, 1947 елның җәенә кадәр әни, вәгъдәсенә туры калып, иренең әти-әнисе йортында яшәгән.

Бабай, бердәнбер кызының бәхетсезлегенә йөрәге әрнеп, аны үз йортына алып кайткан. Шул ук елны күршедәге йортка рус хатыны белән диңгезче, 14 ел буена Тын Океан флотында хезмәт иткән сугыш ивалиды Хәлиулла Әхмәтшин кайтып төпләнә. Тик ул хатын татар авылында озак юанмый, китеп бара. Югары очның Хәйрулла балалары әнине шушы Хәлиуллага сорап бабайга башкода җибәрә. 1948 елда әни белән әти никахлаша. Һай, җиңел булмагандыр әнигә култык таяклары белән йөрүче, русчалы-татарчалы сөйләшүче, матросларча сүгенүче, сугышта тәкәллефсез булырга өйрәнгән, киеменнән башка бернәрсәсе дә булмаган Хәлиулла белән тормыш башлаулары!

Әни сабыр, тыйнак, шул ук вакытта чыдам, куркусыз һәм нык кеше иде. Шулай булмаса, ул әтине бөтен авыр эштән азат итеп, аның җәмгыять кешесе булуы белән килешеп, башлаган һәрбер эшендә иң ышанычлы таянычы һәм киңәшчесе була алыр иде микән? Без – бер-бер артлы туган дүрт кызы һәрвакыт әнинең игътибарын, кайгыртуын һәм кырыслыгын тоеп, ул теккән киемнәрне киеп үстек. Кызганыч, Халидә апа гына сабый чагында ук китеп барды.

Безнең бәхеткә, әти дә, әни дә китап яратучы кешеләр иде. Гаилә шигаре: «Надан булмаска!» Әти белән әни безнең мәктәптәге тормышны бик яхшы белүче, укудан тыш вакытта татарча да, урысча да китап укуны мөһим санаучы, ниңарсә укуыбыз белән кызыксынучылар иде. Өч кызларын да белемле итү өчен нык тырышты алар: Хәдичә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, Гөлшат медицина хезмәткәре, мин – Миңлегөлләре – инглиз теле белгече. Әни минем артык оялчан булуым белән дә үзенчә көрәште: сәхнәдән торып зур аудитория белән сөйләшергә ул өйрәтте. Тышкы кыяфәткә игътибарлылык та әнидән: «Ямьсез, пычрак кием белән кеше янына бару – тирә-юньдәгеләрне кешегә санамау була», – ди иде ул. Югары сыйныфларда, институтта укыганда үземә киемнәр, 90 нчы елларда балаларыма туннарга кадәр тегеп кидерә алуым белән аңа бурычлымын.

Әти дә, әни дә Хезмәт ветераннары. Әни «Тылда күрсәткән хезмәте өчен» медале, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең юбилей медальләре белән бүләкләнгән, ихтирамга лаеклы кеше булып, 1961–2001 елларда Әлмәт районы, Елховой авылының Хәлиулла Әхмәтшин исемендәге авыл тарихы музеенда хезмәт куйды. 2016 елның гыйнварында әниебез Әхмәтшина Миннагиан Әхмәтгата кызына 95 яшь тулган булыр иде.

*Миңлегөл НУРИЕВА,*
*хезмәт ветераны.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***

PRESSA.RU





Фото: Ксения Богданова

# БОЛЫТЛАР АРТЫНДА КОЯШ БАР



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Чынлап та, укытучы артыннан киттегезме?

Ышанмыйча, кат-кат сорыйм. Азнакайдан Буага кадәрме? Татарстанның бер читеннән икенче читенә була түгелме соң? Бөтен республикага атаклы «Ләйсән» ансамблендә җырлап үскән ул. Римма сигезенче классны тәмамлаган елны җитәкчеләре Алсу Гарифуллина Буага күченә. Ансамбльгә йөрүче кызларның барысы да аңа иярергә карар итә. Буага исә... Римма ялгыз чыгып китә: «Алсу апа бөтенебезне алып китәргә әзер иде. Тик кызларның әниләре нык торды. Ә мин үзем катырак булдым бугай...» 9-10 сыйныфларны ул Буада укый. Хәзер, еллар узгач, «Күченәсе дә булмагандыр, мөгаен», – дип искә төшерсә дә, өйдән читтә яшәү аны яшьли мөстәкыйльлеккә өйрәткән. Кире кайтып китәргә дә булгандыр да... Тик бер кабул иткән карарыннан алай җиңел генә баш тартучылардан түгел ул. Бу – «Буа мәктәбе», дисәм, юктыр, ныклык аңарда электән дә булгандыр. Ә менә «болытлар артында кояш бар»ына ихластан ышану... Монысы ул чакта яшь кызга тормыш биргән иң зур сабак-дәрестер. Шул җөмләне күңелдән дога урынына кабатлап, иртәгәсе көн бүгенгесеннән, һичшиксез, матур булачагына өметләнгән мизгелләр алда, әлбәттә, тагын була. Без аның белән шуларны барлыйбыз.

### *Беренчесе*

– Баланы мин җиңел генә күтәреп бетердем. Улым май ахырында туды. Дүрт килограммнан артык! Әни белән аны бала тудыру йортыннан алып чыккан көн, инде утыз ел узса да, бүгенгедәй хәтердә. Пыскып кына яңгыр ява иде... Бала арбасы этеп урамнарда йөри башлагач, үз-үземә: «Нигә мин үзем генә соң? – дигән сорауны беренче тапкыр бирдем. – Башкалар арбага парлап тотынган әнә».

Берничә ел очрашып йөреп, туйлар ясап өйләнешәләр алар һәм... нибары ярты ел торып калалар. Яшь гаиләнең беренче Яңа елы була ул. Ирнең, күптән түгел кавышкан, инде бала көткән хатынын ялгыз калдырып, бәйрәмне әниләре янында үткәрүен сез аңлар идегезме? Римма да аңламый. Икенче көнне иртән сәгать унда гына кире кайткан ирне ишек төбендә чемодан көтә. Шулай аерылышалар. Кискән кебек... Аннан, бала туып, өч ай узгач – рәсми рәвештә.

«Үкенмим, – ди ул. – Барыбер бергә яшәп бетә алмас идек...» Бөгелмә педагогика училищесын тәмамлап кайткан Римма, улы Эдуардка сигез ай тулуга эшкә чыга. (Югары белемне инде читтән торып алырга туры килә.) «Бала тапканчы эшкә урнашырга өлгермәсәм дә, район социаль тәэминат бүлеге аша минем кебек яшь әнигә ай саен 35 сум пособие тиеш булганын беркем әйтмәде. Акча юк... Улымны төрергә бала чүпрәгем дә булмады... Тик кеше бөтен кыенлыкны да җиңә икән. Кайчак уйлыйм: «Бу юлны яңадан узасы булса, түзәр идемме?» – дим. Белмим... Иң авыр чакта ярдәм итүче барыбер табыла ул. Берьюлы өчәр эштә эшләдем. Балалар бакчасында каравылчы булып та тордым.

### *Икенчесе*

– Эдуард авырды да авырды... «Астма», – диделәр. Айлар буе район хастаханәсендә ятып та, алга китеш булмагач, Казанга җибәрделәр. «Күренергә генә», – дигәннәр иде, ә табиблар баламны кулымнан тартып диярлек алып калды. Аңа нибары өч яшь ул чакта... Урамга чыктым да, елап басып торам. Кая барырга, нишләргә?.. Яныма бер машина туктады: «Ни булды, нигә елыйсыз?» – ди. «Бөгелмәгә очарга кирәк, аэропортның кайда икәнлеген дә белмим», – дим. Утыртты. Сөйләшеп киттек. Тәрбиягә бала алганнар, ул кызлары авыру булып чыккан. Минем хәлемне аңлады ул кеше. Кызганыч, инде исеме дә онытылган. Бер ай буе улым янына килеп йөргәндә әллә ничә каршы алып, озатып куйды ул мине. Яхшы кешеләр тирәюньдә барыбер күбрәк... Миңа ул чакта кылган шушы яхшылыгын ул инде күптән оныткандыр, ә мин менә – хәтерлим. Алып кайттым улымны, ә ул сөйләшми! Стресс... Бер айдан соң гына эндәшкәндә җавап кайтара башлады. Бала бөтенләй тын ала алмаган көннәрнең берсендә кулыма Мәскәү гомеопатлары турында язган газета килеп эләкте. Суга батучы саламга ябыша... Хат яздым, «шул көнне, шул сәгатьтә килеп җитегез» дигән хәбәр килде. Акчам, билгеле, юк, «кирәге чыгар», дип берничә пакет карабодай алдым. Күргәннәрне сөйләсәң... Бала янында булам, дип, ай буе идән юдым. Нәрсә ашап тордым икән, белмим... Иң мөһиме – улымны Мәскәүдән, фәнни-тикшеренү институтыннан аякка бастырып җибәрделәр! Бездәге тернәкләндерү төркеменә балаларын йөртүче әниләр күзендәге әрнү таныш миңа. Үз башымнан кичте...



■ Билингваль укыту – ике дәүләт телен өйрәтү буенча миллион сумлык грантка ия булган (ул акчага сенсорлы кабинет ясатканнар, логопед бүлмәсенә ике интерактив такта кайтарткаaннар, 150 меңенә уенчык сатып алганнар, балалар бакчасындагы бөтен ишекләрне – ә алар сиксән бишәү – алыштырганнар) «Йолдызчык»ның уңышлары бихисап, әлбәттә. Мактау кәгазьләре, дипломнарның саны-исәбе юк! Римма ханымның җавабы кыска: «Яратып эшлибез!»

> *Юлымда очраган һәркем мине нәрсәгәдер өйрәтте, сабак бирде.*

### *Өченчесе*

– Улымның куллары шундый зур иде... Без аның белән урамнарда һәрвакыт җитәкләшеп йөрдек. Кичен чыксак, күзебез гел тәрәзләрдә. Үзебез хыялланабыз: «Кайчан да булса, фатир алсак, бер бүлмә синең була, берсе – миңа...» Тулай торактан сигез квадрат метрлы бүлмә бирделәр! Моннан да зур сөенеч кичергәнемне башка хәтерләмим... Без аның ишеген үз ачкычыбыз белән ачып керәчәкбез! Аннан, ниһаять, эштән ике бүлмәле фатир алдым. Бәхет! Кешегә күп кирәкмәгәнен шул чакта аңладым... Улым әтиләр янында кимсенмәсен дип, артыграк та тырыштым бугай. Югыйсә бала «юк» дигәнне дә аңлап, белеп үсәргә тиеш... Эштән соң, банкет, туй-мәҗлесләрдә җырладым ул елларда. Эдик гел янымда булды... Җырлар чират җиткәнне көтеп, төнге ике дә була, өч тә. Ә иртән эшкә барасы бар. Сәхнәләргә күптән чыккан юк хәзер, күңелем генә гел җырлый...

Тормышта миңа бернәрсә дә җиңел бирелмәде. Читтән караганда күпләргә нигәдер бик җиңел яшәгәнмен кебек тоела. Зарланырга яратмагангадыр бәлки. Беркайчан да үземне җәлләүләрен теләмәдем. Җәлләү – түбәнсетә, ә аңлау – анысы икенче.

PRESSA.RU









### Дүртенчесе

Азнакай шәһәренең «Йолдызчык» («Звездочка») балалар бакчасына кайчандыр Римма үзе йөргән, әнисе шунда эшләгән, улы шушында үскән, оныгы Камилла йөргән, тиздән икенче оныгы Дамир да, әлбәттә, бирегә килер. Римма Рәсим кызы Усманова хезмәт юлын «Йолдызчык»та музыкаль хезмәткәр булып башлаган, аннан – тәрбияче, өлкән тәрбияче булган, соңгы тугыз елда исә мөдир вазыйфасын башкара. «Шәһәргә ял көнне чыксам да, аяклар мине үзем дә сизмәстән гел бакчага алып килә. Аптыраш», – ди ул. Туган йорт кебек булып беткәч соң...

*Киләчәктә баланың кем буласы, нинди буласы балалар бакчасына йөргәндә үк күренә.*

Азнакайда иң беренчеләрдән төзелгән балалар бакчаларының берсе бу. Яңа мөдир үзенә тапшырылган хуҗалыкка өр-яңа күз белән карый да ах итә: никадәр яңартасы, рәтлисе, матурлыйсы! «Йә нидер үзгәртәм, йә бер айдан бу эштән китәм», – ди ул үз-үзенә. («Китәм...» – дип бәргәләнгән чаклар, яшерен-батырын түгел, соңрак та булгалый. Әмма... «болытлар артында кояш барыбер бар!» икәнлеге «искә төшә» дә, тагын җиң сызганып эшкә тотына ул.)

– Үземә нидер сорап, берәү каршысына да, мөгаен, бармас идем. Ә бакча өчен йөрдем! «Азнакайнефть» идарәсе ишеген дә ачып кердем, башкаларныкын да... Табылды булышучылар! Район башлыгыбыз Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин да балалар учреждениеләренә бик игътибарлы. Быел инде менә федераль программага кердек – капиталь ремонт көтәбез.

Балалар бакчасының арткы ягында буш ята торган зур гына мәйдан була. Яңа мөдир килгән елны җәй буе анда эш кайный: чүп-чарны чыгаралар, җирне тигезлиләр. Хәзер анда – «Сәламәтлек утравы»: газонлы чын футбол мәйданы ясалган, волейбол, баскетбол мәйданчыклары эшли. Җәй эссесендә балалар ачык бассейнда йөзә, комда яланаяк йөреп чыныга. Бакчаның алгы ягында исә фонтаннар эшли, әти-әниләргә утырып ял итәргә эскәмияләр куелган.

«Балалар бакчасы – сабыйлар өчен дә, аларның әти-әниләре өчен дә җәннәт ул. Кызганыч, күбесе моны мәктәпкә киткәч кенә аңлый», – ди Римма ханым. Уенын-чынын кушып әйтә. Тик «Үзгә бала» группасына йөрүчеләр «җәннәт» дигәндә шаяртырга уйламый да, алар өчен «Йолдызчык», чынлап та, җирдәге оҗмах белән бер.

Физик һәм акыл үсеше тоткарланган балаларны кабул итүче бердәнбер группа ул районда «Үзгә бала». Биш бала урынына бүген анда унөч бала йөри. Йөри дип... Арада ятып кына торучылары да бар. Кашык тотып ашый белмәгәне, йота, чәйни алмаганы. Даун, аутизм, балалар церебраль параличы белән авыручылар. Бу группаның урамга чыгар вакыты җитсә, андагы тәрбиячеләргә ярдәмгә бакчаның бөтен бушрак хезмәткәре җыела: бергә киендерәләр, күтәреп урамга алып чыгалар, алып керәләр, чишендерәләр... Әлеге группада тәрбиячеләрнең нык, түзем, сабыр булганнары гына озакка тоткарлана. Язмыш үзләрен кыерсыткан дип санаучы әти-әниләр дә үзгә мөнәсәбәт таләп итә. Әмма әниләрнең күбесе, әлбәттә, рәхмәтле! Кеше арасына чыгып китеп, башкалар кебек эшләп кайту, чирле бала белән айлар, еллар буе дүрт стена эчендә утыру түгел бит. Бала бакча яшеннән чыгуга аларның күбесен алда болай да мондый котылгысызлык көтә.

Авыру балалар һәрвакыт дәвалауга мохтаҗ. Мөдир урынына утыруга, Римма ханым бакчаның «дәвалау комплексы» дип аталган ягында ремонт башлый. Иң элек галокамераның ишекләрен ачтыра.

**ХЫЯЛЛАРЫ**

■ Үз кафесын ачу. «Мин андагы пәрдәләрнең, җиһазларның нинди буласын беләм. Ризыкларны ничек китерәселәрен. Өстәл өстендәге савыт-сабаның нindилеген... Аш-су әзерләргә яратам! Әзер ризыкны бизәп табынга китерергә – бигрәк тә! Бераүнең кайтуын көтеп өйдә генә утырсам, көн дә бер яңа ризык уйлап чыгара алыр идем».

■ Сноубордта йөрергә өйрәнү. «Һәр көнне иртәнге бишенче яртыда уянам. Чиратлаштырам: бер көнне эшкә кадәр бассейнда йөзәм, икенче көнне тимераякта шуам. Белештем инде, «әйбәт инструкторга туры килсәң, ике-өч дәрестә сноубордта шуарга өйрәнеп була», диләр. Гел биеклектән курыктым, җиңәсе иде шуны...»

■ Яңа илләр күрү. «Сәяхәт итү мөмкинлеге булган кешене иң бәхетлегә саныйм. Үзем дә байтак илләрдә булырга өлгердем анысы. Австрия, Швейцария, Вьетнам, Һиндстан, Кытай, Греция, Сингапур, Төркия, Франция, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре... Һәр сәфәремнән... фил алып кайтам. Кайда барсам да, табам мин аларны: күңелең нәрсә эзли – күзең шуны күрә. Филләрне кайчан җыя башлаганымны инде хәтерләмим дә. Алар турында әллә никадәр китап укыдым. Акыллы хайваннар... Тагын атлар яратам! Ишегалдымда ике-өч ат тоту – бу да минем хыялым!



(«Йолдызчык»та тәрбияләнүче һәр бала елга ике тапкыр унар көн рәттән галокамерада тоз парлары сулый. Грипп вакытында профилактика өчен тагын унар көн группалары белән «тоз базы»на йөриләр: кереп утыралар да йә музыка тыңлыйлар, йә әкият укыйлар.) Янгын сүндерүчеләр ябып киткән сауна да тәртипкә китерелә, яңартыла: тирләп-пешеп саунадан чыккан балаларны фито-бар көтә – үлән чәе эчәргә бик ярата алар.

«Йолдызчык»ның үз логопеды, массаж ясаучысы бар («Үзгә бала» группасындагы ике бала массаж курсларыннан соң тәпи атлап киткән! Әмма массажны реабилитация узучы балаларга гына түгел, барысына да ясыйлар.) Чирләбрәк торган – борынына томау төшкән, йөткергәли башлаган балаңны иртән бакчага китереп, тәрбияче кулына тапшырасың да, үзең тыныч күңел белән эшкә китәсең. Ә тәрбияче, табиб нинди процедуралар билгеләп, баланы барысына да үзе йөртә. Җайлы бит!

«Бала яратмасаң, бакчада эшләргә кирәкми», – ди мөдир.

Ярату, дигәннән. Римма Рәсимовна бер сер ача: бакчада эшләгән һәркемнең үзенең яраткан берәр баласы була икән. Яңа группа җыелгач, нинди дә булса сәбәп табып: «Сезгә кемнәрне китерделәр?» – дигән булып, һәркем бүлмәчләр янына сугылып чыга. Башка вакытта исә инде алар группага аерып яраткан «үз» сабыйларының башыннан сыйпарга керә. Өлкәннәр бер-берсенең кемне үз иткәннәрен сизмәсәләр, һәркайсы моны күрсәтмичә генә эшләргә тырышса да, бала-чагадан моны качырып булмый, диләр. Ярату-яратмауда балалар кебек сизгер берәү дә юк...

Ә тәрбияченең яратуы утыз баланың утызына да тигез бүленә. Якын итмәсәләр, әти-әниләре дә укымаган әкиятләрне укып, сөйләп йоклатырлар идеме үзләрен?! Ике ел элек исә Римма Усманова янә бер яңалык кертә: сабыйлар хәзер бишек җыры тыңлап йокыга китә. Җыр укытучыларының «әлли-бәлли»ләрне скрипкада уйнавын кечкенәләр бигрәк тә ярата икән. Кичен кайткач та: «Алайса йокламыйм!» – дип, өйдәгеләрдән бишек җырлары көйләргә сорыйлар. Тәрбиячеләргә яшь әниләрне дә гореф-гадәтләр белән таныштырырга туры килә. («Йолдызчык»ның бу проектын – балаларны көндез бишек җырлары белән йоклатуны татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы хәзер бөтен татар дөньясына тарату белән мәшгуль.)

*Һәр баланы үзенеке кебек күргән бик шәп тәрбиячеләребез бар: ата-аналарга да «үскәнем» дип кенә дәшә, балалары белән бергә аларны да тәрбияли.*

...Аның кул астында сиксәнгә якын хатын-кыз. Һәрберсенең үз язмышы, холкы, үз дөньясы: шатлык-сөенече, борчу-мәшәкате... Тормыш дәвам итә. Иртәгә тагын көн туачак. Офыктан кояш күтәреләчәк. Римма Рәсим кызы Усманова тагын үзенең яраткан эш урынына – балалар бакчасына киләчәк. Балаларның, хезмәткәрләрнең үзенә төбәлгән күзләрен күрәчәк. «Мин алар өчен дә җавап бирәм, – ди ул. – Һәркайсы белән уртак тел табарга тырышам – җитәкче үзе генә бернигә ирешә алмый. Бу тормышта кем булуыбыз мөһим түгел: зур җитәкчеме, әллә талантлы аш-су остасымы, уңышлы эшмәкәр, әллә гап-гади бакчачымы, иң мөһиме – кеше булып калу».

PRESSA.RU



# «КЫЗЫМ, БЕЗ ҖИҢӘРГӘ ТИЕШ!»



Мәдинә
АВЗАЛОВА

ИНКЛЮЗИВ БИЮЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА АНЫҢ ИСЕМЕН БЕЛМӘГӘН КЕШЕ ХӘЗЕР ЮКТЫР ДА. УЛ – ОСТА БИЮЧЕ, ИЛКҮЛӘМ ҮТКӘРЕЛГӘН ФЕСТИВАЛЬЛӘРДӘ ҖИҢҮЧЕ.

**Даун синдромы белән авыручы кызын кеше арасына чыгару аңа җиңел булмады. Кинәт кенә югалып калган, төшенкелеккә бирелгән, кемгәдер рәнҗегән, үпкәләгән чаклары да булмады түгел, булды аның. Әмма баласының башкалардан ким булмавын күрсәтәсе килү теләге һәрвакыт алга барырга, ябык ишекләрне ачтырырга мәҗбүр итә килде.**







Язманы күңелне тетрәткеч саннардан башлыйсы килә: безнең илдә ел саен ике меңнән артык бала «Даун синдромы» белән туа. Ел саен шуларның 85 проценты турыдан-туры балалар йортларына озатыла. Тышкы кыяфәтләре белән үк башка балалардан аерылып торган ул сабыйларга әни назы да, әни кочагының җылысын тату да насыйп булмый. Туганнан бирле йөзләреннән китмәгән елмаюны гомер буе саклый алар. Янәшәтирәдәгеләрнең мыскыллы-кызганулы карашларына аларның җавабы шул – елмаю инде! Андый балаларга Аллаһы Тәгалә артык хромосома бирә, диләр. Үзләрен ят итеп кабул иткән бу дөньяга алар, ни гаҗәп, иң бәхетле кеше сыман шатланып карыйлар. Яратып караган кешене алар шундук кочаклап алырга әзер.

Мине дә ул бер күрүдә кочаклап ала, колагыма иелеп: «Яратам», – дип пышылдый. Зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп миңа карый. Аннары әнисенә сыена. Яныннан бертуктаусыз нур-яктылык бөркелеп торган бу бала үзе дә шуңа – яратуга мохтаҗ...

– Шундый ул, – ди әнисе кызыннан күзен ала алмыйча. – Хәленнән килсә, бөтен дөньяны кочар иде. Алар бит ачу дигәннең дә, көнләшү, үч дигәннең дә ни икәнен белми. Шуңа аларны «кояшлы балалар» дип атыйлар.

Саба районының Байлар Сабасы авылында яшәүче Рәмзия белән Азат Зариповлар гаиләсенең тыныч кына бер көйгә аккан тормышын бер мизгелдә үзгәртеп куйган, хәер, болай дию генә дә аз, астын-өскә китергән сүнмәс кояшы – Ләйсән турында бара сүзебез. Яратышып, күзгә-күз карашып 31 ел бергә гомер кичкән ир белән хатынның төпчегә – көтеп алганы! Бәләкәче тугач та, инде ике кызы үсеп килгән ана: «Аллаһы Тәгалә яраткан бәндәсенә кызлар бирә», – дип куанган иде.

Алай гына булып чыкмый шул. Аллаһы Тәгалә аны кыз биреп сыный да... Бәләкәчкә ун ай булды дигәндә, табиблар: «Балагызда Даун синдромы...» – дип, телсез калдыра. Рәмзия ханым моннан 20 ел элек булган ул вакыйгаларны, кире кайта-кайта, күңеленнән барлый. «Ул чагында бу зәхмәтнең ни икәнен дә яхшылап белеп бетерми идек бит әле», – ди әни кеше. «Ишеткәч, яшен суккандай булды», – дип, хатынының ачыргаланып әйткән сүзләрен әләктереп ала ире.

Кызганычка каршы, гаиләгә килгән кайгы-хәсрәтнең беренчесе генә булмый бу. Башта ябь тә сигез айлык кызлары Алсу үлеп китә. «Мондый ачы хәсрәтне башка берәүгә дә күрсәтмә», – дип елый күбәләк гомерле баласын бер генә минутка да исеннән чыгара алмаган ана. Аннары уртанчы кызлары Әдиләнең бер күзе күрми башлый. Ата-ана өчен тагын бер зур хәсрәт. Язмыш аларны әнә шулай – бала хәсрәте белән сыный...

## *Нигә без шундый?*

Белмим, кайсы мәлдән, кайсы очрактан соң башлангандыр шушы төпчек кызны, без әйтергә яратканча, «җәмгыятьнең актив әгъзасы» итү өчен көрәш? Бәлкем, мөһер кебек сугылган әлеге диагнозны ишеткән көннәндер, ә бәлкем, кызчыкны беренче мәртәбә балалар бакчасына илткән көннәндер?! Ә бәлкем, бәйрәмчә киендереп, кулына чәчәкләр тоттырып, тәүге мәртәбә мәктәпкә – баланың, теле белән әйтмәсә дә, олы хыялына ирешкән, яшьтәшләре – кызмалайлар белән янәшә баскан мизгелдәндер?!

– Декрет ялына җәмәгать туклануы предприятиесендә эшләгән җиремнән киткән идем, – дип сөйли әңгәмәдәшем. – Декрет ялы озакка сузылды. Ләйсәнемне, ныгысын дип, дүрт яшенә кадәр имездем. Балалар бакчасына алсыннар дип, 6 нчы разрядлы ашчы булсам да, 3 нче разряд белән бакчага эшкә урнаштым. Бер ай дигәндә: «Кызыңны ал, балаларны куркыта», – дип, мыскыллап куып чыгардылар. Бик кимсендем шул чагында. Нигә без шундый икән?» – дип өзгәләнә Рәмзия ханым.

## АЛАР ДА ҮЗЕБЕЗНЕКЕ БИТ!

**Даун синдромы булган, башкача әйтсәк, гадәти булмаган кешеләргә тыныч карау, аларны ничек бар шулай кабул итү, ул авыруларның хәлләрен җиңеләйтү өчен җәмгыятебез ни дә булса эшлиме? Алар да үзебезнеке бит! Совет чорында сәламәтлеге башкалар өчен җитди проблема тудырган авыруларны, җәмгыятьтән аерып алып, махсус медицина оешмаларына җибәрә торганнар иде. Туктаусыз басым астында яшәгән ул балалар өчен һичьюгы мөнәсәбәтне, хәлне үзгәртә алабызмы? Санкт-Петербург шаһәрендә, мәсәлән, күп еллардан бирле «Ачык мохит» һәм «Шатлык киңлеге» социаль проектлары эшләп килә. Бу изге гамәлне волонтерлар башлап җибәргән. Бездә бу юнәлештәниләр эшләнә?**

**Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл УДАЧИНА:**

– «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы (2013 ел, 1 сентябрь) законы нигезендә мөмкинлекләре чикле балалар өчен инклюзив белем бирү, ягъни ата-анага, баланың теләге булган очракта, аны гадәти мәктәпкә биреп укыту хокукы бирелә. Әлбәттә, моның өчен мәктәпләрдә тиешле шартлар, әйтик, акылга зәгыйфь балалар өчен махсус программа, церебраль параличлы балалар өчен махсус тотынгычлар, бер каттан икенче катка менү өчен җайланмалар эшләтү каралган. Бала үзен сау-сәламәт яшьтәшләре арасында уңай хис итәргә, кимсенү кичермәскә тиеш. Бу тиз генә, җиңел генә тормышка ашырыла торган проект түгел. Биредә, иң элек, сәламәт балаларның ата-аналарын әзерләргә, балалар белән аңлату эшләре алып барырга кирәк. Республиканың кайбер мәктәпләре әкренләп шуңа бара да инде. Бу, әлбәттә, балалар бакчасына да кагыла. Бәләкәй чактан ук балалар берберсенә ияләшеп үссәләр, бүгенге проблемалар булмас та иде.

Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттаховның инклюзив белем бирүгә багышланган халыкара конгресста ясаган чыгышыннан: «Җәмгыятьнең өлгереп җитүе балаларга, өлкәннәргә, мөмкинлеге чикле балаларга карата мөнәсәбәттә чагыла. Республикада 2012 елдан бирле «Уңай мохит» дәүләт программасы эшләп килә. Бүген исә авыру балаларны 300 ләп мәктәп кабул итәргә әзер».

Фото Зариповлар шәхси архивыннан

PRESSA.RU



Яшьтәшләре белән чагыштырганда, бала чыннан да үсеш ягыннан артта калып бара. Нишлисең, чире шундый: ул дүрт яшендә генә йөреп киткән, җиде яшендә кыенлык белән генә сөйләшә башлаган.

*Кешеләргә гел елмаеп кына караган ул сабыйларны, әти-әниләренең күбесе, кимсетмәсеннәр, дип, урамга да чыгармый.*

Аларны түбәнсетүләр, кырын карашларның тагын да ачырагы сагалап торган икән. Ләйсәннең укырга барыр яше җитә. Бу көнне Зариповлар гаиләсе дә көтеп ала. Бәләкәй кызга мәктәп формасы, портфель сатып алалар. Чәчләренә зур-ак бант тагып, кат-кат үлчәп караган формасын да киеп алгач, Ләйсән карап туймаслык матур кызга әйләнә дә куя. Инде кулына укытучысына бирәчәк чәчәк бәйләмен дә тоттыргач, кызның иңнәренә канатлар үскәндәй була. «Укытучыма!» – ди ул, үзе генә аңлаган сүзләрне кабатлап. Мәктәпкә барганда да, башка балалар белән беррәттән тантаналы линейкада басып торганда да кызчыкның шатлыгы эченә сыймый. Инде сыйныфларга таралышыр вакыт та җитә. Кызганычка каршы, Ләйсәннең мәктәп белән танышлыгы шуның белән тәгәлләнә. Беренче кыңгырау яңгырауга ук әнисе кызын кулыннан җитәкләп өенә алып кайтып китә. Алдан сөйләшеп куелганча, баланы өйдә укытырга булалар. Укулар өч елдан соң тукталып кала. Укытучыларны өйгә барып йөрүләр туйдырамы, әллә инде бу балага уку нәрсәгә, дип уйлаганнардырмы алар... Шулай итеп, 20 яшьлек Ләйсән ни укырга, ни язарга өйрәнмичә кала.

– Шөкер, узган елның сентябреннән Ләйсәнем яңадан укый башлады, – ди Рәмзия ханым. – Пенсиядәге бер укытучы укыта. Бик тырыша, башкалар шикелле буласы килә. Хәтере бик әйбәт аның. Интернетта апаларыннан да яхшырак аңлаша, белмәгәне юк.

Әйе, ул «ВКонтакте» социаль челтәрендә үз төркемен булдырган, аңа килгән хат-фикерләрнең хисабысаны юк. Үзе аңламаганнарны кыз тәрҗемә аша микрофоннан тыңлый.

### «Бию белән яшим»

Әгәр дә Ләйсәннең ерак-еракларга китә торган хыяллары, үҗәтлеге булмаса, янында аның һәр адымын саклап-кайгыртып торучы кыю йөрәкле, тәвәккәл әнисе булмаса, нишләр иде икән ул бүген?! Аңлашыла ки, үсеш үзенчәлекләре дүрт стена арасына «йомылырга» мәҗбүр иткән, көннең көнендә бары туганнары, якыннары белән генә аралашыр мөмкинлеге булган социаль изоляция... Аның язмышына охшаш меңләгән балаларныкы кебек үтергеч-бетергеч ялгызлык...

Тик бу ямьсез әкият Ләйсән Зариповага кагылмый. Бүген ул – гөрләп торган тормышның нәкъ үзәгендә. Аны районда һәм республикада гына түгел, илдә, дөньяда беләләр. Гаҗәпләнерлекме? Әйе, гаҗәпләнерлек! Чөнки мондый хәлнең әле республика тарихында булганы юк.

Бәләкәй кызчык йөреп китүгә үк бии башлый. Ул бик музыкаль. Бию хәрәкәтләрен үзе уйлап чыгара һәм бии, бии... Бию хәрәкәтләренә феноменаль хәтере әнисен, апаларын гына түгел, хореографларны хәйран калдыра. Сәхнә кызның хыялына әверелә. «Биисем килә», – ди ул көннәрдән бер көнне аның һәр сүзен җөпләргә, куәтләргә торган әнисенә.

– Безне әледән-әле район күләмендә уздырыла торган концертларга, инвалидлар көненә багышланган кичәләргә чакыралар, – дип дәвам итә Рәмзия Зарипова. – Ике ел элек биюләрен видеога төшереп, социаль челтәргә куя башлаган идем. Бервакыт аларны гомерен Даун синдромы булган балаларга багышлаган шагыйрә Заһирә Шетлер күреп алган. Ул Ләйсәннең талантын ачты, аңа ышанды. Аның киңәше белән кызыма хореограф эзләргә керештем. Һәм таптым. Ул – Казан федераль университетының хореография бүлегендә укучы, үзебезнең район кызы Альбина Фәтхриева. Берберсен ярты сүздән аңлыйлар. Хәзер алар бергәләшеп бииләр. Инклюзив бию турында ишеткәнегез бардыр бит?!

Ишеткәнебез бар, әлбәттә. Инвалид кешенең сәламәт кеше белән бергә биюен шулай дип атыйлар. Инклюзив бию – чикләр һәм континентлар аша салынган күпер шикелле. Биегәндә бөтен кеше бертигез. Тормышыңны үзгәртәсең килә икән, Ләйсән шикелле бие дә бие генә!

### Ябыгу тарихы

Сәхнәгә чыкканчы, Ләйсәнгә шактый ук көч түгәргә, тырышырга туры килә әле. 18 яшендә 80 килограммнан узып барган кызга бию турында хыялланасы да юк.

«Әни, ничек ябыгыйм?» Бертуктаусыз көзге каршына басып, чыраен сытып торган кызына янә әнисе ярдәмгә килә. Фитнес клубының танылган тренеры Азат Вәлиуллин янына бара, сөйләшә. Шул көннән алып тренер Ләйсән белән атнасына өч мәртәбә икешәр сәгать шөгыльләнә башлый. Ул аңа тренажерда шөгыльләнү өчен индивидуаль программа төзи, махсус диета тәкъдим итә. Һәм күнегү барышында бер генә минутка да аны күздән яздырмый. Ни дисәң дә, авыру бала бит. Даун синдромы гына түгел бит анда: йөрәк өянәге дә... Ихтыяр көче, туктаусыз күнегүләр... Һәм: ярты ел эчендә 23 килограммга ябыга Ләйсән! «Тукталырга җыенмый, фитнес-клубка йөри, иртән утызар минут зумба (фитнесның яңа юнәлеше) белән шөгыльләнә», – ди әнисе, канәгать елмаеп. Зифа буй-сынлы оста биючегә инде күптәнге хыялын тормышка ашырырга да вакыт!


### Җиңүләр

Һәм, ниһаять, Зариповларның кызы Ләйсән – сәхнәдә! Рәмзия уңышларның әле алда булачагына, төпчегенең кеше сокландырырлык эшләр майтарачагына аз гына да шикләнми. Кызын дөньяга чыгару, инвалид балаларның да җәмгыятьнең тулы хокуклы гражданнары булуын

**«Апрель» тернәкләндерү үзәге методисты Фирүзә ЛУКОНИНА:**

Безнең үзәктә ел дәвамында Даун синдромлы йөзләп бала сәламәтлеген ныгыта. Без алар өчен «Балага шанс бирегез!» дигән махсус программа төзедек. Үзәк бала тудыру йортлары белән даими элемтәдә тора. Даун синдромлы бала тудымы, безгә көне белән хәбәр итәләр. Һәм шул минуттан методистлар эшкә керешә: баланың әнисе (ул беренче көннәрдә югалып, куркып калырга да мөмкин) белән сөйләшәләр, аңа үзебез чыгарган буклетны бүләк итәләр. Аннары, бала тудыру йортыннан чыгуга ук, әни кеше баласы белән безгә килә. Баланы тернәкләндерүгә никадәр иртәрәк керешәсең, нәтиҗәсе шулкадәр яхшырак, үтемлерәк була. Без баланы ничек ашатырга, ничек киендерергә, аның белән нинди уеннар уйнарга кирәклеген өйрәтәбез. Алар бездә өч яшькәчә үсә. Аннары бакчага китәләр. Гадәти бакчага. Андый балалар белән араны өзмибез. Мәктәпкә барыр чагы җиткәч, алар тагын безгә килә. «Апрель»дә булып киткән балаларның 30 проценты гомумбелем бирү мәктәпләренә укырга керә. Калганнары коррекцион мәктәпләргә бара. Андый бала бик аралашучан, яшьтәшләре арасында булырга ярата. Шуңа да инклюзив белем бирү, ягъни аларны сәламәт балалар арасына кертү, бергә укыту иң игелекле, иң кирәкле гамәлләрнең берсе ул.

Безнең адрес: Казан, 46 нчы йорт. Телефон: 557-49-34.



исбатлау өчен сират күпере кичкән әни башкача уйлый да алмый.

Ләйсәннең беренче мәртәбә зур сәхнәгә күтәрелүе моннан ике ел элек була. «Ул елны Тула шәһәрендә эстрада сәнгатенең «Дуслык канатлары» дип аталган халыкара фестиваль бәйге үткәрелде, – ди Рәмзия ханым. – Шунда хореограф Альбина белән Ләйсән дә чыгыш ясады. Кызыма, иң оста биюче буларак, Гран-при тапшырылды. Бу уңыш аңа зур сәхнәгә юл ачты. Фестивальләрдә катнашу өчен тәкъдим арты тәкъдим китте. Мәскәүгә «Бергә яхшырак!» бәйрәменә дә бардык. «Космофест-2015» фестивалендә безнең кызлар янә Гран-при яулады. Ләйсәнем Инклюзив Дэнс халыкара фестивалендә Швеция, Австрия, Нидерланд, Италия, Аргентина илләреннән килгән биючеләр белән ярышып, II дәрәҗә лауреат исеме алды. Хәзер менә Австриядә көтәләр. Аны хәзер бәйрәм концертларына еш чакыралар. Кая гына бармасын – мин һәрвакыт аның янында. Мин аңа һәрчак әйтәм: «Курыкма, мин синең белән! Мин синең яныңда! Кызым, без җиңәргә тиеш!»

Рәмзия бу уңышларның ни бәрабәренә килүен үзе генә белә. Ул – оста ашчы – 2000 нче елдан яраткан эшен ташлап, гомерен авыру бала тәрбияләүгә багышлаган. Ләйсәнгә яшь тулганнан соң, табибларга йөрүне туктаталар. Файдасыз! Сабыена читләрнең бүре баласына караган шикелле каравына да тешен кысып түзә, ачуланмый, каты бәрелми, кире кайтарып сүз әйтми. Файдасыз! Үзенә, кызына дусларны, аны, бары аны гына аңлый торган кешеләрне читтән эзли ул. Һәм таба. Йөзләгән, меңләгән фикердәшләр таба! Баксаң, ул бер дә ялгыз түгел икән. Ул Даун синдромлы балалары булган әти-әниләргә интернет аша мөрәҗәгать белән чыга. «Ләйсән шикелле балаларның проблемасы мине нык борчый. Балаларыгызны ташламагыз! Аны ишетәләр, аның белән киңәшләшәләр, серләшәләр. Елашып та алалар. Байлар Сабасында яшәп ятучы гади бер авыл хатынының исеме тора-бара әнә шулай ил күләмендә яңгырый, телдән-телгә йөри башлый. Авыру балалар саны (гомумән, Даун синдромы турында гына бармый сүз) елдан-ел арта барганда илебез генофонды чаң сугар дәрәҗәгә җиткән бер вакытта Рәмзия Зарипова, биек киртәләрне үтеп, җанында кайнаган хисләрен аны ишетмәүчеләргә, дөресрәге, ишетергә теләмәүчеләргә түкмичәчми җиткерү өчен җан тырмаша.

Ул беркайчан да төшенкелеккә бирелми. Турысын гына сөйли, дөресен генә әйтә. «Ярый әле Аллаһы Тәгалә миңа шушы баланы бирде!» – дигәндә дә, сүзләре чын йөрәктән, ихлас күңелдән яңгырый. «Кояшлы балалар» янында үзеңне башкача тоту мөмкин дә түгел. Аннары... ярамый да.

*«Андый балалар өметсез дигәнне Ләйсәнем үрнәгендә юкка чыгарасым килә».*

...Сәхнәдә – «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Хатын-кыз – ана» номинациясендә катнашучы Рәмзия Рәшит кызы Зарипова. Ул, тын калып, аны тыңлаган әниләргә авыру бала тәрбияләүнең Ходай биргән олы сынау булуы турында сөйлисөйли дә: «Ярый әле ул балам бар!» – дип куя. Зал гөрләтеп кул чаба. Чыгыш тәгәлләнгәндә генә экранда ут кабына, һәм кыз белән ана пәйда була. Шулчак Ләйсән әнисенең: «Без җиңәргә тиеш!» дигән сүзләрен искә төшерепме, колагына иелә дә: «Әнием, син җиңәргә тиеш!» – дип кабатлый. Бер уйласаң, «Кояшы»ның нурын бөтен дөньяга таратучы, илләр белән илләр арасында өмет күпере салучы бу ана инде күптән җиңүче бит!

«Ел хатын-кызы. Ел ираты: хатын-кыз карашы» бәйгесенең зональ турлары һәм финалистлар исемлеге белән сайтыбызда танышып була.

PRESSA.RU

# БЕЗ – ХАТЫН-КЫЗ!




**Хатын-кыз бәхетле булса — аның тирә-юнендәгеләр, якыннары да бәхетле. Әмма моңа ничек ирешергә соң? Әйе, тормышыңның кайчак үзең теләмәгән башка сукмакка борылуын аңлыйсың, нәрсәнедер үзгәртергә кирәк икәнен дә тоясың...**
**Тик нәрсәне? Менә шундый чакта тренинглар хатын-кызга үзенең уй-хыялларын искә төшерергә, тормыштан ни теләгәнен ачыкларга, аңларга булыша да бугай инде. Бүгенге әңгәмәдәшебез — психолог, хатын-кыз программалары тренеры Зөлфия МӘКСУТОВА.**

**Бездә тренингка ниндидер проблемасы булганнар гына йөри дип уйлау бар...**

– Әйе, кызганычка каршы, андый күренеш очрый. Тирә-юньдәгеләр үзләре турында начар уйламасын дип, кызларга кайчак тренингка йөргәннәрен яшерергә дә туры килә.

Тренинг узарга теләүнең сәбәпләре төрле, әлбәттә. Кемдер үзен ышанычлырак тоту өчен үзенә-үзе биргән бәяне күтәрергә теләп килә. (Безнең – хатын-кызларның үз-үзебезгә биргән бәясе, гадәттә, гел түбән була.) Кемдер ире белән мөнәсәбәтләрне көйләргә тели. (Ирем белән алга таба болай яши алмыйм, аерылышу да куркыта – кулымда ике бала, дип килүчеләр бар.) Ә кемнеңдер барысы да әйбәт: ире дә, балалары да, эше дә, ләкин аларга тормыш бер урында тукталган кебек, – күңелләре яңалык, үзгәреш тели. Андыйлар күбрәк үзлегеннән үсәргә теләп, интеллект арттыру өчен килә.

35-45 яшьләр арасында күп хатын-кызлар кризис кичерә: бу чорда аларда эчке конфликтлар күбәя. Шул сәбәпле, күңел төшенкелеге, депрессия башланырга мөмкин. Җандагы авыртуны, әрнүне ничек итеп бастыру юлларын эзләп тренингка килүләре – табигый.

Кызлар арасында егетләр белән җиңел, иркен итеп аралашып китә алмауларының сәбәбен эзләп, шуны аңларга теләп килүчеләр бар. (Юк, мин берәүгә дә тренингтан соң кияүгә чыгасыз дип вәгъдә бирмим! Безнең бит максат башка.)

**Китап кибетләрендә боларның барысы хакында язылган китаплар бихисап! Интернетка кереп эзләнә башласаң, тагын да күбрәк мәгълүмат табасың. Нигә тренингка йөрергә, теләсәң, өйдән чыкмыйча да тормышыңны үзгәртергә өйрәнеп буладыр.**

– Мин үзем дә китапларны бик күп сатып алам. Укыйм-укыйм да, күнегүләргә җиткәч, туктыйм – китапны киштәгә алып куям. Аннан икенчесенә тотынам һәм... тагын барысы да өр-яңадан кабатлана. Китапта язганнар баштагы мәгълүмати «чүп»кә генә әйләнә. Ә тренингка килгәндә кеше акча түли: аны җилгә очырмассың бит инде – шуңа ул кушканны үти дә. Ә үзгәрешләр нindидер күнегүләр ясаганда, алган яңа мәгълүмат практика белән үрелеп барганда гына башлана: без дәрестә язабыз, кул белән нидер эшлибез (әйтик, пластилиннан нидер әвәлибез, рәсем ясыйбыз), тел белән сөйлибез... Тыңлаган, ишеткән мәгълүмат шул очракта гына ДНК дәрәҗәсендә эчкә салына – аңга тәэсир итә. Кеше шул вакытта гына үз-үзе өчен психологка әйләнә. Кемдер үзе өчен көтелмәгән шактый «кызык» яңалыклар ача. (Бер генә мисал. Тренингка килгән бер ханым ире белән күптән түгел аерылышулары турында әйтте. «Юк, кабат башка кушылмабыз инде, иремнең холкы бик авыр иде. Аның белән мин генә яши алганмындыр, башкалар түзмәс», – диде ул. «Гафу үтенү» дигән техника бар бездә – дәресләрнең берсендә шуны эшли башладык. Үзе язганнарга карап торды да, әлеге ханым: «Ул минем белән ничек торган икән?! Мескен!» – дип ирен жәлләргә кереште... Үзебезне әүлия дип белсәк тә, чынлыкта, кимчелекләр һәркайсыбызда да җитәрлек бит.)

**Элеккегеләр бернинди тренингка да йөрмәгән...**

– Әйе, аларга тренинглар кирәкмәгән. Әмма хәзер тормыш нык үзгәрде. Әбиләребез, әниләребез кебек кенә яши алмыйбыз инде. Үзебезнең энергетиканы көйләү өчен безгә нидер эшләргә кирәк. Тренингка килүче хатын-кызларның күбесенә ир-ат табигате хас. (Хатын-кызны эчтән иң нык җимерүче көч шушы ул!) «Мин бит болай да матур, чибәр хатын-кыз. Тренингка йөрү нигә кирәк?» – дип уйлый кайберәүләр. Зифа буй-сын, затлы киемсалым, матур макияж гына түгел әле ул хатын-кыз табигатьле булу. Хатын-кызларга гына хас нәфислек, йомшаклык, мөлаемлык аның эчендә ятарга тиеш. Ир-ат иң элек хатын-кызның тышкы матурлыгын түгел, әнә шул эчке халәтен, энергиясен «күрә», шуңа игътибар итә дә инде. Яшерен-батырын түгел, хатын-кыз булырга безне берәү дә өйрәтми. Әбиләребез моны белми, ирләре сугышта үлгән әниләре аларны ялгыз үстергән, дөнья нужасын ир-ат өчен дә, хатын-кыз өчен дә үзе сөйрәгән. Безнең әниләрнең дә күбесе: «Мин барысын да үзем эшли алам!» – дип яшәгән. Без дә шулай... Башкаларга ялынганчы, дип, бар йөкне үзебез тартабыз. Аннан, кырык яшьләренә җиткәндә хатын-кызның башына: «Ә бу миңа нәрсәгә кирәк соң?» – дигән уй керә, ул ара, аңарда кризис башлана...

Тренинг вакытында, күнегүләр ясый-ясый, хатын-кыз үзенең табигатенә тиеш булган халәткә керә, тынычлана. Дөнья артыннан бертуктаусыз куу туктамаса да, әкренәя. Ниһаять, ул киеренке халәттән чыга. (Без бит үз-үзебезгә азрак «йомшарырга», ял-хәл алырга беркайчан да ирек бирмибез. Кая ул!) Һәм, ниһаять: «Әйе, мин хатын-кыз!» – дип уйлый башлагач, аның башында да нидер үзгәрә... Ә инде үзен яраткан, бәяләгән, үзен ничек бар шулай кабул итәргә өйрәнгән хатын-кызга башкаларның да мөнәсәбәте үзгәрүе гаҗәп түгел... Хатын-кыз үзгәргәч, иң беренче чиратта, аның янындагы ир-ат та үзгәрә. Үзе дә сизмичә! «Мин матур!» – дип ышанган хатын-кызның матурлыгын иң элек аның ире «күрә», аннан тирә-юнендәгеләр, хезмәттәшләр, урамдагылар игътибар итә. Аңа комплиментлар ява башлый! Бигрәк тә, «камиллеккә мәдхия» дигән техниканы узганнан соң. (Бер кызыбыз иренең: «Мин сиңа кабат гашыйк булдым бугай! Чибәрләнеп киттең әле. Нәкъ Афродита!» – дип әйтеп, мәхәббәт аңлатуын шаккатып килеп сөйләде: «Гомергә андый сүзләр әйткәне юк иде. Кайдан тапкан?!»)

## *Нәрсә эшләргә кирәген белмәсәң, нәрсәдер эшлә!*

Тренинглар, беренче чиратта, кешенең эчке ресурсларын табарга, ачарга ярдәм итә. Кызлар арасында соңрак үз бизнесын ачучылар яки тәвәккәлләп бөтенләй башка юнәлештәге эшкә тотынучылар бар. Алар: «Әйе, мин моны булдырам!» – дип уйлый. (45 яшьлек тыйнак кына бер ханым килде тренингка. Ике-өч дәрестән соң ук аның йөрешләренә кадәр үзгәрде, күзләре яна башлады. Тренинг ахырында ул: «Мин үз эшемне ача алам бит», – дигән фикергә килде. Бу хакта

**Хатын-кызның энергиясе аз булганда аны «күрмиләр».**
**Ә аның энергиясен, үпкә-рәнҗүдән тыш, тагын ниләр ала соң?**

- Башлап ташланган, ахырына җиткерелмәгән, эшлисе бар дип уйлап йөргән эшләр.
- Тәртипсез җенси тормыш алып бару.
- Йокы туйганчы йокламау.
- «Мин нигә башкалар кебек түгел» дип, үзеңнән канәгать булмау, «дөрес эшләмәдем», дип үз-үзеңне битәрләү.
- Гәүдәңә, буй-сыныңа карата таләпләрең, дәгъваларың артык күп булу.
- Бала төшүләр, аборт ясатулар: саклап кала алмадым, дип, хатын-кыз мондый очракта гел үзен гаепли.
- Гомумән, үзен балалар, ир, әти-әниләр каршында, эштә гел нәрсәгәдер гаепле тою.
- «Мин әйбәт хатын (әни, әйбәт хезмәткәр) булырга тиешмен» дип санау.
- Җыештырылмаган өй, китек чынаяк-тәлинкәләр, тәмамланмаган ремонт та хатын-кыз энергиясе кимүгә сәбәп булып тора дип санала. Ир-ат белән мөнәсәбәтләрдә хатын-кыз күбрәк биреп, азрак алса да, аның энергиясе китә.

PRESSA.RU



моңарчы беркайчан уйламаган! Тренингны ул үткән елның апрелендә узды. Аннан «Акча» дигән тренингка да йөрде. Ә декабрьдә инде миңа үзенең визиткасын китерде. Элеккеге эшеннән киткән. Мөселман хатын-кызлары өчен күлмәкләр тегә башлаган. Интернет-кибетен ачкан. Берничә тегүче яллаган. Инде күмәртәләп сатып алучылар белән эшләргә керешкән. Шаккаттым!)

*Проблемалар бер-бер артлы кабатлана икән, бу – хәбәр: димәк, нәрсәнедер дөрес эшләмисең.*

**Үзеңдә хатын-кыз энергиясен арттыру өчен нишләргә кирәк?**

– Эчтәге агрессиядән, «керпе»-ләрдән арынырга, үпкә-рәнҗүләрне онытырга, кичерергә. Бөтен нәрсәне дә! Сәламәтлегебез өчен иң куркынычы – үпкә-рәнҗүләр. Алар вакыт узу белән онытылган кебек тоелса да, чынлыкта, беркая да китми, эчтә җыелып бара. 35 яшьләрне узган кайбер хатын-кызларга карасаң, аларның күңелендә инде хыял, теләк юк, күзләре сүнгән... Эчтә таш-таш булып җыелган үпкәләр яшәүне шулай кызыксыз итә. Авырулар шулар аркасында килеп чыга. Шуңа күрә ни генә булса да: «Гомеремдә кичерәсем юк», – дияргә ашыкмагыз: болай әйтеп без үзебезгә генә зыян салабыз... Махсус техника ярдәмендә тренингта бөтен нәрсәне кичерергә өйрәнәбез. Күңелсез, начар хатирәләр күңелдән китә, җанга тынычлык иңә. Шул чакта хатын-кыз чәчәк ата башлый! (Яшь кенә бер ханым йөрде тренингка. Дүрт айлык баласын кәрзингә салып алып килә иде ул. Ирем белән аерылышасым килми дип, гел аны кичерү, гафу үтенү техникасын ясады. Ире акча да бирми тилмертә иде аны. Беркөнне сөенеп килгән: «Ул миңа чебуреки алып кайткан!» – ди. Шуннан, әкренләп, ире аңа кием-салым ала башлады. Матур сүзләр дә әйткәли торган булды. Хәбәрләшеп торабыз: инде тормышлары тәмам көйләнде, күптән түгел яңа йорт та салып чыктылар.)

**Тренингка килүчеләргә иң беренче дәрестә үк: «Үзеңнең йөз (!) хыялыңны яз», – дигән өй эше бирелә. Күбрәк түгелме бу?**

– Хатын-кызларның 90 проценты бөтенләй хыяллана белми... Кәгазьгә йөз хыял төшерергә кушкач, күп булса, 10-12 гә җитәләр дә, туктыйлар. Моның сәбәбе бик гади: кечкенә чакта безне беркем дә хыялланырга өйрәтми. Киресенчә, «Хыяллан-ма!» – дип, адым саен тыеп торалар. Күңелдә ниндидер хыял туугa без аны бастырыклап куярга гадәтләнгән инде...

Үзеңне көчләп өстәл янына утыртып, хыялларны кәгазьгә төшерү безне хыялланырга этәрә. Бу бик мөһим! Чөнки хыялларда мөмкинлекләребез ята. Тормышыбызга «тартып» керткәч, алар чынга аша башлый. Хатын-кызның хыяллары кечкенә булса, аның янәшәсендәге ир-атның җиңүләре, уңышлары да кечкенә. Хыяллар зур булса – киресенчә. Алар бер-берсенә бик нык бәйләнгән. Хатын-кыз үзенең хыяллары белән гаиләсенең чикләрен киңәйтә. (Тәрәзәгә яңа пәрдә, өйгә яңа җиһаз алу уе иң элек хатын-кыз башында туа лабаса.) «Югары дәрәҗәгә ирешкән ир-атларның уңышы хатыннарыныкы да», – дип юкка әйтмиләр. Ирләрнең керемнәре дә безнең хыялларга бәйле.

Әмма бер нәрсә бар: «теле белсәң – теләк, теле белмәсәң – имгәк», дип әйткәннәрен онытырга ярамый. Әйтик, «булачак ирем көчле кеше булсын, җитәкче урында эшләсен», дип хыялланасың икән, үзең аңа буйсынырга әзерме? «Сизгер җанлы, йомшак күңелле булсын», дисәң, тормыш катылык таләп иткән чакларда дилбегәне үз кулыңа алырга туры килүен уйлыйсыңмы?

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ТРЕНИНГ-ЦЕНТР ЗУЛЬФИИ МАКСУТОВОЙ
iHappy
Женские психологические тренинги
Индивидуальные консультации
Индивидуальный коучинг
Творческие мастер-классы
Образовательные курсы
Контакты: +7 987 060 73 56
+7 905 316 42 94
Адрес: Казань, ул. Московская, 31
офис 211а
РЕКЛАМА





# БЕЗ ШУНДЫЙ!





Хатын-кызны күкләргә чөеп мактар, дөньяның асыл затлары өчен ихластан бер горурланып алыр өчен ярый әле «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын кыз карашы» республика бәйгесе бар! Әйе, без шундый: киң күңелле кайгыртучан әни дә, булдыклы эшмәкәр дә, мәдәни-рухи тормышыбызны әйдәп баручы лидер да, үз эшенең остасы, үрнәге дә... Юк, ни дисәгез дә, хатын-кызсыз бармый бу дөнья! Безнең хәзер моңа иманыбыз камил.

Бу бәйгене үткәрүгә хәтта кризис та комачау итә алмый. Быел әнә зона турлары сигез төбәктә: Әлмәт, Мамадыш, Яшел Үзән, Чистай, Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм Биектау районында булып узды. Биредә хатын-кызларның иң күренеклеләре, иң уңганнары, кыскасы, иң шәпләре катнашты. Жюри составына кертелгән «Сөембикә» журналистлары да үзенең ике баласы янына дүрт ятимне сыендырган Марина Ионова («Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңүче, Биектау районы); Манзарас авылының «әнисе», авыл җирлеге башлыгы Рәмзия Хәбибуллина («Хатын-кыз – лидер», Кукмара районы); Гөлнара Заһидуллина («Хатын-кыз – бизнес-леди», Саба районы); җырлары белән хәйран иткән «Шаян» ансамбле җитәкчесе Нәкыя Нәсифуллина («Хатын-кыз – ел үрнәге»); кайчандыр физкультура укытучысы булып эшләгән һәм бүген кинезетерапия системасы буенча төркем оештырып, дәрес-күнегүләр алып баручы тынгы белмәс 70 яшьлек Тәнзилә апа Шәйхуллова («Өлкән буын» номинанты, Менделеев районы) кебек кулларында ут уйната торган ханымнарга сокланып карап, гыйбрәт алып утырдык.







«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесен оештыручылар – Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы, Татарстанның профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хезмәткәрләре һәм Татарстанда кеше хокуклары яклау буенча вәкаләтле вәкиле. Бәйгенең тугыз номинация буенча үткәрелүен исегезгә төшерәбез. Җиңүчеләргә бүләкләр март башында Казанда узачак зур тантана-бәйрәмдә тапшырылачак.





«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесенең зональ турлары һәм финалистлар исемлеге белән сайтыбызда танышып була.

PRESSA.RU





Автор фотосы

# ЧИСТАЛЫК ҺӘМ ТӘРТИП КАПКЫНЫНДА



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Балалар туганчы мин катырып куйган тәртип ярата идем. Өйдә нәрсә дә булса кыек ятса, янынннан тыныч кына үтә алмыйм – турылап куям; бизәнгечләр янчыгымда һәрнәрсәнең үз оясы бар иде. Китапларым да Тукайның «Шүрәле»сендәге наратлар кебек рәт-рәт тезелеп тора иде...

Иде, дим, чөнки бүген безнең өйдә өч яшь ярымлык һәм унбер айлык ике кыз бала үсеп килә. Кайчагында иннекне уенчыклар арасыннан табып алып сөртергә туры килә. Хәзер бездә еш кына кәстрүл капкачларын да залдан ээләргә кирәк – кечкенә кызымның яраткан уенчыгы ул. Һәм шушында үз башыннан үткән кешеләр өчен язмамны төгәлләп тә куярга була – алар аңлады инде. Ләкин көн саен диярлек яңа сызыклар өстәлүдән модернистик сәнгать әсәрләрен хәтерләтүче обойлар турында да сөйлисе килә бит әле. Ягъни бу язма «минем ничек итеп идеаль хуҗабикә булырга өйрәнүем» турында.

Әй кызыгам инде рекламаларда күрсәтелә торган пөхтә итеп җыештырылган фатирларга, чип-чиста итеп киенгән тыңлаучан балаларга, ул балаларның «Роллтон» шулпасына майонез салып биргәнне телен йотардай булып ашаучы әтиләренә һәм әле генә матурлык салоныннан чыккан кебек «ялт» итеп торган әниләренә! Булдыклы хатыннарныкы гел шулай буладыр инде...

Димәк, мантыйкка ярашлы, мин булдыксыз булып чыгам, чөнки бездә әлеге манзарага охшашлы мизгелләр сирәк була. Болай мин үзем өйдә – аш пешерүче, тегүче, җыештыручы, табиб, юрист, укытучы, икътисадчы, дизайнер-стилист, психолог. Тәүлегенә 24 сәгать кизүдә мин, моның өчен миңа бер тиен хезмәт хакы түләнми, якыннарым сәламәт һәм шат булса – миңа шул җиткән, чөнки мин – әни кеше.

Шул ук вакытта мин гап-гади хатын-кыз да бит әле дип кычкырасы килә кайчак! Бигрәк тә бер бүлмәне җыештырып бетереп, икенчесенә чыкканда, шундый ук «бардак» каршы алса. Ә уңда аш бүлмәсе – анда раковинада тау булып өелгән савыт-саба һәм кичке ашны әзерләр өчен җебетергә алып куйган ит һәм башка яшелчәләр. Юыну бүлмәсендәге кер машинасы «кетер-кетер» үз эшен эшләп утыра (аны уйлап чыгарган кешегә кулымны күкрәгемә куеп рәхмәт әйтәм!), ә йокы бүлмәсенең икенчесендә кер үтүкли торган тактада юылган керләр үз чиратын көтеп ята – тау кадәр булып өелмәгән бит әле, ишекне дә этеп ябарлык түгел – көтсен, дисең дә тыныч күңел белән борылып чыгып китәсең. Тукта, залдан никтер бер тавыш та килми, кызлар нишли икән? Билгеле инде, әгәр кечкенә бала сине борчымый, тавышланмый, еламый икән, димәк, анда сюрприз көтә. Келәмгә рәсем төшерәләрме икән? Гөл чүлмәген аударып, балчыгыннан «пәрәмәч пешереп» утыралармы? Бәлки, диванга пластилин ябыштырып уйныйлардыр – күңелдән генә кырыкмаса-кырык төрле этлек уйлап өлгерәсең. Уф-ф, юк икән, алдагы көнне Зөлфия сабын куыклары алдырткан иде, шуның суы белән Адиләнең башын гына юган икән...

Зөлфия беренче тапкыр обойларга рәсем төшергәч, бу әзер өйгә килен булып төшкән кеше буларак, шүрләп калган идем – кайнанам ни дияр? Ә ул: «Дөнья малы өчен баланы орышасы юк, язу-сызу яшеннән чыккач яңасын ябыштырырбыз, сәламәт булып торыйк», – дигәч, эчкә җылы керде. Алай да «Икеа»дан махсус такта алып кайтып куйдык – рәхәтләнсен, дидек. Әмма рәхәтләнмәде, аның каруы обойлардагы сызыклар Зөлфиянең буе үскән саен биегәя генә бара. Тора-бара фломастердан калган эзләр нindидер бер җитезлек белән караватбашларында, шкафларда пәйда була башлады.

Кечкенә чакта апама ияреп мин дә акбур белән коймаларны буяштырып йөргән идем. Әни моны күрде дә апамнан юдыртты. Апам зур иде инде, сигез яшьләр чамасы булгандыр, миңа өч тирәсе. Әмма аның елый-елый койма юганы истә калган. Сабак булмаган, ахрысы, ул минем өчен – биш яшьләр тирәсендә әби орышкач, ачу итеп, авылның бүрәнә өенә тигезле-тигезсез ябыштырылган обойны таяк белән тишкәләп чыккан идем.

Ә өйдә чисталык белән тәртип сакларга безне кечкенәдән өйрәттеләр. Безнең татарның канында бит ул өй җыештыру – ял итмәсә итми, әмма өен музей кебек итеп җыештырып куя. Тузан да төшерми! Өйдә артык әйбер тотарга яратмыйбыз, тизрәк чыгарып ташлыйбыз. Яңа җиһаз алсак, искесен – чүплеккә. Яңа заман модасы – фэн-шуй да шулай куша анысы. Янәсе, «си» энергиясенә иркенлек кирәк. Әмма шушы рәвешле күпме ядкарьләр чүплек башында кояшта уңып юкка чыккан бит: винтаж стилендәге иске кәнәфиләр, абыйның Германиядән армия хезмәтеннән алып кайткан чемоданнары, картәбинең укалы камзуллары... Ә без чүп дип мичкә аткан көндәлекләрен әни бүген дә сагынамы икән әле? Истәлекләрне тереләй утка якканбыз – имеш, кыз балалар өй җыештыра.

*Әгәр балалар булган өйдә идеаль тәртип икән, димәк, биредә нәрсәдер дөрес түгел.*

...Менә хәзер тиз арада тавык та чүпләп бетерә алмастай шушы мәшәкатьләрдән котылмасаң, менә хәзер шушы мизгелне кулдан ычкындырсаң, безнең шушы микрокосмосыбыз мәңгелек хаоска әйләнәчәк! Ә болай миңа тәртип урнаштыру өчен нибары ярты сәгать яки кырык минут вакыт кирәк булачак. Икенче раунд башланганчы, әлбәттә.

Их, шушы көн саен кабатлана торган кырык минут бит ул! Еллар дәвамында көн саен мин грек мифологиясендәге Сизиф роленә кереп алам. Сизифныкы кебек минем эш тә мәңге бетми, кабатлана, нәтиҗәсе юк, рәхмәт әйтүчесе дә... Хатын-кызның тәкъдиренә язылгандыр инде: аның эшләгән эше күренми, эшләмәсә – ничек кенә әле! Кабатлана торган шушы мәшәкатьләрдән котылу өчен элегрәк миңа ярты көн кирәк булыр иде, ә бәлки, бер көндер. Бөтен хикмәт тә эшне автомат рәвештә башкарырга өйрәнүдә бугай – теш чистартырга кергән арада да юыну бүлмәсен тәртипкә салып: раковина белән унитазны юып, кер машинасын кабызып чыгасың. Иртәнге ашны әзерләгәндә, кичкә пешерәсе итне суыткычтан алып куясың, берәр шкафны тәртипкә салып өлгерергә була. Ә бит студент чакта без имтиханнарны һәм сынауларны гына «автомат» рәвештә тапшыра идек.

Гомумән, балалы өйдә тәртип саклау кар яуганда кар көрәүгә тиң, дигән сүз хак ул. Балалар булган җирдә хәрәкәт бар. Хәрәкәт булган җирдә тузан да

PRESSA.RU



куба, әйбер дә туза. «Бала өчен һәрнәрсә мулдан булырга тиеш. Бала кечкенә чагыннан ук муллыкка өйрәнеп үссен. Муллык дигәндә бер вагон һәм бер арба уенчык дигән сүз генә түгел. Ул кояш нурларында коенсын, авыз тутырып җиләк ашасын, сөт эчсен, суга да чумып уйнасын, кар көртләрендә аунасын. Рәхәтләнеп көлсен, тирләп, чәчләре маңгаена ябышканчы йөгереп уйнасын», – бу прицип, ялгышмасам, японнар тәрбиясеннән.

*Бала иркле, мөстәкыйль шәхес булып үссен өчен аңа үзен уңайлы итеп хис итә торган иркенлек булдырырга кирәк. Без өлкәннәрнең төп бурычы шул түгелме соң инде?*

Берничә ел декрет ялында утырган арада үземнең кагыйдәләр җыелмасы да барлыкка килде. Киңәш итеп әйтмим, әмма үзем кебек хуҗабикәләр белән уртаклашасым килә, бәлки, кемгә дә булса ярдәме тияр:

- әгәр макияж ясаган булсаң, кичтән битне чистартмыйча йокларга ятмаска;
- иртән торгач, беренче эш итеп теш чистарту һәм чәч тарау мәҗбүри;
- кичтән раковинада юылмаган савыт-саба калдырмаска (безнең әбиләр, төнгә пычрак савыт-саба калдырсаң, аны төнлә шайтан ялый, диләр иде);
- иртәгә кичке ашка нәрсә пешерергә икәнен бүген кичтән планлаштырып ятарга, бәлки, кибеттән алып кайтасы нәрсәләр бардыр;
- өйне көн саен – җиңелчә генә, ә атнага бер – әйбәтләп җыештырырга;
- тузан сөрткәндә ишек токталарын да сөртергә (балалар булгач, элек игътибар итмәгән һәм барлыгына юньләп ышанмаган вирус һәм микробларны таный, күрә һәм тоя башлыйсың икән);
- әгәр балалар бәләкәй чагында берәр җиһаз алырга яки ремонт ясарга туры килсә, материалларның кыйммәтлесен алмасаң да ярый яки кыйммәтле обой, плитка ябыштырмаска. Җиһазларның бармак эзе калмастаен сайларга кирәк;
- идәнгә су түгелсә дә, зыян килми торгандаен җәяргә (балага аларны нинди бәядән сатып алганны аңлатып булмый);
- уенчыкларны тутыру өчен зур тартмалар булдырырга (ни гаҗәп, Зөлфия «тәртип» төшенчәсен башкачарак аңлый бугай – уенчыклар тәртип белән тартмада ята икән, аның эче поша башлый, ул аларны таратып ташларга ашыга);
- әгәр син чын хуҗабикә икән, мистер Пропперның барлыгына һәм аның кайчан да булса син яшәгән урамга да бер килеп чыгачагына ышанырга! Кешене өмет яшәтә бит...

# FLYLADY СИСТЕМАСЫ

Көндәлек мәшәкатьләрдән йончыган хуҗабикәләр өчен флайледи системасы бар. Аны 1999 елда Марла Силли исемле шундый ук хуҗабикә уйлап чыгарган. Әлеге системаның нигезендә авторның шәхси тәҗрибәсе ята. «Белсәгез иде минем моннан ничек туйганымны!» дигән җан авазы танышмы сезгә? Үзегезне плитә янында, идән чүпрәге тоткан килеш һәм себеркедән башка күз алдына китерә алмыйсызмы? Әфсенләнгәндәй, әсирлек боҗрасында итеп хис итәсезме? Бәлки, хәлләр алай ук аяныч түгелдер?

Марланың «finally loving yourself» – «үзеңне ярат, ниһаять» дип аталган системасы хуҗабикәләр арасында интернет аша дөнья буйлап тиз арада тарала бара. Хуҗабикәләрнең иҗтимагый оешмасы түгел бу, ә вакытны дөрес оештырырга өйрәнү өчен кулланма, ягъни хуҗабикәләр өчен ярдәмлек.

Теләсә кайсы системадагы кебек флайлединың да үз терминологиясе бар. Төп төшенчәләре өчәү: зоналар, көндәлек мәшәкатьләр һәм контроль кенәгәсе яки көндәлек.

**Зоналар,** аңлашылганча, өйдәге яки фатирдагы бүлмәләрне, мәйданнарны күз уңында тота: аш бүлмәсе, юыну бүлмәсе, йокы бүлмәсе, коридор һәм башкалар. Һәр зонага аерым атна багышларга була.

**Көндәлек мәшәкатьләр.** Төп бурыч – аларны ялкыткыч эштән яратып башкарыла торган шөгыльгә әйләндерү. Алар иртәнге һәм кичкегә бүленә. Иртәнгесенә теш чистарту, иртәнге аш яки макияж салуны кертергә була. Кичкесенә юыну, йоклар алдыннан китап укудан тыш, иртәгәсен һичшиксез үтәлергә тиешле эшләр дә теркәлеп куелырга тиеш.

**Көндәлек.** Ул берничә бүлектән тора. Беренчедән, атналык план. Һәрбер көннең төп эше аерып билгеләнә: кибеткә бару, кер юып үтүкләү, тәрәзә челтәрләрен алыштыру һәм башкасы. Шулай ук ваграк эшләр дә планда теркәлсен. Икенчедән, кенәгәдә кирәге чыгардай телефон номерлары язылган бүлек булырга тиеш. Рецептлар өчен аерым бүлек. Һәм шәхсән үзегез өчен кызыклы идеяләрне, фикерләрне теркәп бару өчен аерым бүлек булдырырга кирәк.

**ФЛАЙЛЕДИ ӨЧЕН КИРӘК БУЛЫРГА МӨМКИНЕ:**

- таймер (аның өчен вакыт олигархларныкы кебек үк кадерле төшенчә, тигез табанлы аяк киеме кебек үк);
- чиста раковина (бу теләсә кайсы хуҗабикәнең йөзе!);
- башмак урынына туфлиләр (монда халат урынына күлмәк яки җыйнак киемне дә өстисе килә, хуҗабикәләр өчен дресс-код юк дигәнгә ышанмагыз, көнчыгыш хатын-кызлары бу җәһәттән безнең өчен үрнәк – алар өйдә дә матур).

**ФЛАЙЛЕДИНЫҢ ПРИНЦИПЛАРЫ:**

- өйдә чүп-чар, кирәкмәгән әйбер сакламаска, алардан котыла барырга;
- өйдә «кайнар нокталар» була, ул урыннарда пычрак тизрәк җыела, шуңа күрә андый җирләрне күз уңыннан ычкындырмагыз;
- колач җитмәстәй эшкә берьюлы алынмагыз, флайледи системасына да кинәт кенә күчмәгез, беренче итеп чиста раковинадан башлагыз, калганы үзеннән-үзе киләчәк.

## ҖӘМГЫЯТЬ



**ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Менделеевскидагы «Аммоний» заводында Япониянең Россия Федерациясендәге илчелеге вәкаләте башлыгы урынбасары Хитоси Озава белән очрашты. Ул Япония кунакларын сәламләп, Татарстанда гамәлгә ашырыла торган проектларга ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерде. «Аммоний» заводын төзүне Россия белән Япониянең нәтиҗәле хезмәттәшлек итү үрнәге дип белдерде. Очрашуны йомгаклап, Рөстәм Миңнеханов кунаклар катнашында Япониядә зур эшне тәмамлау символы булган «дарума» курчагының икенче күзен буяды — берсен ул «Аммоний» проекты гамәлгә ашырыла башлаганда буяган иде.**

**ТР Президенты туган авылы Яңа Арышта (Балык Бистәсе) Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов һәм «Салават» җыр театрының хәйрия концерты узды. Җырчы авылда яңа мәчет төзелешенә шулай өлеш кертте. «Россия балалар фонды»ның Татарстан бүлекчәсе рәисе дә булган Салават халыкны игелекле гамәлләр кылырга чакырды, «Изге эшләр белән башкаларны сөендерү безнең канызда», — диде. Бу вакыйгада ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә булышлык күрсәтү фонды җитәкчесе Нурия Һашимова да катнашты.**

## КОТЛЫЙБЫЗ

**«Хәзинә» милли сәнгать галереясында Бакый Урманче исемендәгә премия лауреатларын тәбрикләделәр. Әлеге абруйлы бүләккә быел Александр Петров, Вера Карасева, Рөстәм Габбасов, Рөстәм Шәмсутов, Ольга Улемнова лаек дип табылды.**



## МӘДӘНИЯТ

Казан Кремлендә урнашкан «Эрмитаж – Казан» үзәгендә «Ибн Фадлан сәяхәте: Багдадтан Болгарга кадәр Идел юлы» дип аталган күргәзмә ачылды. Ул X йөзнең атаклы гарәп дипломаты Әхмәд ибне Фадланга багышланган. Күргәзмәнең тантаналы ачылышына Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Эрмитажы Михаил Пиотровский, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр шурасы рәисе шәех Равил Гайнетдин, Ирак Республикасының Россия Федерациясендәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Исмаил Шәфыйк Мөхсин һәм башкалар катнашты. Минтимер Шәймиев «Әхмәд ибне Фадланның Иделгә сәяхәте турында язмалар» китабының зур әһәмиятен ассызыклады. ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитеты Болгарны Бөтендөнья универсаль хәзинә буларак таныганда, әлеге язмалар әһәмиятле роль уйнады.





## МӘГАРИФ

Иннополис университетында мәктәп укучылары арасында математика буенча читтән торып оештырылган олимпиада туры башланды. Ул өч категориядә – 9, 10, 11 нче сыйныф укучылары арасында үткәрелә. Онлайн-тест барышында конкурсантлар 10 мәсьәлә чишә. Укучыларның математика буенча ачык олимпиадасы Россия Федерациясенең иң яшь шәһәрендә уза. Инновацион технологияләр өлкәсендәге иң яхшы белгечләр дә беренче чиратта — көчле математиклар.

Татарстанда урта һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар арасында «Без бәхетле буын-2016» үзешчәннәр фестиваленең зона этаплары бара. Анда республика көллият һәм техникумнарында укучы 2 меңнән артык студент катнаша. Тәтеш, Арча, Әтнә, Апас, Яшел Үзән, Чүпрәле, Буа яшьләре үзләренең зур әзерлеген күрсәтте инде.

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

**Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районы Мәдәният йортында «Уңганбикә» талант һәм матурлык бәйгесе узды. Бәйгене оештыручылар — Әсәкәй районы мәдәният бүлеге һәм «Сөембикә» журналы. «Авыл кызы» Бөтенроссия татар милли конкурсыннан үсеп чыккан әлеге бәйгедә районның иң булган 10 хатын-кызы ярышты (тулысынча «Сөембикә» журналы сайтыннан укый аласыз).**



PRESSA.RU






Үткəнен белмəгəн халыкның киләчәге юк. Халкыбыз тарихында, узган юлында сизелерлек эз калдырган шәхесләр хакында күбрәк белергә, аларның яшәү рәвешен, идеалларын аңларга тырышуыбыз табигый. Игелекле гамәлләр кылган, милләт, халык мәнфәгатьләрен алга куеп фидакарьләрчә көрәшкән бөек затлар онытылмый, соклану, горурлану уята. Уйландыра, игелекле гамәлләр кылырга рухландыра. Әйтик, кемнәр соң алар Акчуриннар, дигән сорау бүген күпләрне гаҗәпләндерми инде. Төрки-татар мәдәнияте тарихында эшкуар Акчуриннар калдырган эз тиз генә җуелырлык түгел. Төрки-татар дөньясында беренче хатын-кыз рәссам Хәдичә Акчурина, беренче хатын-кыз археолог Зөләйха Акчурина, тарихка татарлардан беренче хатын-кыз журналист буларак кереп калган Зөһрә Акчурина исемнәре һәм эш-гамәлләре күпләргә билгеле.

Наил ТАИРОВ, тарих фәннәре докторы, Казан мәдәният һәм сәнгать институты профессоры.
Илһам ТАИРОВ, төбәкне өйрәнүче.

# «УРТАДАН ЮЛ БИР ХАТЫННАРГА!»

### *Визит карточкалары*

Элеккеге Сембер губернасы, хәзерге Ульяновск өлкәсендәге Гурьевка авылында әтисе Абдулла Сафа улы эзеннән сәүдә белән шөгыльләнә башлаган Курамша Акчурин йон аялау, юып сатуның төшемле эш икәнен абайлап ала. Постау мануфактурасына йон китереп тору белән баеган Курамша Акчурин 1826 елда алпавыт Д. Кротков нигез салган постау фабрикасын 1868 елда сатып ала. Алга карап эш итә торган зирәк, эшчән крестьян улы гаять зур тырышлык, көч куеп предприятиене киңәйтә. Күп тә үтми, егәрле, эшчән, булдыклы Акчуриннар тырышлыгы белән «бала» фабрикалар барлыкка килә. Курамша (ихтимал, Хөрамшаһ) башлаган үрчемле эшне дәвам итү аның уллары – Тимербулат, Әсфәндияр, Исмәгыйль һәм Ибраһимга мирас булып кала. Уңганлыгы, сәләте, зирәклеге белән аерылып торган Тимербулатны – Тимай байны туганнары башлык итеп таный. Хәер, энеләре дә олы агаларыннан калышмый. Коромысловка авылында постау фабрикалары тоткан бай сәүдәгәр Әсфәндияр Курамша улының кызы

Зөһрә Акчурина яшьтән үк каләм тибрәтә башлый. Кырымлы Исмәгыйль Гаспринскийга кияүгә чыккач та каләм чарлавын дәвам итә. Ире белән берлектә Кырымда «Тәрҗеман» газетасын иҗат итүгә тирән белемле ханым күп көч кертә. Шунысы аеруча куанычлы, сәүдәгәр Акчуриннар эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, Россия хөкүмәтен яхшы сыйфатлы постау белән тәэмин итү белән бергә милләт мәнфәгатьләрен дә истән чыгармаска тырыша, хәйрия эшенә – меценатлыкка гаять зур игътибар бирәләр.

Сембер фабрикантлары Акчуриннар үз хисапларына уку йортлары төзегәннәр. Мәчет-мәдрәсәләр салдырганнар. Рус һәм татар телендә китаплар бастырып чыгарганнар. Китапка, басма сүзгә хөрмәт, күрәсең, аларның канында булгандыр. Төрле җирләрдән китаплар китертәләр, газета-журналлар яздырып алдыралар. Бай китапханәләр туплыйлар. Китапханә киштәләрендә рус, татар, шәрык һәм көнбатыш язучыларының кызыклы әсәрләре урын ала. Туган тел язмышына битараф булмаган алар. Татар әдәбиятын, үсешен даими күзәтеп торганнар. Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый әсәрләрен үзләрендә булдырганнар. Күпсанлы нәсел-нәсәп арасында әдәбият белән кызыксынучы, язу эше белән мавыгучылар да булган. Аралашып, фикерләшеп яшәргә омтылганнар.

Фабрикантларның күп тармаклы нәсел-нәсәбенең күбесе үзләренең визит карточкаларын – исем-фамилияләре, атасының исеме, профессиясе, адресы язылган кечерәк калын кәгазь булдырган. Визиткаларның кайберләре әлегә кадәр сакланган. Курамша улы Исмәгыйль (Исмаил) Акчуриннар гаиләсендә берничә төрле визитка кулланышта йөргән. Ә бәлки бу гаиләгә караганнары күбрәк саклангандыр һәм безнең көннәргә килеп җиткәндер, кем белә... Гаилә башлыгы Исмәгыйль әфәнденең берничә вариациядә ясалган визиткалары бар. Ике ягына да: «Исмаилъ Курамшевичъ Акчуринъ» дип басылганнарын да, татарчасын да, рус телендәгеләрен дә күрәбез. Татарча дигәнебез ул чактагы гарәп графикасында язылган визиткалар. Хәер, латин шрифтындагылары да очрый. Әйтик, «Ismail Aktchourine» вариантын очратабыз. Җәмәгате Гайнелхәят Габдрәшит кызыныкы – «Айнельхаят Абдряшитовна Акчурина» дип язылганы белән дә танышабыз. Хуҗа үзе дә, хуҗабикә ханым да визит карточкалары булдыруны кирәкле эш санаган, димәк. Бу мавыгу, күрәсең, аларның балаларына да йоккан. Кызлары Мәрьямнең (шул исәптән кияүгә чыкканнан соң алган фамилиясен дә кертеп «Марьям Исмаиловна Акчурина-Агеева» дип язылганнарын да, Исмәгыйль кызлары Асия, Зөһрә, Фатыйма, Зөләйха, Зөбәйдә исемнәренә тутырылганнары да кулланышта булган. «Саламандра» сәүдә ширкәтендә страховой агент булып эшләгән Йосыф Исмәгыйль улының визиткасы исә «Уосиф Исмаиловичъ Акчуринъ» дип тутырылган.

Ни кызганыч, әлегә иң эре сәүдәгәр һәм фабрикант Тимербулат Курамша улы Акчуринның һәм балаларының визиткалары табылмады. Һичшиксез, алар булган. Ихтимал, шәһәрләрдә яшәүче Акчуриннар визиткалар булдыруга һәм алардан куллануга зуррак әһәмият биргәннәрдер. Хәер, калаларда тамыр җибәргәннәре дә авылларны онытып бетермәгән. Акчуриннарның күбесе авылда да, калада да йортлар салганнар. Сембер губернасындагы авылларда, Сембернең һәм Сызраньның үзендә аларның зур, матур йортлары булган. Әлбәттә, калада яшәгән Акчуриннарның балалары күпкырлы белем алу өстенә, башка милләт мәдәниятен дә якын иткән, руслар белән күбрәк аралашкан.

*Бу нәселдән чыккан хатын-кызларның да заманында ирләрдән калышмыйча олы эшләр майтарырга омтылуы аеруча сөендерә.*

Визиткалар белән мавыгу юктан гына түгел, әлбәттә. Сәүдәгәрләрнең генә түгел, хатыннарының, балаларының да тора-бара аралашу даирәсе киңәйгән. Сәүдә өлкәсендә эшләүчеләр белән генә түгел, татар зыялылары, укымышлылары, галимнәр, мөгаллимнәр белән дә бик теләп, якыннан аралашканнар. Шулай ук фабрика зыялылары, хезмәткәрләр, приказчиклар арасында да дуслары, якыннары шактый булган. Укытучымөгаллимнәр, табиблар, фабрика клубында эшләүче сәнгатькә якын кешеләр, театр һәвәскәрләре, билгеле инде, Акчуриннар белән дуслашу, аралашуны хуп күргәннәр. Акчуриннарның аралашу даирәсен күзаллау өчен сакланып калган визиткаларның әһәмияте аз түгел. Тимербулат Акчурин варисларында хезмәт иткән Гафарова ханымның визиткасы кулдан язылган булса да, әһәмияткә ия. «Хәдичә Бакировна Гафарова. Гурьевка, Барыш ст. М.-К. ж.д.» дип укыйбыз.

Визит карточкалары фабрикантларның һәм аларның балаларының мәдәни карашлары күпкырлы икәнен дәлилли. Димәк, XX гасырның башында – унынчы елларда ук Россия бизнесына саллы өлеш кертергә өлгергән алдынгы карашлы татар эшмәкәрләре заман белән бергә атлаган, дөньядагы яңалыклар белән танышып торган.

## *Туры Тукай*

Тукайның Сембер ягында – Акчуриннарда кунак булуы хакмы, дип шикләнүчеләр аз түгел. Хак булса, данлыклы татар байларының ни эш-шөгыльләре, ни тормыш-көнкүрешләре хакында ник бер-ике авыз сүз, бер кәлимә шигырьме, истәлек-фәләнме язып калдырмаган? Казанга килүен, авылга кайтуын, күңеленә яткан-ятмаган очрашулар, аралашу-көрешүләре хакында тәфсилләп сурәтләргә иренмәгән шагыйрьнең данлыклы татар байлары хакында бер ни әйтмәве, ә бәлки сүз әйтергә кирәксенмәве гаҗәп түгелме? Без бит шул чорны – замана зыялыларын, Ямашевларын, Карәхмәтләрен, Ишми ишаннары белән бергә, туры Тукайның үткен, күп чакта аяусыз каләме аша күзаллыйбыз.

PRESSA.RU



XX гасыр башында постау фабрикалары әкренләп Тимербулат – Тимай бай уллары Хәсән, Якуб һәм Абдуллага күчә. Хәсән Акчурин – русча, татарча укый торган, мәгълүматлы, алдынгы карашлы ир – милли мәдәният белән дә кызыксына. Мәдәниятне күтәрүгә акчалата ярдәм дә күрсәткәли. Шөһрәтле яшь шагыйрь Тукаевны чакыру уе нинди ният белән башына килгәндер, ул кадәресе безгә караңгы. Чакыруны җиткерүне үтенеп, ул Казанның зур сәүдәгәре һәм җир хуҗасы Бәдретдин Апанаевка хат юллый, юл чыгымнары өчен акча да сала. Усал телле шагыйрьнең үзен бигүк өнәп бетермәгәнен белгән Апанаев исә шагыйрьнең үзенә түгел, Фатих Әмирханга мөрәҗәгать итә. Тукайны күндерүне әдипкә йөкли. Бу даирәне дә күреп кайтсын, тәэсирләре артсын, диптер, дусты аны кунакка барырга үгетли.

## *Акчуриннарда шагыйрьнең бер атнага якын торганы мәгълүм.*

Сүз Галиәсгар Камалга: «Тукайның Казаннан икенче чыгуы аның Сембер губернасындагы Акчуриннарга кунакка баруы була. Фабрикант Хәсән Акчурин, мөселманча зур укымышлы кешеләрдән саналып, яңа әдәбиятны да сөючеләрдән булганга, Тукайның шигырьләрен укый һәм аның үзен дә күрәсе килә. Казандагы дусларына Тукайны кунакка җибәрүләрен сорап хат яза һәм акча да җибәрә. Алар, Тукайның үзенә акча мәсьәләсен белдермичә, аны барырга күндереп, баштанаяк киендереп озаталар. Тукай зур кунак булып кайта.

«Тукайның кайтканын ишеткәч, мин аның янына менәм, ни күзем белән күрим, өстеннән яхшы киемнәрен, ак якаларын салып ыргыткан да эчке күлмәктән генә караватына сузылып яткан. «Нихәл, бик шәп йөреп кайттыңмы, бик шәп сыйладыларммы?» – дигән сорауга каршы, Тукай: «Сыйлавын шартлаганчы сыйладылар, шулай да үземнең караватымны сагынып кайттым әле, безгә кул кешеләр түгел алар, әллә ничә горничный нәнкә шикелле ашаталар, нәнкә шикелле эчертәләр, нәнкә шикелле йоклаталар, үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк. Сыйлары да гел коньяк та шампанский, безнең шикелле кара корсакка кул нәрсәләрмени алар», – диде, ник барганына үкенгән көнгә төшкәнлеген белдерде». (Г. Камал. Әсәрләр, 3 т., 325 б.)

Бу чорда Хәсән бай җәмгыятьнең директоры – җаваплы оештыручы саналса да, исәнлеге какшау сәбәпле, җитәкчелектән читкәрәк китеп, эшне энесе Якубка тапшырган була. Акчуриннарның уртанчы уллары Якуб, әти-әнисен хафага салып, күрше Силаевка авылыннан фабрикага килеп эшләүче Васена атлы рус кызы белән якынаеп китә. 1899 елда аларның беренче кызлары Александра, аннан Клавдия, Владимир, Георгий, Елизавета һәм Виктор туа. Акчуриннар эшенең чишмә башында торган Тимербулат Абдулла улы өчен бу чын фаҗига була. Катгый каршы килүенә, үзе исән чакта киленне бусагага аяк бастырмаска ант итүенә карамастан, яшьләр үзләренчә яши. Ахырда, улын яратумы, капиталны бүлгәләргә теләмәүме – атаның фикерен нидер үзгәртә, Якуб гаиләсенә ике катлы йорт өлгертә. Тимербулат Акчурин үлгәч, 1910 елның 7 июнендә Якуб белән Василиса Сембер чиркәвендә христиан йоласы буенча никахлаша. Мөселман Якуб Тимербулат улы Акчурин – өйләнмәгән егет; Василиса Семеновна Рождествина – христиан динендәге девица, ә никахка кадәр туган балалар исә христиан динендә тәрбияләнәчәк дип теркәлә документта.

Акчуриннар мәдрәсәсендә хәлфә булып торган Кыяметдин Кадыйри истәлегеннән күренгәнчә, поезд килеп туктаганчы ук шагыйрьне каршыларга өч чакрым ераклыктагы Барыш станциясенә, туганнарын ияртеп, Хәсән Акчурин ике тройка белән үзе килә. Кайткач, кунакны зурлап биек таш йортның иң якты бүлмәсенә урнаштыралар. Кичен китапханә бүлмәсендә шагыйрь хөрмәтенә зур мәҗлес уза.

Хәсән байның энеләре, сеңелләре, фабриканың дәрәҗәле затлары, Гурьевка зыялылары киенеп-ясанып табын тирәли тезелешеп утыра. Һәм, әлбәттә, Казан кунагыннан хикмәтле сүз көтә. Әмма шагыйрь, ни сәбәпледер, ачылып китми. Хуҗаларның сорауларына кыскакыска җаваплар белән чикләнә. Күпме сорасалар да, шигырь укудан да баш тарта. Кыям хәлфәне гаҗәпкә калдырган хәл – кунакның йомыклыгы Акчуриннарны өнәмәвеннән генә түгелдер... Читләр алдында ачылып китә алмавы, ихтимал, аның оялчанлыгы белән бәйледер. Сул күзенә сизелер-сизелмәс ак төшкән булуы да, хатын-кыздан уттан курыккандай курка торган шикчеллеге дә моңа сәбәп булырга мөмкин. Галиәсгар Камал Габдулла дустын ничә тапкыр өенә чакырып караса да, аның баш тартуын: «Анда бит синең хатын, балалар... Бик сыйлыйсың килсә, берәр кәтлит китерт тә, сыйла инде», – диюен искәртә ич. Ә Фатих Әмирхан истәлекләреннән күренгәнчә, ул табигате белән йомыкый: «Тукай хатын-кыздан кача иде. Ул идарәханәгә кереп чыга торган хатын-кызларның сәтрәдән (пәрдәдән) азат, зыялы хатын-кыз икәнен белә торып та, алар бар вакытта идарәханәгә керми генә түгел, хәтта ул барында алардан берәрсе килеп керсә, ул ашыгып чыгып китә иде. Көннәрнең берендә ул, миңа йомышы булганлыктан, идарәханәгә өч мәртәбә килеп, өч мәртәбәсендә дә, очраклы рәвештә хатын-кыз булганлыктан, өч мәртәбәсендә дә минем янга керергә теләмичә киткән. Икенче көнне шул вакыйганы сөйләп, мине бераз ачуланып алды:

– Хатын-кыз белән ни сөйләп утырмак кирәк? Көненә өч мәртәбә сәгатьләп-сәгатьләп ма ля сөйләп утырудан ничек туймаска кирәк?

– Ник нәкъ менә ма ля, ягъни мәгънәсез, кирәксез сүз?

– Хатын-кыз булган җирдә башка сүз сөйләнми...»

Моңа карап, Тукай хатын-кыз затына нәфрәт саклаган икән, дип ялгыш нәтиҗә ясый күрмә, укучым. Аның хатын-кыз галәмен кузгатырга теләп язган шигырьләре үз бурычын үтәде, иң әүвәл нәкъ менә

хатын-кыз шагыйрәләр: «Тукай хәкыйкый халык шагыйре» дип таныды.

Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатынларга,
Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төнләргә
Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатынларга!
Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга!

Фабрикант белән икәүдән-икәү калганда алар ниләр хакында сөйләшкән, ниләргә игътибар иткән, болары мәгълүм түгел. Кыям хәлфә истәлекләреннән аның шар тәгәрәткәне, ягъни икәүләп бильярд уйнаганнары, шагыйрьнең фабрикага кереп йөргәне билгеле. Әлбәттә, гади эшчеләрнең авыр тормышы аның күз уңыннан читтә калмагандыр. Бу чорда иҗат иткән, татар прозасы үсешенә үзенчәлекле өлеш керткән Мәхбүбҗамал Акчуринаның хикәяләре Тукай игътибарына ирешкәнме-юкмы, без моны белмибез. Әдибәнең фабрикант Акчуриннарга кардәш тиешлеме-түгелме икәне дә ачыкланмаган. Әмма әдибәнең каләме татар үткән авыр язмышны сурәтләве белән кызыклы. 1910 елда язылган «Хаммал Ягъкуб» хикәясе Сембер артындагы авылдан шәһәргә фабрикага эш эзләп килгән ирнең кярханәгә йөкче булып яллануын тасвирлый. Эш авыр булса да, әзрәк акча эшләп ат аласын, иген игәсен уйлап, тырышып эшләп йөргәндә үзе кебек йөк ташучылар магарыч сорап аңа бәйләнә. Эчми торган авыл кешесен төрлечә мыскыллап, «сыйларга» күндерәләр. Әмма юмартланып трактирда типтерүнең соңы фаҗигале тәмамлана: аякларын өшетеп, авырып яткан иргә чиләнеп тапкан акчасының да әҗерен күрү насыйп булмый. «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә» дип аталган, тормыштан алынган хикәясе исә автор бала чагында күргән фаҗигале вакыйганы тасвирлый. Иске гореф-гадәтләргә, ырымнарга ышануның бар авырлыгы болай да хокуклары чикләнгән хатыннар иңенә төшә. Май уртасында кырау төшеп, игеннәр зыян күрә. Мәчет янына җыелган картлар моның кәсафәтен ураза тотмаган хатыннардан күрә. Дүрт балалы хатынның көндез чәй эчкәнен ире – атасы малын сарыф итеп, гаиләсен хәерчелеккә дучар иткән ялкау Камал фаш итәргә тотына. Бишенчегә йөкле булып, шуннан котылырга азапланган авыру Хәбибҗамалны мич башыннан сөйрәп төшерәләр. Исмай углы белән икесенең кулларын бәйләп, кыйнап, битләренә корым ягып урам әйләндерәләр. Бу темага совет чорында М. Гали («Яңгырсыз елларда», 1921 ел), М. Гафури («Кара йөзләр», 1926), Н. Исәнбәт «Миркәй белән Айсылу», 1931) язды. М. Акчурина хикәясе 1914 елда бу теманы башлап күтәрүе һәм реалистик чишелеше белән әһәмиятле. Уңай герой буларак тәкъдим ителгән абыстайның да бу хәлгә төшүнең сәбәбен мескинә хатынның үзеннән эзләве гаҗәп: «Атаң-анаң яхшы кешеләр иде. Ләкин сезнең авыл кызларының әхлакына андагы фабрикалардагы тәрбиянең күп яман тәэсире булган», – ди ул Хәбибҗамалга. «Мин, абыстай, аслан фабрикада хезмәт итмәдем. Үзегез дә беләсез, атам яхшы тормышлы иде». «Анда хезмәт итмәсәң дә, синең тиңдәш, кордаш кызларың шул фабрикаларда хезмәт итеп, җомга көнләрдә генә өйгә кайта иделәр, син шулар илә бергә кунып, андагы тормыш хикәяләрен тыңладың. Йөреш-торышта анларча булырга үгрәндең. Бәхетсезлегеңә, ярты гакыллы Камалга тугъры килдең. Синең кебек көяз хатынга җебегән, юкә ир тиң түгеллекне инкяр итеп булмый». Җәберләнгән хатынның, үзен хаксызга мәсхәрә иттергән, ерткычларча кыйнаган иреннән аерылуны сорап, мулла ишеге төбенә кат-кат баруын әдибә ачынып хикәя итә. Талак хатына марка өчен ире акча бирмәгәч, хатын кулындагы беләзеген салып: «Анамнан калган сагынмалык иде, хезмәт иткәч, йолып алырмын, кайсыгыз булса шуңарга бер сум акча бирә торыгыз!» – дип үтенгәч, шаһитлардан берәве бер сум акча чыгарып бирде».

*Хәер, Тукайның эшчеләрнең авыр тормышын чагылдырган «Кярханәдә» шигыре Акчуриннар фабрикасында булу тәэсирендә туфы да ихтимал.*

«Тукайның фабрикантларны мактап язмавы хак. Хурламаган да. Ул алардан начар кәеф белән кайтмаган, – ди гомерен фабрикантларның игелекле эшләрен, нәсел-нәсәбен өйрәнүгә багышлаган галим, үзе дә Акчуриннар якташы Наил Измаил улы Таиров. – Әйе, алар безнең иш түгел, алар башка камырдан, дигән кебегрәк фикер белдергән ул. Киткән чакта – озатканда Акчуриннар аңа илле сум акча, кием тектерергә постау биргәннәр. Ни кызганыч, Тукайны кунак иткән ул йорт юк инде». (Туфан Миңнуллин «Без китәбез, сез каласыз...» дигән драма әсәрендә, бирергә теләсәләр дә, шагыйрьнең байлардан акча алмавын кистереп әйтә.)

«Ялт-Йолт» журналында бергә хезмәт иткән Әхмәт Урманчиев «һич бирәүгә тәрилкә тотмаган» Тукай тормышыннан бер эпизод китерә: «...татарлар арасында шау-шулар була башлагач, Россия татарларының иң атаклы фабрикантларыннан берәү, шөбһәсез, байлыгына горурланып, үз фикерен чын дип санап, Тукайны Муса әфәндегә каршы корал булырга димләп, бер хат язды. Менә шул вакыт кечкенә гәүдәле, олы йөрәкле шагыйрь ни эшли? Ул хатны иртә белән алгач та укып ташлый да, аңа шул минутта ук җавап яза. Мине чакыртып, ул хатны укый. Бу җавап шулкадәр әче иде ки, шөбһәсез, алтыннарына мәгърур булган бай моны алгач, чын мөхәррирлек янында акчаның никадәр зәлил (кадерсез) булганын аңлагандыр. Бер тиенсез йөргән чакта бу кадәр олылыкны, шөбһәсез, чын мөхәррир булмаган кеше катгыян эшли алмас.»

Халык шагыйре Тукай гамәленә сокланудан кала тагын нинди хис белдереп була?!

Роза КАМАЛЕТДИНОВА әзерләде.

PRESSA.RU



2006 ЕЛНЫҢ КӨЗЕНДӘ АНЫ ХЬЮСТОН ОПЕРА ТЕАТРЫНА ЧАКЫРЫП АЛУЛАРЫ ЗУР ВАКЫЙГА БУЛДЫ.

**Дөнья операсы җырчысы булачак Альбина Шаһиморатова белән шунда таныштым мин.**

Марк ЗАЛЬЦБЕРГ

# АЛЬБИНА. ТЕХАС. БЕЛЬКАНТО...

Альбина Шаһиморатова... Россия һәм Татарстан горурлыгы, дөнья операсы йолдызы!.. Казанга сагындырып, тансыклап кына кайта да, тылсымлы тавышы белән сихерләп, илаһи бер дулкында тибрәтеп калдыра...

Быел Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивалендә Альбина Казан тамашачысын тәмам әсир итте. Ул сәхнәгә чыгуга, зал тынсыз калды. Чыгышы моңарчы күрелмәгәнчә аншлаг белән узды! Татар халык җыры «Сакмар су», беренче чәчәкләр, беренче алкышлар... Верди, Пуччини, Бизе, Чайковскийның тылсымлы музыкасы. Тамашачы аягүрә алкышлый, ә Альбина һаман образыннан чыга алмый: күзләрен йомып, тетрәнеп, акылдан шашкан Лючиянең драматизмын залга күчерә... Тормышындагы иң уңышлы чыгышларының берсе булгандыр ул кич!

...Тамашачыны, гадәттә, сәхнә арты да кызыксындыра. Безне сокландырган Альбина әле Нью-Йоркта, әле Венада, әле Миланда җырлый. Гаиләсе Мәскәүдә яши. Табиб, медицина фәннәре кандидаты ире Руслан белән алар Казанның Колшәриф мәчетендә никахлаша. Кызлары Аделинага 1 яшь тә 4 ай. Кызына исемне, мөгаен, Альбина үзе сайлагандыр. XIX гасырда яшәгән атаклы опера җырчысы, Джузеппе Вердиның яраткан вокалисты Аделина Патти да колоратур сопрано тавышка ия булган бит! Нәни Аделинага рәхәт: ике яктан да дәү әти, дәү әниләр алмашлап карый үзен. Альбинаның әнисе Мәскәүгә барып бәбине ун айга якын карашып кайткан. Аннары кодагые, Русланның әнисе Кадрия ханым бәләкәч белән утырган. «Аллага шөкер, үсте инде кызыбыз: тәпи дә китте, теле дә татарча ачылды, инде курчаклар белән уйный, – ди Равза ханым Шаһиморатова.

Сәхнә арты дигәннән... Альбина иҗатының башлангычы, аның Америка чоры шулай ук кызыклы. Яшь җырчының Хьюстон опера театрындагы тәрҗемәчесе Марк ЗАЛЬЦБЕРГ укучыга Альбина Шаһиморатова тормышының моңарчы таныш булмаган битләрен ача...

Эльмира ЗАКИРОВА

Мин җырчы да, музыкант та түгел, алай да Опера театрында күптән инде үз кеше. 1993 елда театрның ул чактагы директоры мистер Дэвид Гокли мине «Мадам Баттерфляй» операсында катнашу өчен Хьюстонга килгән ике рус җырчысына тылмачлык итәргә чакырды. Ул елларда Россия җырчылары инглизчә сөйләшмиләр иде әле. Ә Хьюстонда мине синхрон тәрҗемәче һәм инженер-физик буларак кына түгел, бәлки опера һәм музыкага мөкиббән кеше итеп тә беләләр.

Дус-ишләрне җыеп, өебездә музыкаль кичәләр оештырабыз, концерт, операларның видеоязмаларын карыйбыз. Язмалар меңләгән, балачактан ук операны, классик музыканы яратып үстем. Дөнья мәдәнияте бишеге булган Ленинградта туган кеше өчен бу бер дә гаҗәп түгел.

Театр, гадәттә, рус җырчыларына филолог-тәрҗемәче билгели иде. Чио-Чио-Сан партиясен җырларга килгән атаклы җырчы Галина Горчакова тәрҗемәчене ярты сәгать эчендә куып та чыгарган. Тәрҗемәче опера, музыка, театр турында бернәрсә дә белми, хәтта элементар терминологиядән дә хәбәрдар түгел икән! Шунда Гокли мине искә төшерә. Хьюстон университетының Космосны өйрәнү Үзәгендә фәнни хезмәткәр булып эшләгән чорым. Лабораториядән опера театрына автомобильдә ун минут чамасы гына барасы.

Кичен театрга килеп, җырчылар, режиссер, дирижер белән таныштым, репетиция башланды. Спектакльдәге персонажларның исемнәрен белергә, музыка жанрына караган сүзләрне дөрес кулланырга кирәк иде. Күпчелек музыка терминнары итальянчадан, халыкара телләрдән булганга, профессиональ җырчы йә музыкантка болай да аңлашыла анысы. Әмма аларны белмәгән тәрҗемәченең эше харап: режиссерга йә дирижерга карап, аптырау хәлендә төртелә дә кала! Безнең тәрҗемәче дә композиторларның ни исемен, ни операларын белми иде.

Ә мин ул яктан әзерлекле, шуңа күрә репетиция уңышлы узды, бар да канәгать калды. Хьюстон Гранд Операдагы волонтерлык хезмәтем әнә шулай башланды һәм 20 елдан артыкка сузылды.

...Хьюстон Гранд Операның опера студиясенә ул беркемгә билгесез җырчы булып килде. Тыйнак, студентларча артык гади киенгән яшь кызга әллә ни исем китмәде. Инглизчә бер сүз дә белми. Мин Студия директоры белән Альбинаның әңгәмәсен тәрҗемә иттем.

Аннары аны театр әзерләп куйган фатирына озата бардым, Америка кухня җиһазлары үзенчәлекләре белән таныштырдым.

Стажерлар өчен дәресләр күп вакыт кичләрен уза, мин дә студия хезмәткәре сыйфатында йөрим. Миңа кызык, чөнки театрны яратам, СССРда яшәгәндә дә (1979 елда гаиләбез белән Америкага күчтек – *авт.*) актерлар, җырчылар белән дуслыгым аркасында күп вакытымны театрда репетицияләрдә үткәрдем.

Альбина беренче күрүдә йомыкый, уйчан, аз сүзле, бер дә елмаймый торган кебек тоелды. Аңлашыла да инде, ул бит чит илдә, телне белми, ни дуслары, ни туганнары юк. Оештыру эшләренә кагылышлы сөйләшүләрдән гайре, Альбина мине кызыксындырмый иде. Ләкин концертмейстер Питер Пасторның беренче дәресеннән соң ук аңа башкача карый башладым.

Питер кыздан берәр әсәрне җырлап күрсәтүен үтенде. Альбина Римсий-Корсаковның «Салтан патша турында әкият»еннән патша кызы Аккош ариясен башкарырга булды. Һәм шуның белән ул безне таң калдырды. Сирәк очрый торган матур һәм көчле тавыш!

Патша кызы Аккош югары колоратур сопрано өчен язылган, башкару өчен техник яктан ярыйсы ук катлаулы. Төсләр, кайчак хәтта температура аналогияләрен кулланмый гына җырчы тавышын тасвирлау җиңел түгел. Җылы тавыш, бәллүр тавыш, тавышның ачык яки тонык тембрлары дигән гыйбарәләр укучыга, бәлки, таныштыр. Алтын тавыш, металл, көмеш тавыш дигәннәрен дә ишеткәләгәннәрдер. Күптән урнашкан эпитетлар ярдәмендә дә әле җырчының тавышын төгәл тасвирлап бирү кыен, ә аның җаннарга, хисләребезгә ничек тәэсир иткәнен аңлату тагын да авыррак. Техник яктан башкару осталыгын латин яки итальян теленнән кергән махсус музыкаль терминнардан башка аңлатып та булмый әле. Чиста, матур тавышны җиткерү өчен нота текстларына иярү генә җитми, башкаручының музыкальлеге, культура дәрәҗәсе, зәвыгы да бик мөһим.

*Альбина тавышын ишетеп, гаҗәпләнү катыш канәгатьлек белән карашып алдык.*

Кабат Альбинага әйләнеп кайтыйк әле. Студиядәге беренче дәресендә Альбина тагын Моцартның «Тылсымлы флейта»сында Төн патшабикәсе ариясен дә җырлады. Колоратур сопрано репертуарында бу ария иң катлаулылардан санала. Аны бернинди көчәнүләрсез, иң мөһиме: матур һәм дөрес итеп җырлаучылар аз. Анда югары октавадагы ноталар шактый, ә ария үзе бик тиз темпларда башкарыла. Альбина арияне искиткеч итеп җырлады. «Студиягә талантлы һәм киләчәктә әле танылачак җырчы килде, аның белән эшләү җиңел һәм рәхәт булачак», – диде Питер дәрестән соң. Мин Альбинаны игътибар белән күзәтә башладым. Студиядәге даими дәресләр вокал өйрәнүгә генә кайтып калмый иде, әлбәттә. Анда телләр, барыннан да бигрәк итальян телен, операны һәм музыканы өйрәнәләр, Гранд Операда куелачак операларда зур булмаган рольләр әзерлиләр, музыка яратучы бай меценатларның өйләрендә һәм концерт залларында чыгышлар ясыйлар. Атаклы режиссерлар, җырчылар, опера режиссерлары һәрвакыт мастер-класслар үткәрә. Альбина студиядәгеләрдән тавышының матурлыгы белән генә түгел, башка-башка яклары белән дә аерылып тора. Тавышындагы кечкенә генә төгәлсезлек өчен дә үзен гафу итә алмый, бер үк пассажны яки җөмләне кат-кат кабатлый. Альбинаның клавирны гына түгел, партитураны да иркен укуы

PRESSA.RU





■ Альбина әнисе Равза ханым белән Зальцбергларда кунакта.

ачыкланды, рояль артына утырып, үз вокаль партиясеннән теләсә кайсы урынны уйный ала. Фатирында инструментлар юк иде, мин аңа безнең өйдә Ленинградтан киткәндә үзебез белән алган пианинода уйнарга тәкъдим иттем. Альбинаның безгә килүләрен, җырлауларын хатыным белән күтәреп ала идек. Үзе уйнап җырлый, сәгатьләр буе безнең коллекциядәге музыкаль язмаларны тыңлый, театр һәм музыкага кагылышлы китапларны укырга алып тора. Аның белән тәмам дуслашып киттек, безнең өйдә ул тәмам үз кеше иде инде. Бу яшь кызның эшкә сәләтенә дә шаккаттык. Үз партияләрен, күпсанлы романсларны һәм җырларны кәгазь битеннән үк хәтердә калдыру сәләте бар иде аңарда. Вокал техникасы шулкадәр югары дәрәҗәдә – студиядә шөгыльләнү кирәк тә түгел иде Альбинага. Әмма ул мастер-классларда күп нәрсәләр белде. Аеруча үзе турында.

## Тәүлегенә 10-12 шәр сәгать шөгыльләнә ул!

Атаклы опера җырчысы, меццо-сопрано Ева Пудель мастер-классында менә мондый хәл булды. Остаз Альбинаның мөмкинлекләрен шундук чамалап алды һәм аны дәреснең башыннан ахырынача күз уңыннан һич ычкындырмады. Опера партияләреннән кыен өзекләр җырлауны таләп итте. Аз гына төгәлсезлек китсә дә, бәйләнде. Альбина, чак еламыйча, Евадан ни өчен бер аңа карата гына шундый «игътибар» күрсәтелүен сорады. «Син генә мин теләгәнчә җырлый аласың, шуңа синең таләпчән мин. Сине зур киләчәк көтә!» – диде Ева.

Күп еллар дәвамында Артуро Тосканининың дирижер-ассистенты булган мәшһүр итальян дирижеры Эдуардо Мюллер берчак репетициядә: «Альбина, тиздән син үз тавышың белән ни телисең шуны эшли алачаксың. Мин болай да мөмкин булмастайны таләп итәм инде, ә син барысын да башкарып чыгасың», – диде. Эдуардо миңа андый тавыш, талант һәм андый эшкә бирелгәнлек белән бик сирәк очрашырга туры килүен әйтте. Тиздән Альбинаны тыңларга дип АКШның башка театрларыннан импресарио һәм дирижерлар килә башлау да гаҗәп түгел. Студия артисткасы сыйфатында Альбина Хьюстон операсы спектакльләрендә җырлый башлады.

Озакламый Альбинага Яначекның «Хәйләкәр төлке» операсында җырларга туры килде. Ләкин ул күз яшьләре өчен дә сәбәп булды. Альбина бельканто тавышлы җырчы бит. Тавышына һәм вокал техникасына барыннан да бигрәк Беллини, Доницетти һәм Верди арияләре туры килә. Яначек исә Альбинаның да, минем дә ачуны китерә. Бу опера музыкаль гармония һәм опера стиле төшенчәләрен кире кагу рәвешендә язылган «яңа» опералар рәтеннән иде. Вердиныкы яисә Пуччининыкы кебек талантка ия булмаган белдекле композиторлар яңа юнәлештә иҗат итә башладылар. Аларга матур арияләр яки ансамбльләр кирәк түгел иде. Иң мөһиме – текст, шигъри булмаса, тагын да әйбәтрәк, ә музыка күбесенчә тавышлы. Бельканто, ягъни матур җырлау турында әйтә башласак инде, Яначекта җыр да, матурлык та юк. Концертмейстер Питер Пастор шундук Альбинаның кәефе юклыкны сизеп алды. Аның үзенә дә бу опера ошамый иде, ул җырчыны кызыксындыру юлларын уйлап табу чарасына кереште. Альбина бу партияне җырламыйм дип кырт кисүгә үк зур тавыш чыгар иде. Алай да Питер белән мин аны бу адымнан туктата алдык. Юкса аңа Студия белән хушлашырга ук туры килүе ихтимал иде. Партияне һич тә начар җырламады!

Еш кына шулай була: талантлы кешеләрнең башкалардан күзгә күренерлек өстенлеге хезмәттәшләренә дә, җитәкчелеккә дә ошамый. Альбинаны да читләп үтмәде бу нәрсә. Опера студиясенең яңа директоры – кайчандыр үзе дә уртакул җырчы булып йөргән өлкәнрәк хатын-кыз – зур талантларга сак карарга кирәген, аны башкалар белән тигезләргә ярамаганын аңламый.

Менә Студиядән бердәнбер Альбина Нью-Йоркка оча, Метрополитен Операда җыр тыңлатырга. Ә Студия бу вакытта Техас штатындагы провинция шәһәрчегендә концерт куясы икән. Альбинага анда нибары бер ария җырлыйсы. Студиядә артистлар җитәрлек анысы, Альбинадан башка гына да ерып чыгып буласы. Әмма җырчы «концертка кайтып җит!» дигән катгый боерык ала! Нью-Йорктан Хьюстонга чаклы ике меңгә якын километр, җитмәсә, әле бу кечкенә шәһәрчеккә Хьюстоннан очарга кирәк, турыдан-туры авиарейслар юк. Альбина моның өчен тулы бер көн китәсен, концерттан соң иртүк кабат Нью-Йоркка Метрополитен Операга кире кайтып җитәргә кирәген директорга аңлатып карый. Шундый җаваплы көнне талчыккан кыяфәттә бик үк уңышлы вокал формада булмам, дип хафалануын да җиткерә. Әмма аны Студиядән куу белән яныйлар! Тәки бу мәгънәсез авыр юлны үтәргә туры килә аңа. Арыган булуына да карамастан, искиткеч итеп җырлап күрсәтә.

Аны Метрополитен Операда да күреп алалар: Студияне тәмамлауга шунда эшли башлый.

Соңрак Альбина Хьюстон Гранд Операсында Моцартның «Тылсымлы флейта»сында Төн патшабикәсе партиясен җырлады. Һәм ничек кенә әле! Менә шунда инде ул үзен мәшһүр опера җырчысы итеп танытты!

Альбина, элеккечә, Студия артисткасы, аның вакыты һәм эше Студия карамагында иде. Альбина исә аларын бары үзе генә хәл итәргә тиешле дип исәпли. Һәм моңа бәйле күңелсезлекләр гел чыгып тора. Берчак Студия директоры: «Альбина кайда?» – дип, кич белән соң гына минем өйгә шалтыратты. Мөмкин кадәр итагатьле итеп, белмим дидем, Студиядә шөгыльләнер өчен хәзер вакыт шактый соң, ә Альбина бала түгел, үз вакытына үзе хуҗа икәнен аңлатырга тырыштым. Андый сөйләшүләр вакытында Альбина еш кына бездә пианино артында утыра һәм Студиядән качып кына Мәскәүдә 2007 елда узачак П. Чайковский исемендәге вокал җырчылар конкурсына әзерләнә иде. Җиңү яулап беренче урынга чыгуы гел көтелмәгән хәл булды. Хәтта музыкаль Россия, Мәскәү һәм без американнар өчен дә.

Без, ярты гомеребезне СССРда яшәгән кешеләр, беләбез, моның ише чаралар конкурсны оештыручылар һәм жюри әгъзаларының алдан килешенүеннән башка гына үтми. Ул хакта матбугаттан да укып белеп була: бу уңайдан җәнҗаллар гел чыгып тора. Оештыручыларның бөтен уй-теләкләре конкурста алдынгы урыннарны бары тик совет вокалистлары һәм музыкантлары гына алуга юнәлтелгән. Гаҗәеп тавышка ия һәм үзлегеннән мөстәкыйль рәвештә итальянча җырлау мәктәбен узган Альбинаның беренче урынга шанслары аз иде. Ул язмалар буенча һәм үз аккомпанементында өйрәнде.

Сагаюларыбыз тикмәгә генә булмаган! Альбинаның Россиядән киткәненә инде елдан артык иде бит. Аны инде онытканнар, ә исемле укытучылар һәм хакимият тарафыннан ярдәм күрсәтелеп торган конкурста катнашучы Россия җырчылары барысының күз уңында. Һәм менә Альбинаның феноменаль җиңүеннән соң ук кайсыдыр Мәскәү газетасыннан (исемен хәтерләмим инде) түбәндәгеләрне укыдым: «Алтын медаль башка Россия җырчысына билгеләнгән иде, әмма Шаһиморатованың өстенлеге ярылып ята: жюри аңа беренче урынны бирми булдыра алмады!»

Герой һәм җиңүче булып кайткан Альбинаны Студиядә триумф белән каршыламыйлар. Мин Америка артистлары мохитен яхшы беләм. Аларга Америка җырчысы түгел, Америка Студиясендәге рус җырчысының җиңү яулап кайтуы ошамады.

П. Чайковский исемендәге Халыкара конкурска мәшһүр импресарио Мэтью Эпстайн килгән иде. Моңарчы беркем белмәгән Альбина аңа шулкадәр ошады, чорыбызның мәшһүр дирижеры Альберто Мутига ул Альбинаны Австриягә Зальцбургта узачак опера фестивалендә җырларга чакырырга кушты.

Эпстайн әйтте – Мути үтәде! Һәм менә Хьюстон Гранд Операсының Опера студиясе артисткасы, П. Чайковский исемендәге конкурсның алтын медаль иясе Альбина Шаһиморатова 2008 елда Зальцбургта Моцартның Төн патшабикәсен зур уңыш белән башкарды. Ләкин Студия бу юлы да Альбинаның гаҗәеп уңышларын күрмәмешкә салыша.

Альбинаның Студиядә шөгыльләнүе эзсез калмый, әлбәттә. Аның белән Американың һәм Европаның күренекле опера белгечләре таныша. Талантлы җырчыны алар югары бәяли. Ике ел укыган Студиясен тәмамлатмыйча да аны Хьюстон, Чикаго һәм Сан-Франциско опера театрларына төп партияләрне җырларга чакыралар. Студия артисткасы чагында ук «Богема»дан Мюзетта партиясен искиткеч итеп башкара. Хьюстон аудиториясенә аның Төн патшабикәсе аеруча ошый. Бу рольдә Альбинага тиңнәр юк.


Шаһиморатованың Студиядәге тагын бер казанышы – инглиз теле. Баштарак бер авыз сүз инглизчә белмәгән кеше Студияне тәмамлаганда инде менә дигән итеп сөйләшә! Аеруча авазларны әйткәндә интонацион төгәллек чагыла. Ул бу телдә шундый итеп җырлый, Америкада берәү дә аны чит илнеке дип әйтмәс.

## *Җырчыны зур киләчәк көткәнен аңладым мин.*

Альбина турында халыкара дәрәҗәдәге җырчы гына дию аз. Ул инде Студиягә беренче килгәндәге оялчан кыз түгел. Шәп инглизчәсе, күлмәкләре, концерт киемнәре, сәхнәдә үз-үзен тотышы беренче класслы опера театрының югары таләпләренә бик тә туры килә. Ул чын мәгънәсендә үз дәрәҗәсен белгән һәм әйләнәтирәдәгеләрдән шуны аңлауны, шуның белән килешүне таләп итә алган Опера Йолдызына әйләнә.

Альбинаның кадере зур бүген. Нью-Йоркның Метрополитен Операсында йә Токио Операсында, Россия Зур театрында, дөньяның Милandaгы атаклы «La Scala»да – һәркайда аның кабатланмас тавышы яңгырый. Ул җырлап кына да калмый! Еш кына мин радио аша аның төрле илләрнең музыка журналистлары белән интервьюларын тыңлыйм. Кичәге тыйнак Мәскәү студенты Альбинабыз кем булды бит! Үз дәрәҗәсен белеп җавап бирүләре, сөйләшү рәвеше!.. Тавышыннан ук бик дәрәҗәле җырчы һәм артистка сөйләгәне аңлашыла! Бер тоннан икенчесенә күчә торган матур һәм бай тавыш, шәп дикция. Шундый сөйләшүләрен ишетеп алсам, бар эшемне ташлап, радиоалгыч янына ашыгам.

Күптән түгел Альбинаның: «Минем өчен иң мөһиме – тавышым һәм тавыш төсмерләрем аша геройларымның характерын ачу. Сәхнәдә сикергәләп, төрле мәгънәсез хәрәкәтләр ясап йөрүне яратмыйм! Иң кирәге – тавыш һәм җыр техникасы!» – дигәннәрен рәхәтләнеп тыңладым. Шундук аңлап алдым: даһи артист һәм җырчы, опера җыры кануннарын мәңгелеккә кертеп калдырган Федор Шаляпинның артистлык кыйбласы иде ул!



Язманы тулысы белән сайтыбызның «Мәдәният» сәхифәсендә укып була.

PRESSA.RU



Шигырьләрендә хыял, романтика, мәхәббәт, кызлар – ул матурлыкка табына!.. Сәях җаны диңгез-таулар, илләр-җирләр гизә – Париж, Луврларда, Мадрид, Лондоннарда була... Байрон, Гёте, Гарсиа Лоркалар ватанында алар белән шигырь телендә сөйләшә... Шәрыкның нечкә аһәңнәре шигъриятендә газәлләр, робагыйлар аша ачыла. Гомәр Хәйям, Хафиз, Нәваилар – остазлары. Күңеленә Җир шары, Галәм, Галактика сыйган. Ул – һич картаймас, ул – гашыйк, ул – талант!
Шагыйрь Рәдиф ГАТАШны гомер бәйрәме белән котлыйбыз!
Илһамлы иҗат телибез!



Рәдиф ГАТАШ

# ҖАВАБЫҢ КАЯ, КЫЗ БАЛА?

* * *

Янган йөрәк, сузылган кул –
Минеке.
Ике толым, кап-кара күз –
Синеке.
Егерме ике кояш эзе –
Минеке.
Уналты яз, гөлчәчәкләр –
Синеке.

...Ал йөрәгем! Бүгеннән ул
Синеке.
Синең йөрәк булсын ләкин
Минеке.
Ал кулларым! Нык, каты кул –
Синеке!
Язың, ямең синең булсын
Минеке.
Син ризамы? Юк, дисеңме?
Синең эш.
Сөймә мине, оныт! Дисең?
Синең эш!
...Тик оныту һәм онытмау –
Минем эш.

### *Студент хаты*

– Җавабың кая, Кыз бала?
Йөрәкнең янган чагы.
Сөюемне дә беләсең,
ни әйтим сиңа тагы?
Төн кебек кара чәчләрне
башкалар сөйсенмени?
Башкалар сөйсен, студент
янсын да көйсенмени?
Тыңламый каләм, «дәрес»ем
язылмый бүген, кала –
уйларым сине эзли тик,
Кыз бала, күзең кара!
Янганын хисле йөрәкнең
студент сөйли сиңа.
Карашың читкә алганны
студент сизми димә.
Табылган бит: борынгыдан:
«Студент – ярлы», – диләр.
«Мөлкәте – иске чемодан,
анысы да бармы?» – диләр.
Ташыган хисләргә бай мин,
күрмиләр – хыялга бай.
Бар дөнья – минем байлыгым,
киләчәк... барсы минеке! –
белмисең син дә, малай...

Таңнардан таңнарга кадәр
күрмәгәч, көтеп үзен,
студент хат язды янып,
сагынып кара күзен:
– Җавабың кая, Кыз бала?
Йөрәкнең янган чагы.
Сөюемне дә беләсең...
Үрелеп йолдыз тотыйммы?
Ни кирәк сиңа тагы?!

### *Кое*

Шыгырдап тора чыгыры,
Урамда зәңгәр кое.
Синдә – су алу, ә миндә
Бер күреп калу уе.
Зәңгәр кое – суы тулы,
Хис тулы минем күңел.
Чиләк тутырып алыр идең,
Ник күңел кое түгел?

Әйләнә чыгыр... Су ага,
Чиләгең тула инде.
Әллә түгимме суыңны,
Китми тор, тыңла инде!

...Зәңгәр кое яннарыннан
Синдә тик китү уе;
Минем сыман авыр сулап,
Шыгырдап кала кое.

### *Кыз җавабы*

И абый, ниләр әйтим соң,
Язасыз: зәңгәр кое,
Янәсе, кое янында
Мине очрату уе.
Шигырьләрегез дә әйбәт,
Сүзем юк аларына.
Ләкин мин сезгә тиңмени,
Мин әле бала гына...
Күземә сөрмә кунмаган,
Якмаган иннек, кызыл.
Мин әле ояла торган,
Кызара торган кызый.
Әнкәй бик шикләнә, абый,
Авылда сүзләр йөри.
Шуңа да мин сезнең белән
Сөйләшми йөрим юри...
И абый, кызык үзегез,
Әйтерсең бала минә...

Шигырьләрегез бик матур,
Сүзем юк аларына.
Кешегә ишеттергәнсез,
Шушымы егет эше?
Простой диләр сезне бик,
Катлырак булыр кеше.
Шулай да моңсу үземә,
Әлеге зәңгәр кое...
Күңелдә шул коега кич
Ешрак чыгу уе!

### *Чакыру*

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Югыйсә артык бушанды
Күңелнең урамнары.

Кайтыгыз, җилне-давылны
Тынычтан артык күргән,
Тын йортның ишеген ватып,
Урамга чыккан көннәр!

Кайтыгыз, йолдызлы төннәр,
Беркатлы өметләрем!
Кайтыгыз, кыш үскән гөлләр,
Йокысыз минутларым!

Кайтыгыз, былтыргы карлар,
Кайтыгыз, сезгә карыйм!
...Гөнаһсыз чакның карына
Гөнаһлы исемем языйм.

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Бушанды, артык бушанды
Хисемнең урамнары!

* * *

Сеңлем!
Толымнарың кисмә, яме?!
Мин, аларны күрсәм, һаман
тотынып, гүя балачакка кайтам:
озын чәчле су кызлары
төшкә керде балачактан.
Беләм, алар һаман да әле
озын чәчле!

Толымнарың кисмә!
Күпме истәлекләр яшерә алар:
анда миңа беренче оялчан
карашлар, анда
кояш үбүе, яңгыр биргән назлар,
безнең өчен генә килгән язлар.
Син аларны, зинһар,
еракка алып китмә,
толымнарыңны кисмә, яме?!
Кисмә!

* * *

Кызлар, быел һәммәгез ут чәчлеме?
Сары көнбагыш сез – кояш чәчтеме

Йөз-чәһрәгез тирәли ул төсләрне?
Яшьлек алтынымы
назлый күзләрне?

Ничәгезне мин, тик Аңа охшатып,
Күбәләктәй якын бардым, җан атып.

Ничә күлмәк иясен (аллы-гөлле!)
«Танып», утка очып килдем мин –
тиле...

Ялгыштым шул! Кызлар,
тере ялкын сез,
Гүя игезәктәй охшаш-матурсыз...

Алдансам да, ярыма әйтер сүзне,
Серне чишмәдем, –
саклады Хак сүзе...

Әмма бу яз хистә төсләр буталды.
Шуны беләм: Казанымны ут алды.

Гүя ялкын эченнән эзлим сине –
Алтын балкышны,
көнбагыш төслемне.

* * *

Кайт тагын да шигыремә
май кичендә, –
Вагыйфны яттан сөйләвең исемдә.
«Күпләрне оныттым бугай», –
дисең дә,
Яшисең син төрки моңнар өчен дә...
Кайт яңа шигыремә май кичендә!

Сагынып сине, ләләләр күз ача,
Казанда нәркисләр хәлеңне сораша.
Яшел яз! Йөрәкләр серләшә,
очрашса,
Карт күңел гөле дә үреләә кояшка.
Кайт, сине сагынган гөлләр күз ача...

Булса да уеңда диңгез, фонтаннар...
Ак шомыртлар илдә, түгел анарлар.
Саф татарча яңгырап, аһәңсазлар,
Гашыйк җырын сиңа
җиткерсен алар,
Ә Казанда сагыну хисен –
фонтаннар.

Килде чәчәк ату вакыты кешегә! –
Суытса да кинәт, күңел төшермә,
Кырау төшермә тик бәхет хисеңә!

Җилгә әйт, кагылса ут-чәчеңә,
Исен китерсен сагынган кешеңә!

Кайт Казанга – шигыремә! –
май кичендә,
Вагыйфка гашыйк итәрсең мине дә,
Йөрик шигъри ләләләр, моң эчендә,
Тугры булып төрки дөнья хисенә,
Казанымда – гаҗәеп май кичендә!

* * *

Сүзләрең – җыр, гел яңгырап барыр,
дим!
«Сагындым, бел... Сагынам.
Сагынырмын!» –

Шулар белән бүген минем җаныма
Ефәктән дә йомшак,
матур кагылдың.

Җыр сүзең, дим, гади һәм
бөек – анда
Борынгы һәм мәңгегә яшь
сабый моң!

Шул моң белән кавышкан
җанымны да
Бәхетле, дим, хәтта бөек
саныйм мин!

* * *

Төшеңә кердемме? Чынмы, сөеклем?
...Яшь җанда манзара
каян ул тиклем?

Анда хәтта диңгезләр дә сыйганмы?
Җан кылың минем халәтне
тойганмы?

«Йөрдең, дисең, борынгы ябынчадан,
Диңгез ярында –
Байронга охшаган...»

Кулым белән ымлаганмын аръякка,
Шунда дип белгәнгәдер Яр – еракта...

Төш – шигъри өн... Җанда күптән
давыл шул,
Синсез узган минутым да авыр шул.

Чынлыктан ул – хыял язган сурәтең...
Лаекмы мондый хөрмәткә,
йөрәк, син? –
Кадерен бел мәңге тансык
хис-йөкнең!

...Төшеңдә булса да ярат, сөеклем!

PRESSA.RU




Сәйдә ЗЫЯЛЫ

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе шагыйрә, язучы Сәйдә ЗЫЯЛЫның (Сәйдә Закир кызы Зыятдинова) иҗаты укучыларга узган гасырның 70 нче елларыннан ук таныш.
Ул хезмәт юлын журналист буларак башлый. Озак еллар «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли. Нәкъ менә шул чорда әдәби әсәрләр язарга керәшә. 1982 елда «Азат хатын» («Сөембикә») журналының ул чактагы баш мөхәррире Венера Ихсанова яшь язучыны редакциягә эшкә чакыра. «Кайнар сукмаклар», «Кар карасы», «Сыну», «Ике Әнисә бер Мәхмүт», «Хөкем», «Буранлы төн» хикәяләре нәкъ шул елларда иҗат ителә. «Ачылмаган бөре», «Югалту», «Кара таплы бизәк» бәяннары тупланган җыентыклары 2007 елда иң күп укылган китаплар исемлегенә керә.
Бүген Сәйдә апаның күзләре начар күрсә дә, ул һаман иҗат итә. Быелгы юбилеена да өр-яңа бәяннардан торган «Яралы кош авазы» исемле китабын әзерләде.
Без, «Сөембикә»леләр язучыны олы юбилее белән котлыйбыз, иҗат уңышлары телибез.



# ФӘНИЯ ТӘҮБӘСЕ

(Хикәя)

Төшке аштан соң урамда йөреп керергә гадәтләндем. Безнең эш бүлмәбез нәшриятның тугызынчы катында. Көндезге сәгать уннар җиткәндәрәк бүлмәбезгә авызын ерып кояш керә. Урам як дивар пыяладан гына тора диярлек. Колачын җәеп кояш югарырак күтәрелгән саен, бүлмәдә җылылык арта гына.

Бүлмәдә без өчәү. Түзеп-түзеп утырабыз да, бераздан беребез торып идәнгә су бөрки. Сулыш алулар җиңеләеп киткәндәй тоела. Әмма бу җиңеллек озакка бармый – бүлмә һавасы тагын элеккеге хәленә кайта. Аптырагач, тәрәзәне ачабыз. Бүлмә бераз җилләсен, сулышлар киңәйсен, янәсе. Юк, болай да тынычлап, рәхәтләнеп эшкә керешеп булмый. Шалтыр-шолтыр килеп узып торучы трамвайлар шавы, урамны иңләп агучы машиналар гөрелтесе колакларны тондыра. Бу тавыш баш миен бораулый, фикер тупларга комачаулый. Биредә иҗат кешеләре эшләячәге хакында уйлап та карамыйча, бары тик урам матурлыгын гына күздә тоткан архитекторларга күңел көн саен рәнҗи. Ярый әле төшке аш вакыты бар. Нәшрият тирәсендә яшь каеннар, серле миләшләр үсә. Алар күләгәсендә бераз хәл алырга мөмкин.

Җәйнең бер эссе көнендә, үз уйларыма чумып, агачлар күләгәсендә йөрим. Шулай йөргәндә илле яшьләр чамасындагы бер ханым туп-туры минем каршыма килеп басты да:

– Исәнмесез! – диде.

– Исәнмесез! – дидем, таныш түгел ханымның сәламен алып.

– Сез мине гафу итә күрегез, акыллым, – дип дәвам итте ул. – Мин менә өч-дүрт көн инде шушы тирәдә буталам.

– Нишләп? – дип сорап куйдым мин.

– Ничек дип әйтим икән, акыллым. Менә бу биек йортта язучылар эшли, диделәр.

– Ә-ә, – дидем, апаның ниятен үземчә аңлагандай.

– Шушында эшләүче берәр кешене очратмаммы дип йөрүем, акыллым! – Мин аның йөзенә текәлеп карадым. Ханымның тирән карашыннан, сөрмәләнеп торган күз төпләреннән сагыш

бөркелә сыман иде. – Сез монда эшлисез булыр. Миңа шулай тоелды, – дип дәвам итте ул.

– Әйе, – дидем мин, сүзне кыска тотарга тырышып. – Журнал редакциясендә.

– И-и, акыллым! – дип, ул беләгемә ике куллап ябышты. – Сез кирәк инде миңа! И-и, рәхмәтләр төшкере, сез кирәк! Сезгә сөйләр сүзем бар минем, зинһар, тыңлагыз!..

Аның шултиклем ихластан мөрәҗәгать итүенә каршы килерлек түгел иде. Без, читкәрәк китеп, ялгыз каен күләгәсенә утырдык.

– Исемегез ничек, апа? – дидем мин, сөйләшүне башлап.

– Фәния!

– Фән иясе, димәк, – дип шаяртып алдым.

– И-и, нинди фән иясе ди инде ул, акыллым? Көч-хәл белән этә-төртә җиде классны ерып чыктык инде. Яшь чакта тиле буласың бит. Укымыйсың... Укытучы өчен укыйсыңмыни!.. Аннары – төзелештә. Безнең заманда авылда паспорт бирмиләр ие. Әйе. Төзелеш эшенә паспортсыз да урнашып була. Менә шулай кала кешесе булдым инде.

– Минем исемем – Зөһрә, – дидем, танышуны дәвам итеп.

– Исемегез матур икән.

– Үземә ошый. Сез миңа нидер сөйләмәкче идегез, Фәния апа.

– Ә-ә. Әйе, акыллым. Үзем турында сөйләмәкче булам.

Апаның мондый сүзләре безнең өлкәдә эшләүчегә яңалык түгел. Гәзит-журнал редакцияләренә үзләренең тормыш юлын бәян итәргә килүчеләр җитәрлек.

– Тыңлыйм, апа!

– Бәхетсез булдым мин, – диде ул, тирән сулыш алып. – Үзем генә бәхетсез булсам, бер хәер иде... Башкаларны да бәхетсез иттем...

Фәния ханымның үз-үзен гаепләп сүз башлавы мине кызыксындырып җибәрде. Адәм баласына күп очракта гаепне башкалар өстенә ташлау хас бит. Ә ул иң элек үзен гаепли. Мин, сабырсызланып, сорап та куйдым:

– Ничек инде?

– Тыңлагыз, акыллым!

Фәния апа кара күзләрен әллә кая, еракка төбәде дә сөйли башлады. Ул чакта әле диктофоннар юк иде. Аның сүзләрен өлгергән кадәрле язып барырга кулымда кәгазем дә, каләмем дә юк. Бар ышаныч – хәтердә. Шуңа күрә апа сөйләгән һәр вакыйганы күз алдымда гәүдәләндерергә тырышам...

* * *

...Казан төзелеш идарәләренең берсендә эшли башлавына биш ай үтүгә, Октябрь бәйрәменә Фәния авылга шәһәрчә киенеп кайта. Аягына, халык теленә «прощай молодость» дип кергән кыска кунычлы, биек үкчәле киез башмак алып кия. Башына кечкенә яшел шәлен яба. Ничек итсә итә, акчасын кысып тота-тота, язгы-көзге пәлтә алуга да ирешә.

Кич җитүгә ясанып-төзәнеп, битенә иннек-кершән ягып, яңа киемнәрен киеп, ике өй аркылы гына яшәүче сыйныфташы Мәдинә янына керә. Аны ачык йөз, тәмле сүз белән зурлап каршы алалар. Мондый олы игътибар Фәнияне бераз каушатып та җибәрә. Мәдинәнең әтиәнисе янында гына болай каушамас та иде. Үзенең шәһәр тормышын бераз күпертебрәк тә сөйләр иде әле... Монда Шаһибулат авылыннан килгән кунак егет – Гыйльметдин аның зиһенен бутый. Фәниянең бу егетне элек тә күргәне бар иде. Ул чакта Фәния мәктәп укучысы гына иде шул. Гыйльметдиннең әнисе – Мәдинәнең әтисе белән бертуган. Мәдинә дә еш кына Шаһибулатка кунакка баргалый.

Гыйльметдин Казыбашка туганнарына килгән. Егет әле солдат киемнәрен дә салмаган. Иңендә сержант погоннары, түшендә матур-матур значоклар ялтырый. Коңгырт күзле, туры борынлы, киң маңгайлы, елмайган саен бит уртасы түгәрәкләнеп алучы «мәхәббәт чокырлы» егетнең киеме үзенә килешеп тора.

Гыйльметдинне күрүгә, Фәния әллә нишләп китә: тәне чымырдап ала, әйтер сүзләре юкка чыга, башы әйләнгәндәй була...

Алар өчәүләп клубка дип китәләр. Клубка килеп җитәрәк, кызлар уртасында барган Гыйльметдин, Фәниянең учын сизелер-сизелмәс кенә кысып ала да, Мәдинәгә болай ди:

– Без Фәния белән йөреп киләбез. Син үзең генә керә тор.

Фәния мондый ук бәхетне көтмәгән дә була. Егет кызны җитәкләп ала. Ул кичне аларга сүз кирәк тә булмый бугай. Егет, шинелен чишеп, кызны куенына ала. Өч ел буе кызлар җылысын хатлар аша гына тоеп яшәгән Гыйльметдиннең йөрәге күкрәк читлеген бәреп чыгардай булып дөпелди. Фәния, шул йөрәк тибешен тыңлый-тыңлый, рәхәт бер хис кичерә. Гыйльметдин, үзенең бар күзәнәгендә берьюлы кузгалган ләззәти давылның көч-куәтенә каршы тора алмый – кызның алсу иреннәренә үрелә... Күктәге йолдызларның күзләре гел аларда кебек. Аларга шундый рәхәт. Егет белән кыз сөялеп торган читән дә, шул читән өстенә кибәргә эленгән эт эчәгеле бәрәңге сабаклары да, бәрәңге сабакларыннан таралган үзенә генә хас әчкелтем ис тә мондагы мохиткә үзгә бер ямь өсти кебек. Дөнья тып-тын. Ике җанга бәхет дәрьясында тирбәлү өчен күп кирәкми шул.

Ике кич сизелмичә үтә дә китә. Фәния Казанга – эшенә юл тота. Гыйльметдин дә кунак булып озын-озак тормый. Казан белән Шаһибулат авылы арасында хатлар йөри башлый. Егет хатларны матур яза. Хатларын йә шигырь, йә җыр белән тәмамларга ярата. Бер хатына ул:

«...Сагынганда айга кара –

Айда очрашыр күзебез», – дип язган. Шуннан соң Фәния гел айга карый башлады. Алай гынамы соң, мәктәп елларында кулына китап тотмаган кыз шигырьләр укый башлады. Күңеленә хуш килгәннәрен күчереп ала да Гыйльметдиненә язып җибәрә. Шулай хатлар аша сөйләшә-сөйләшә яшәгән арада ташулар шаулап акты,

PRESSA.RU




чәчәкле җәй җитте. Ул арада Фәниянең башына күңел ашкындыргыч кыю уй килде. Берәүгә дә хәбәр итмичә, кинәт кенә Шаһибулатка килеп төшәсең... Сабан туе бәйрәме менә дигән форсат, дип фикер йөртте ул. Кайтуын кайтып булыр... Кайткач, кемгә туктарга соң? Мин – Казыбаш авылыннан, Мәдинәләрнең күршесе булам, дип, егет өенең ишеген шакый алмыйсың. Шактый көннәр берәр хәйлә эзләп йөри торгач, балачагындагы истәлекләр күз алдына килде. Шаһибулаттан Фатыйма исемле апаның аларда әллә ничә тапкыр кунганы булды. Алар тегермәнгә килерләр иде. Әнисе, Фатыйма апаны безгә кодача тия, дип сөйли торган иде. Менә шуларга кайтырга була ич...

Фәния иң элек Гыйльметдингә хат язды. Сүз уңаеннан гына үзләренә кодача тиешле Фатыйма апаның хәлен сорашты. Соңыннан болай дип тә өстәп куйды: «Посылка җибәрермен дип тотынган идем, фамилиясен белмәдем...» Җавап озак көттермәде. Фатыйма апаның фамилиясе, кемнәр белән яшәве турында тулы мәгълүмат бирелгән хат килеп җитте.

Иртәгә Сабан туе буласы дигән кичне, ике букчасын күтәреп, Фәния Фатыйма апаларына килеп тә төште. Фатыйма карчык аны, иңнәреннән сөеп, рәхмәтләр әйтә-әйтә каршылады.

Иртәгесен Фәния хуҗаларның тугызынчы сыйныфны тәмамлап йөрүче кызлары Ләйсән белән мәйдан карарга чыкты. Гармуннар матур көйләр сиптерә. Шау-гөр. Берсеннән-берсе чуаррак итеп бәйрәмчә киенгән хатын-кызлар... Уен-көлке, шат йөзләр... Әмма Фәния берсенә дә игътибар итми. Аның күзләре тик берәүне, Гыйльметдинне эзли. Ләйсәнне култыклап, мәйдан тирәли өченче тапкыр әйләнгәндә күрде ул аны. Күрде. Текәлепләр карап торды. Гыйльметдине чегәннәрнекедәй чем-кара чәчле, чем-кара күзле ябык кына бер кызыйны җитәкләгән иде.

– Нинди чибәр егет! Чегән кызын җитәкләгән... – дип куйды Фәния Ләйсәнгә.

– Чегән түгел ул – Вәзирә апа, – диде Ләйсән. – Тегесе Гыйльметдин абый. Сөйгән кызы белән...

– Ә-ә, – диде Фәния, башка сүз таба алмыйча.

Бу мәлдә аның зиһене таралып китте. «Сөйгән кызы булган килеш, сөйгән кызы булган килеш...» – дип тыпырчынды баш миенең күзәнәкләре. Хәзер ул нишләргә тиеш соң? Йөрәген учына кысып, күз яшьләрен түгә-түгә килгән юлыннан кире китсенме? Гыйльметдиннең күзенә дә күренмәсенме? Ул рәхәтләнеп, иркенләп Вәзирәсе белән калсынмы? «Юу-ук, калмасын әле! – дип уйлады Фәния. – Күзенә кылчык булып керәм әле. Сагынганда айга кара, имеш!..»

– Әйдә, каршы якка барып басыйк әле, – дигән булды Фәния Ләйсәнгә. – Монда күзгә кояш төшә.

Кызлар Гыйльметдин янына җитәр-җитмәсрәк туктады. Гыйльметдин ишетсен дип, Фәния сүз кушты:

– Сезнең мондагы тау битләре нәкъ безнең Казыбаштагы шикелле икән. Матур.

Кыз теләгенә иреште. Гыйльметдин ялт итеп борылды да күзен шар итеп ачты. Карашлар очрашты. Егетнең кинәт каушап калуы йөзенә чыкты. Ул, ике ут арасында калган еландай, моннан тиз генә киту ягын карады. Тиз генә Вәзирәнең колагына нидер пышылдап алуга, алар читкә атлады. Мондый ук тәкәллефсезлекне Фәния көтмәгән иде. Кыз аптырап калды. Гарьлегеннән күзенә яшь тулды, тамагына төер утырды: «Нинди җылы хатлар язып... Барысы да ялган булган икән... Кабахәт! Качып ук китте бит... Куркак җан...»

Кунак апасының йөзенә чыккан үзгәрешкә игътибар иткән Ләйсән борчылып сорады:

– Фәния апа, ни булды? Авырыйсызмы әллә?

– Юк, юк, – диде ул, үз-үзен кулга алырга тырышып. «Гыйльметдиннең сөйгән кызы бар дип, үлеп булмый инде, – дигән уй килде аның башына. – Уйнарга, көләргә, онытылып күңел ачарга».

– Ләйсән, әйдә, биючеләр янына барыйк әле! – диде кунак кыз.

– Әйе шул!

Алар гармунчы янына ук килеп бастылар. Дүрт-биш минут та үтмәде, чем-кара бөдрә чәчле, киң җилкәле, уртача гәүдәле бер егет аны биергә чакырды. Фәния бөтерелә-бөтерелә биегәндә, егет кул чабып такмаклап та торды.

Бие, бие әле,
Биегәнне күрсеннәр;
Кунак кызы иң чибәре,
Иң матуры, дисеннәр.

Аннары Фәнияне әлеге Мулланур исемле егет култыклап тау итәгенә таба алып китте. Ләйсән дә үзенең сыйныфташлары белән китеп барган иде.

Моннан ике ел элек хәрби хезмәтен тутырып кайткан Мулланур кинәт кенә тәкъдим ясады:

– Фәния, әйдә, өйләнешәбез!

Кыз аптырап калды:

– Син – мине, мин сине белмибез дә ич, – дип көлде.

– Белмәгән кыз укылмаган китап инде ул. Син миңа шуны әйт. Бер күрүдә гашыйк булганга ышанасыңмы?

– Ышанам!

– Менә мин сине күрдем дә... Йөрәгем уртасына кереп утырдың.

Шулай сөйләшеп барганда каршыларына Гыйльметдин белән Вәзирә килүен шәйләп алды Фәния. Шул мәлне ул сизелер-сизелмәс кенә итеп Мулланурга сыенды. Егет, кызның тән җылысын тоюга, аны биленнән кочып алды. Фәния Гыйльметдинне күрмәмешкә салынып узып китте...

Шул кичне Фәния Мулланурлар өенә килен булып кайтты.

Яшь килен ул җәйне комбайнчы иренең ярдәмчесе булып үткәрде. Рәхәт булды аңа. Йорт эшләренә катнашмады, мал-туар карамады. Ире белән китте, ире белән кайтты. Басуда Мулланур күбрәк үзе эшләде, Фәния үзәнлектәге агач күләгәсендә ял итте...

Көз керде. Йорт эшләре артты. Мулланурның ике сеңлесе дә мәктәптә. Маллар да көтүдә түгел. Су китерәсе, идәнне көн саен юасы... Ул арада колхоз эшләренә дә кушкалыйлар. Юк-юк та – аның юлында йә Гыйль-


Рәсем: Наталья Васильева

метдин, йә Вәзирә очрап куя. Дөрес, алар янында туктальп Фәния сүз катмый. Уза да китә. Бу очрашулардан аның гарьлеге, тапталган хисләре кузгала... «Нишләп болай соң бу? Нишләп соң мин Гыйльметдинне һаман оныта алмыйм? – дип сорый ул үз-үзеннән. – Әллә чын ярату булганмы соң ул? Мулланур аннан мең тапкырга артыграк бит. Кулыннан килмәгән эше юк. Йөзгә дә Гыйльметдиннән матуррак та... Ә уемда – һаман шул сатлыкҗан...» Йөккә узуы да кәефен гел җибәреп торды. Ризык исенә дә укшый, ашый башласа да укшый. Ниһаять, аның күңелендә Шаһибулаттан китү теләге кузгалды.

– Әйдә, моннан китик! – диде ул бер кичне Мулланурына.

– Кайда?

– Казанга.

– Монда начармыни?

– Начар дип... Кала – кала инде. Сала – сала...

– Калада әзерләп куйганнармы?

– Әзерләп куймасалар ни... Казанга киткәннәр берсе дә кире кайтмый әле.

– Һе, – диде Мулланур. – Тулай торакның эт оясы хәтле бүлмәсен, сасы бәдрәфләрен сагынасыңмы?

Фәния шактый гына эндәшмичә торгач, үзалдына сөйләнгәндәй генә:

– Күңелсез миңа... Ямь тапмыйм... – дип куйды.

Иренең туган йортны ташламаячагын белсә дә, Фәниянең күңеле утырмады. Ул һаман Шаһибулаттан китү хыялы белән янды.

Март башлары иде. Мулланур комбайнын ремонтларга китте. Фәния маллар янында кайнашты. Яз кояшы шулкадәр нурын мул итеп чәчә – күзләр чагыла. Кар өсләре төрле төсләрдән энҗеләрдәй җемелди. Бу матурлыктан күңел кытыклана. Йөрәк каядыр ашкына, тыпырчына башлый. Аек акыл үзенең хакимлеген югалта. Мондый мизгелләрдә хыяллар баш калкыта да үзен тормышка ашыруны таләп итә.

Фәниянең дә Казыбашка кайтып китү хыялы җанына тынгы бирми интектерә. Ю-уук, тора алмый ул монда бүтән. Төннәрен, Муллануры кочагында яткан хәлендә, күз алдына Гыйльметдин белән үткәргән мизгелләре килә. Муллануры иркәләгән саен, Гыйльметдиннең кул җылысын, аның иреннәренең тәмен тоя... Шәһәргә күченсәләр, моннан соң Гыйльметдине белән юллары кисешмәсә... Бәлки, онытыр да... Мулланур китми. Шушы Шаһибулатына, туган йортына кендеге ябышкан...

Ул көнне Фәниянең тәкате бетте. Маллар яныннан керде дә тиз генә җыена башлады.

Киленнең ыгы-зыгы килеп төенчек төйнәвенә игътибар итеп утырган Шәмсегөл апа сорап куйды:

– Берәр җары барасыңмы әллә?

– Китәм, – диде Фәния кырт кына.

Бәрәңге әрчегән Шәмсегөл апаның кулыннан пычагы төшеп китте.

– Ни сөйлисең син? Нишләп? – диде ул, аптырап. Мулланур беләме соң?

– Юк.

– Фәния, ашыкма әле, – диде Шәмсегөл апа, бераз тынычлана төшеп. – Бер син генә түгел, бөтен хатын-кыз кичерә мондый хәлне. Чит кешене «әни» дип йөрисең. Чит кешене «әти» дисең... Ир көен дә көйлисең, өй көен дә көйлисең. Мин дә кичердем синең халәтне. Шулай ирем өйдә юкта, абзар-кура тирәсендә йөргән чакта, тоттым да кайтып киттем. Әнигә зарланам, әти

PRESSA.RU




тыңлап тора. Әти тыңлап бетерде дә, нык итеп әйтте: «Чукрак бул! Күпне ишетмә. Сукыр бул! Күпне күрмә! Тиле бул! Бар сүзне дә йөрәгеңә алма. Бар, хәзер үк ирең йортына кит!» Урамнан килгән идем. Кайтканда бакча башыннан туры абзарга кердем. Тиле мин хәзер. Берни булмагандай кыланам. Әйтерсең, мин беркая да бармаган, абзардан чыкмыйча гел шушында эшләгән. Шулай җырлый-җырлый абзар себерәм. Берзаман кайнатам тавышына сискәнеп киттем. «Килен, – ди, – матур җырлыйсың икән. Түлке җырыңның башын ишетми калдым. Тагын җырлачы», – ди. Тиле кешегә нәрсә? Җырладым. Менә шулай, Фәния. Буең да бар. Сабыебыз туарга тора. Ялгыш адым ясама! Уйла...

– Уйладым инде!..

Шәмсегөл, килененә ни-нәрсә дияргә белмичә бераз аптырап утырды да, өйдән чыгып китте. Ул ашыга-ашыга, туп-туры, күршесе Фәрдәниягә керде.

– Килен китә! – диде кайнана, ишеген ябар-япмас. – Кер әле. Берәр сүз әйтеп кара. Сиңа колак салмасмы?..

– Сеңлем, – диде Фәрдәния, иплəп кенә. – Алдымбәрдем генә, болай ашык-пошык хәл ителә торган гамәл түгел бит. Уйла әле...

– Уйладым инде...

– Тагын уйла! Мулланурыңны бер югалтсаң... таба алмассың... Ирләр мондый гамәлне кичерми.

– Ил бетмәсә, ир бетмәс әле, – диде Фәния.

Һәм... Төенчеген тотып чыгып та китте. Шәмсегөл апа Мулланурны һәр көн Казыбашка куды:

– Улым, алып кайт киленне. Сагынгандыр... Шуңа гына киткәндер... Яшь акыл – буш акыл... Әйтергә кирәк ие дә бит...

– Мин кумадым. Үзе киткән. Үзе кайтыр да!..

Фәния кайтмады... Кызы Тәнзиләне тапкач, алты айлык нарасыйны әнисенә калдырып, Казанга китте. Тәнзилә дәү әнисе белән үсте. Балам бар, дип гариза биргәч, төзелеш идарәсе җитәкчелеге аңа тулай торактан бер бүлмә дә бирде.

* * *

...Фәния авыр сулап куйды.

Ул үзенең тормыш юлын кабат күз алдыннан кичердеме, беразга тынып калды. Ә мин аны аңларга тырышып, үз-үземә сораулар бирә башладым. Нәрсә соң бу: иң элек Гыйльметдингә үч итеп кенә кияүгә чыгуына, аннан соң алдын-артын уйламыйча гына аерылуына үкенүме? Тәнзиләне ятим итеп үстергәне өчен үз-үзен гафу итми яшәү газабы тышка бәреп чыгуымы? Әллә... Бүгенге ятимнәрнең саны сугыш вакытындагыдан да артып киткәнлеген хатын-кызларга аңлатасы килүме?.. Башымда мең төрле сорау. Аларга җавап табарга теләп, мин тагын сүз башлыйм:

– Фәния апа, Мулланур абыйдан соң икенче иргә чыктыгызмы соң?

– Әйе, – диде ул. – Йортка керттем. Кызыма ун яшь тулганда бер бүлмәле фатир алдым. Үземнән җиде яшькә кече егет белән танышкан идем.

– Шуннан?

– Ару гына яши идек үзе, наный. Тәнзилә дә якын итте. Әти дип, йөрде... Тәнзиләм үндүрт яшенә җиткәч... Мин юкта Хөснуллам... кызыма күз ташлый башлаган...

– Менә кабахәт! – дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым.

– Кабахәтнең кабахәте! Ярый әле, тавыш-гауганы ишетеп, күршеләр ишек дөбердәткән.

– Аннары?..

– Утырттылар... – бераз тын торгач, ул болай дип өстәде: Тик... Тәнзиләмнең йөрәгендә мәңге төзәлмәс яра калды...

Хатынның сөрмәле күз төпләре дымланды. Фәния апа күңелендә шыткан беренче мәхәббәт гөлен күз алдыма китердем. Ул мәхәббәт гөлендә яшел чирәм өстендәге таң чыкларының иртәнге җемелдәве, саф сулы чылтер чишмәләрнең шатлыклы агышы, колачын җәйгән иген басулары күгендә тургайларның эчкерсез җыры чагыла сыман... Ә ул гөл сулган. Чыклар кипкән, чишмәләр киткән...

– Мулланур абый белән башка очрашмадыгызмы? – дидем мин бераздан.

– Очраштык. «Әйдә, кайт Шаһибулатка», – диде. Чакырды...

– Ә син?

– Юк, дидем. Бер кискән ипи ябышмый, дидем. Тиле булганмын. Үземнең юләрлегемә әле дә шаклар катып утырам, акыллым. Шул юләрлек аркасында үзем бәхетсез булдым. Кызымны ятим иттем. Шәмсегөл әнигә, үз әниемә, Мулланурга никадәр җан ярасы ясадым! Җирләргә ятып еласам да, кырларга чыгып кычкырсам да узган гомерләр кире кайтмый шул! Әгәр мөмкин булса, мин сөйләгәннәрне түкми-чәчми яз, Зөһрә акыллым! Гыйбрәт итеп яз! Дөньяның матурлыгы, аның бар яме тигезлектә! Ә ул тигезлекне хатын-кыз зирәклеге саклый. Гаиләнең иминлеге, балаларның тәүфыйгы, аларның бәхете – хатын-кыз кулында.

* * *

Мин бүлмәгә кергәндә хезмәттәшләрем кайтып киткән. Өстәлемдә бүлмәдәшем Әлфия калдырган язу ята. «Зөһрә, син кайда йөрисең? Хуҗа эзләде. Иртәгә «давыл» чыгарга охшаган. Әзерлән».

Мин ирен чите белән генә елмайдым да тәрәзә каршысына килеп бастым. Көндезге көч-куәтен югалтып офык читенә җиткәч, кояш сүрән, кызгылт нурларын миңа төбәгән сыман. Бүлмә җиләсләнгән. Утыр да, көндез яза алмаганнарыңны рәхәтләнеп яз. Тик кулым эшкә бармый. Фәния апа сөйләгәннәрдән гәүдәләнгән мәхәббәт гөленең сагышлы язмышы күңелемә тынычлык бирмәде. Сагышка уралган фәлсәфи уйлар башымда бөтерелә. Иң мөһиме: кылган хаталарың башкаларга бәхетсезлек китермәсен икән дип уйлыйм. Кеше рәнҗеше өстеңдә тормасын. Уйларым чоңгыл өстендә йөзгән йомычкалар сыман әле калкалар, әле баталар. Бөтерелеп торган уйлар упкынында бүлмә тынчулыгы да, баш мөхәррир кузгатасы «давыл» да – тормыш вактөякләре генә...

БОРЫН-БОРЫННАН ӨЙЛӘНЕШҮНЕҢ АЛ-ШАРТЛАРЫ БУЛГАН. ЯУЧЫЛАР, ДИМЧЕЛӘР, ТАНЫШТЫРУЛАР, КОЛАК ТЕШЛӘТҮЛӘР, УРЛАП КАЙТУЛАР... ҺӘР ХАЛЫКНЫҢ ҮЗ ЙОЛАСЫ, ҮЗ КАГЫЙДӘСЕ, ҮЗ ГАДӘТЕ...



Асия
ЮНЫСОВА

# ӨЙЛӘНЕШИК

Колак тешләтүләр татарларда булмаган бугай. Ә менә кыз урлаулар хакында үзем дә язгалаганым бар. Яшьләрнең бу рәвешле өйләнешү гамәлен әле дә безнең тормыштан югалган дип булмый. Татар хәятенең егеткә кыз яучылау хәлләренә нигезләнгән сәхнә әсәрләре дә байтак безнең драматургиядә. Мәшһүр «Галиябану» драмасын гына искә төшерик. Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем»е соң, Галиәсгар Камалның «Бүләк өчен» комедиясе... Әйе, яңа гаилә кору кебек җитди мәсьәлә тирәсендә драма да, комедия дә гомер буе уйналып тора.

Замана яшьләре гасырлар буе уйналып килгән сценарийны хәзер үзләренчә «яза» башлаганнар икән. Әле менә бер дустым шалтырата. Ишеткән яңалыгыннан хәйраннар калган. «Беләсеңме, – ди, – Казандагы оныгыма егете тәкъдим ясаган. Ничек итеп, дип сора! Кран алып килеп, оныгым яшәгән тәрәзә биеклегенә күтәрелгән дә, тәрәзә шакып ачтырган. Аннары чәчәк бәйләме белән йөзек салынган тартма сузган. Чәчәк арасына «Өйләнешик!» дигән язу кыстырган. Тиздән туйлары була».

Менә шулай. Элекке вакыт булсамы? Дустым, шәльяулыгын ябып, кодагыйларын күрергә барыр иде. Чәкчәкләр анда, пар күмәчләр, пар казлар... Хәзер әнә ресторанда утырыр да кайтыр. Чакырсалар әле. Ярый әле туй була, дигәннәр. Яшьләр туй үткәреп, туган-тумача җыеп азапланмыйлар. Үзләре генә «межсобойчик» үткәреп алалар да, имеш, гаилә булалар. Ярый әле, «гражданлык никахы» дигән шаукым соңгы вакытта модадан чыга бара.




Тәкъдим ясау мәсьәләсе миңа, чыннан да, кызык тоелды. Юлымда очраган беренче яшь ханымга ук мөрәҗәгать иттем. Имеш, егете аның кулын ни рәвешле сораган. Әтиәнисенә кыз сорап барганмы? Ягъни йоланы үтәгәнме? Баруын бармаган икән, әмма тәкъдим үзенчәлекле ясалган. «Ул Кытайга укырга киткәндә миңа бер диск биреп калдырды. Аның эчендә: «Мин алты айдан кайтам, кайткач та кавышырбыз», – дигән сүзләр тезелгән җыр бар иде. Кавыштык. Аңынчы бу хакта хатлар аша сөйләштек». Бу темага хикәятләр байтак җыйдым мин. Гаджетлар, техника заманында танышу да, кавышу да проблема түгел икән. Тик менә яшьләр романтикага сусаганнар. Хәтта техника һәм гаджет катышлы романтика булса да... Әйтик, бер егет болай иткән. Машинам ватылды, дип автосервиска борылып кергән. Анда механик белән низаглашкан. Имештер, якалашып киткәннәр. Кыз егет өчен ут йота башлаган. Кайнарланып китеп, ул да капотка барып ябышкан. Ә анда машинаны сафтан чыгарырга мөмкин булган тартма ята икән. Алып ташлыйм дисә, эченнән машина бәясе торышлы җәүһәр ташлы йөзек килеп чыккан. Шул йөзекне борынгыларча, ягъни гади итеп кенә – сыңар тезен тезләнеп, сыңар кулын кызга таба сузып: «Сөеклем, чык миңа кияүгә!» – дисә, ни булган инде?.. Юк шул, мөгез чыгарырга кирәк.

Мөгез чыгару артистлардан башланды бугай. Алар бит йә диңгезгә чумып, йә тау башына менеп туй балдагы кигерәләр. Әйтик, Анастасия Заворотнюк өченче иренә – Петр Чернышевка кияүгә чыксын өчен спортчы егет мондый хикмәт ясый. Диңгезгә кереп китә дә, «менә нәрсә таптым» дип, Настяны суга керергә чакыра. Егет учын ачып җибәрсә, анда тагын да шул җәүһәр кашлы йөзек икән. Икенче берәү, монысы Казанда, ярәшү балдагын поварга биреп, үзләре ашарга тиешле балык эченә салдыра. Байларның әкиятләре дә кызык инде. Антон Сихарулидзе белән Яна Лебедеваның әкияте мондыйрак: Антон төрле тартмалардан матрешка ясаган. Матрешканың бер тартмасыннан мәхәббәт аңлаткан язу, икенчесеннән назлы сүзләр, өченчесеннән: «ашыкмый тор, шушы номерга шалтырат» дигән әмер килеп чыккан. Әмма Янаның телефоны сүнгән икән – шалтырата алмый. Ярый әле шул мизгелдә чәчәк бәйләме тоткан Антон үзе килеп кергән, йөзеге белән инде...

Ике авыл арасын – сигез чакрымны – җәяүләп, чемодан күтәреп килен булып төшкән җиңгәмне искә төшерәм дә уйлап куям: иң мөһиме шаккаттыру түгел, ә гомерне ничек яшәп бетерү ләбаса!

PRESSA.RU






10 мартта Татарстанның бөтен кинотеатрларында «Гаилә мәшәкатьләре» («Семейные хлопоты») дигән тулы метражлы комедия прокатка чыга. «Татаркино» дәүләт бюджет учреждениесенең матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, әлеге нәфис фильм Казанның мультиплексларында ике атна дәвамында көн саен ике-өч тапкыр күрсәтеләчәк.

...Рус егете белән татар кызы корган катнаш гаиләдә бала туа. Балага нинди исем кушарга? Рус исемеме, татарныкынмы? Менә шунда башлана да инде хикмәтләр... Сюжет Казанда булган вакыйгаларга нигезләнгән. Фильмның продюсеры һәм режиссеры – Россиянең «Ак фил» кино тәнкыйтьчеләре һәм кино белгечләре гильдиясе бүләге иясе, «Ника» номинанты Алексей Барыкин. Фильмда Татарстанның танылган артистлары Ләйсән Фәйзуллина, Андрей Ясинский, Рамил Төхвәтуллин, Люция Хәмитова, Роман Ерыгин, Фирая Әкбәрова, Елена Калаганова уйныйлар.
Фильм 2015 елда ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән төшерелгән.



# ЛӘЙСӘН ФӘЙЗУЛЛИНА



**ТЕАТР**

Ләйсән – театр артисты. Ул 2008 елда Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлап, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә килә. Беренче роле Х. Вахитның «Талак-талак» спектаклендә Гүзәлия була. Шуннан соң «Тәкъдир», «Кыю кызлар», «Курчак туе», «Тартюф», «Зөбәйдә – адәм баласы», «Хан кызы Турандык», «Зәңгәр шәл», «Ричард III», «Хуҗа Насретдин», «Галиябану» һәм башка спектакльләрдә уйный.
Ләйсән – театр артистлары династиясен дәвам итүче. Әнисе Раушания Фәйзуллина – Татарстанның халык артисты, Әлмәт Татар дәүләт театрында эшли, 60 тан артык роль иҗат иткән. «Роль турында иң дөрес, ихлас сүзне миңа әнием генә әйтә ала», – ди Ләйсән.



## КИНО

«Гаилә мәшәкатьләре» комедиясе – Ләйсән Фәйзуллинаның кинокамералар каршында беренче мәртәбә генә уйнавы түгел. Моңа кадәр аның «Дилемма» (режиссер – Рамил Төхвәтуллин), «Гастарбайтер» (режиссер – Илшат Рәхимбай) нәфис фильмнарында, җырчы Илсафның бер клибында төшкәне бар.



## ТӨП РОЛЬ

«Гаилә мәшәкатьләре» комедиясенә аны режиссер Алексей Барыкин чакыра. Ул Ләйсәнне «Гастарбайтер»да күреп кала. Көннәрдән бер көнне Ләйсәнне эзләп таба да: «Сиңа төп роль бар», – ди. Ләйсән, сценарийны да укып тормыйча, риза була, чөнки театр артистына кино кебек башка төр сәнгать әсәрендә катнашу тәҗрибәсе дә, һичшиксез, кирәк дигән фикердә. «Ә бездә андый мөмкинлекләр еш булып тормый», – ди ул.



## «ГАИЛӘ МӘШӘКАТЬЛӘРЕ»

«Гаилә мәшәкатьләре» комедия булса да, анда күтәрелгән проблема җитди: катнаш никах, мәхәббәт һәм көндәлек тормыш өчпочмагында мөнәсәбәтләр сынау үтәргә тиеш буллы. «Бу җәһәттән, мин үзем татар гаиләсе корыр идем. Балаларым телне, мәдәниятне, тарихны белеп үссеннәр иде. Бәлки, башка яшьләр дә бу фильмны карагач, уйланыр», дип ышана Ләйсән Фәйзуллина. Ул үзенең героинясы Айгөлне дине дә, иманы да булмаган «умырткасыз адәм баласы» дип бәяли. «Мин үзем андый ук ваемсыз булмас идем», – ди ул.



## КИНО ҺӘМ ТЕАТР ТУРЫНДА

Кино белән театрның табигате төрле. Хәтта театр артистының камера каршында югалып калган чаклары да булгалый икән, чөнки кино артык тормышчан. Россия киносының күп йолдызлары берьюлы театр артисты да, кинода да уйныйлар. Аларның күбесе, кинода төшү – вакытлы шөгыль, ә театрда уйнау дәрәҗәлерәк эш, дип саный икән. Ләйсән дә бу тәҗрибәсен үзендәге потенциалны кино ачып бетерә алмаган, ләкин театрга кайтып, сагынып уйнау өчен стимул булган, дип әйтә. «Масштаблырак проектларда катнашыр өчен этәргеч булды бу», – ди актриса үзе.



## ЛӘЙСӘН — КУЛ ОСТАСЫ

«Зәңгәр шәл» спектаклендәге 8 метрлы чигүле чыбылдык, 11 яулык, 9 алъяпкыч, «Дон Жуан»да Люция Хәмитнең героинясы кигән пальто һәм Хәлим Җәләйнең башлыгы – Ләйсәннең алтын куллары булдырган «сәнгать әсәрләре».

PRESSA.RU





Күл буе тыкрыгының түренә урнашкан әлеге төп йортта тормыш шулай үз көенә ага бирә. Ләкин бу гадәти мәшәкатьле гади йортның авылдагы башка бер өйдә дә булмаган хикмәте бар — бу нигездә Клара БУЛАТОВА дигән шагыйрә яши.

# БЕР ИЛАҺИ ЗАТ



Камәрия ЖӘМАЛЕТДИНОВА

Авылдагы төп нигезгә күченеп кайтуларына да кырык еллар инде аларның. Башта кайнатасы Харис абзый, аннан соңрак әнкәләре Маһинур апа да улы-килененең кайгырту-хөрмәтен күреп 89 яшендә дөнья куйды. Шул арада бердәнбер уллары үсеп җитеп, инде үзләре әби-бабай дәрәҗәсен алган Ханым белән Әфәнде оныкларга тиенделәр.

Зур бәрәңге бакчасы, һәртөрле яшелчәгә урын биреп, шунда ук нәсел хыялы умарталарны да үз куенына алып, тәмам кечерәеп калды. Ихатада Әфәнде-бабай ясаган читлекләрдә йомшак куяннар үрчеде. Бакча җиләкләре кышны көтеп базга урнаштылар, гәрәбә чорналган кәрәзле рамнар өстәл түренә күчте. Ханым-әби белән Әфәнде-бабай тынгысыз холыклары һәм әкияти хыялыйлыклары белән дөнья көтәләр. Ә авыл җиренең, үз йортының шөгыль-мәшәкатьләре һәркеменә җитә.

Биш-алты яшеннән такмаклар чыгара белгән, студент чагыннан шигырь китапларын бастырган, 25 чакрымнан йөреп авыл мәктәпләрендә, Әлмәт шәһәр гимназиясендә, татар-төрек лицеенда, муниципаль институтта – җәмгысы 52 ел дәвамында татар теле һәм әдәбияты укыткан, гомере буе мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән мөгаллимә ул. Бу көнгә 50 ләп китабы, шулар арасында 2 томлык сайланма әсәрләре дөнья күргән. Шигырьләре көйгә салынган, поэмалары һәм чәчмә әсәрләре белән дә үзенең талантын раслаган әдибә ул. Иҗаты һәм хезмәте өчен дәүләтнең һәм җәмәгатьчелекнең зур бүләкләрен дә алган шәхес. Җир кешеләре турында җирдә торып язучы, халык кызы. Ир хатыны, ана, килен, кодагый, кайнана, әби дигән вазыйфалары да бар әле. Шагыйрә Клара Булатованың тулы портреты менә шундый.

Клара апа белән беренче очрашуга да 47 ел икән инде. Безнең сыйныфка Аны директор үзе алып керде. Дулкын-дулкын үҗәт чәчен бөтереп-бөтереп җыеп кадаган, «кәртинкә кебек» зифа буйлы, үзе гади, әмма шәһәрчә затлы, сөйкемле бу апага сынап та, сокланып та текәлдек без. Ә танышу көтелмәгәнчә булды. Ул безне кызык итте. «28 кешенең исем-фамилиясен берьюлы отып булмас. Шуңа бүгенгә болай танышыйк, – диде ул. – Чәчәк исемле кызлар бармы безнең?» Әнә – Ландыш, Сиринә, Гөлсинә... Адашлармы? Буа буарлык: ике Рәис, ике Рөстәм, ике Илдар, ике Илдус! Мәдинә исеме җырданмыни әле ул?! Ә Исмәгыйльнеке спектакльдә дә бар! Карале, һәркемнең исеме үзенчә «атказанган» икән бит!.. Әлмәт районының Яңа Кәшер авылы урта мәктәбенә укытырга килгән кызыл дипломлы мөгаллимә шул чакта ук ике китап чыгарган шагыйрә иде бит. Ә шуннан соңгы китапларда безнең күз алдында туган шигырьләр – без белгән кешеләр яки үзебез («Алтынчылар» шигыре) турындагы әсәрләр дөнья күрә торды.

Уку елы башлангач килгән Клара апа мәктәпкә якын яшәүче чибәр, уңган тол хатын Гыйльмия апага фатирга керде. Ә Гыйльмия апа килене ярдәменә мохтаҗ булган бик өлкән яшьтәге кайнанасын тәрбияли һәм ятим оныгын үстерә иде. Без шаһит булган беренче шигырь («Бәрәңге уңды быел көз») менә шунда туды. Көндәлек гади тормыштан алынган әсәр ачлыкны һәм ялангачлыкны, сугышны һәм ятимлекне кичергән әби-апаларны, күрше халкын елатты да, моңайтты да. Ә мөгаллимәнең җанга үткәреп сөйләгән яңа шигыре шул мизгелдән аны гайре табигый зат итеп танытты. Гадәттә, гади халык шигырь укымый, укыганы да аңламый дияргә яраталар. Нәрсә турында һәм ничек язасың бит! Үз гомерендә ни кадимчә, ни җәдитчә уку эләкмәгән әнием белән ахирәт дусты Җәннәт апа да «Клара шигырьләре»н миннән кат-кат укыталар иде. Ә безнең Яңа Кәшер – Нәдер «квадратында» (башка якташларым үпкәләмәсен, бу шартлы үлчәм! – *К. Җ.*) – көн дә күз алдындагы хәлләр шигырьгә әйләнеп, янәшәңдәге син хөрмәт иткән кешеләр җырга әверелгән төбәктә мондый бәяләмә кимсетү дип кабул ителә ул!

Гыйльмия апа өе белән мәктәп арасында инеш аша салынган асылмалы басма бар иде. Тиздән ул да җырга күчте («Кыз җыры», Хәлил Сәлимов көе – *К. Җ.*). Һәм могҗизага тиң мондый хәлләр мәктәп елларында һәр көнне булып тора иде. Колхозның уңган шоферы да, алны-ялны белмәгән игенчесе дә, кешелекле табибыбыз да, тату гаиләдәге сөйкемле хатыны да, кырлар патшасы агроном да һәм башка һөнәр ияләре – гомумән, безнең зур авылның ихтирам казанган кешеләре шагыйрәнең яраткан геройларына әверелде. Ә инде борын-борыннан китапны, әдәби сүзне олылый белгән татар өчен бу «Почетная грамота» гына түгел, бик затлы бүләк иде. Әйтергә кирәк, Гыйльмия апа фатиры Клара апаның бик күп шигырьләре туган бәрәкәтле нигез булды. Мөгаллимә шагыйрә күрше Нәдер авылы егетенә кияүгә чыгып, тормышына гаилә-бала мәшәкатьләре дә кушылгач, аның иҗатына да яңа хисләр, яңа геройлар өстәлде.

*Кәшергә килгәч язылган шигырьләр тиз арада яңа китапка әйләнеп куандырды.*

Бервакыт шулай Укытучым өендә тикшереп алып килгән контроль эш дәфтәрләрен класста тараткач, күңелле шау-шу купты. Әнисе тикшереп билге куйган кайбер дәфтәрләргә кечкенә Марс үз «автограф»ын язарга өлгергән икән!

...Кай арада өлгердең соң
Буялырга ал-зәңгәргә?
Ник тиясең минем дәфтәр
Карый торган каләмнәргә?
Китапларга ник тиясең,
    Дәфтәрләрне ник аласың?
    Бер апаңның диктантына
    Әкәм-төкәм ясагансың.
Аңар ни дип аңлатыйм мин
Бу сурәтнең чыганагын?
Дәрестә бит сөйләп булмый
Улыңның тик тормаганын.
        Мә үзеңнең дәфтәреңне,
        Тегe якка әнә кер дә
        Яз, газиз углым, әмма тик
        Бу өстәлгә тия күрмә... – дигән юллар

(«Яз, газиз углым») да безнең мәктәп еллары хатирәсе. Ана хисләре, хатын-кыз кичерешләре, яшәү мәгънәсе, гомер турында уйланулары белән шагыйрә үзенең укучысына тагын да якыная барды.

Мәктәп елларымның Укытучыма бәйле җанга якын хатирәләре бихисап. Һәр адымда, һәр минутта шигырь туарга мөмкин булуы, без көн дә күреп йөргән гадәти хәлләрнең шигырьгә күчүе – безнең өчен могҗиза иде. Җаныма якын газиз кулъязма-истәлекләремне актарып утырганда, әллә ничек, масаеп аласым килеп китте әле: һәммәбезгә «улым-кызым» дип дәшүче Укытучым кеше алдында миңа корырак, таләпчәнрәк булса да, башкалардан артыграк яратканын сизә идем. Мәктәп чыгарылышына Ул миңа үз хыялындагыча «билен өзеп, җиңен бөреп» аклы күлмәк тегеп бүләк итте. (Колхоз пенсия-

PRESSA.RU



сендәге әти-әниемнең мөмкинлеген уйлап, мине сөендерүе булгандыр инде...) Гомумән, тегүгә дә, чигүгә дә маһир бу затның бер кичтә ялт итеп тегеп-чигеп кигән костюм-күлмәкләре иң көяз-купшы ханымнарның да күзен кыздыра иде... Ә шигъри хатлар арасында нindиләре генә очрамый... Менә монысын мине экраннан күргәч язган. 4 нче курстан соң үз гомеремдә бер тапкыр чәч кистергән идем, мондый хат алдым:

«Камәрия-бала! Ни чуртыма ул чәчеңне кистең әле син, юньсез? Бик килешә дип уйлыйсың инде, ә? Чуртым да килешми, шуны бел! Шигырьләрең әйбәт, укуың әйбәт. Гомумән, экранда күренүең әйбәт. Әмма чәчеңне кисүең юри дә бер әйбәт түгел. Әйбәт түгел, менә шул!» – дип тетмәмне теткән иде. Аныңча, озын толым – татар кызының горурлыгы булырга тиеш иде.

*Көндәлекләре – аның сулышы, йөрәк тибеше кебек табигый, эчкерсез халәте.*

...Ул шигырьләрдә үз сүзен бик тә гади һәм берәгәйле итеп, көтелмәгәнчә әйтә белә шул.

Алмашынмас ике бөҗрам минем,
Әткәм-әнкәм минем – карт, карчык.
Хәтта ярны ярлар алыштыра,
Сезне булмый, булмый алмашып! – дип язды ул әти-әнисе турында.

Мин бу кешелекле, гадел, тыйнак мөгаллимнәр гаиләсендә күп тапкырлар булып, Гариф абый һәм Хәнифә апаның яктылыгын-җылылыгын үземдә дә тойган кеше. Шуңа күрә биш балалы гаилә язмышын үзебез туып-үскән һәм матур хыяллар белән яшәткән совет иленең чын тарихы дип саный идем. Ә Клара апа шигырьләре еллар узган саен кыйбласы гел үзгәреп торган тарих дәреслекләреннән көчлерәк, үтемлерәк иде безнең өчен.

Зирәк фикерле, чая телле, гаҗәеп хәтерле чичән шагыйрә гомеренең теләсә кайсы фасылында да үтә нечкә хисле, әмма көчле рухлы әрнүле җан булып кала бирә:

Сөю мине мең кат үтерде дә
Мең дә бер кат яшәү китерде, – ди ул соңрак.

1959 елдан бирле үзенең күңел хисен шигъри көндәлекләр итеп яза ул.

...Җан актарып тапкан шигъри сүзләр,
Табигатьтән килгән бу көйләр –
Минем өчен иҗат, яшәү, өмет! – ди шагыйрә бер язмасында.

Мәктәптән башланган рухи якынлыкның дәвамы булып, арабызда йөргән хатлар, бәйрәм котлаулары да еш кына шигъри юлларга тезеләләр. Чөнки күңелдәге ул кабызган сихри яктылыкны, яхшылыкны аңа үз дулкынында җиткерәсе килә:

Ак чәчәкләр ак теләгем булсын
Ак чәчәкләр төсле бу җанга.
Язмышыма мең рәхмәтле бит мин
Дөньялыкта шул җан булганга.

Шигърияттнең Зөләйхасыдыр ул,
Йә яшьлекнең пәйгамбәредер...
Җиргә иңдерелгән шул илаһи
Затларның да меңнән бередер...
Бәлки, ул җан салкын март җилендә
Җылы эзләп туган бөредер...
Язмышларны ярлыкарга иңгән
Бу галәмнең бердәнбередер?
Илаһилар аңа зирәклекне,
Чичәнлекне күктән биргәндер...
Ак чәчәкләр төсле яктылыгы,
Керсезлеге барыбер җирдәндер...
Күңел төпкеленең тирәнлеге
Илаһилар салган сердәндер...
Ни булса – шул, әмма дөньялыкта
Бу әүлия күңел – бердәнбер!

Көндәлекләрнең бер өлеше китапларында урын алса да, шагыйрә ихтыяры белән гомерлек сер булып калырдайлары да җитәрлек...

1996 елның 24 апрелендә «Тукайга» дип исемләнгән язмасында мондый юллар да бар:

...Әллә нинди серле уртаклык бар
Остаз белән шәкерт көнендә.
Син кичергән милли язмышыбыз
Әрнүле шул әле бүген дә.
...И Габдулла! И нарасый Апуш!
Уртаклыклар күп шул язганда.
Өметләрне сүндермәсен тормыш
Сине биргән моңлы язларда...

(Көндәлек, 33 нче бит.)

Сер сыярдай шушы остазы исеменнән узган ел бирелгән олы бүләккә – Тукай премиясенә чынлап та лаек кеше Клара апа. Шул мәртәбәле вакыйгалардан соң да аның өр-яңа ике китабы дөньяга туды бит! Тукайдан 50 ел соңрак туып, Тукай җанын яшәтүче, Туфан рухын саклаучы бу серле зат һаман да иҗатта: ул өр-яңа китабын басмага әзерли, үзенең турылыклы укучылары белән очрашуларга йөри һәм ... килен булып төшкән нигезендә көн итеп ята. Бу йортта әле хәзер дә авыл тормышының югала барган ямен эзләп, яшьлекләренең ризык тәмен сагынып, бер карасаң – махсус тарттырылган көрпәле оннан таба күмәче салалар; икенче килүдә чөгендерле катык көтә яисә чичән шагыйрәнең күпме китаплар койган кулы тансык тары коймагы пешергән була.

Быел февраль уртасында очрашкач, мин укытучымнан тагын бер дәрес алып кайттым. Клара апа, чәе суынуын да онытып, миңа татарча бер озын поэманы яттан сөйләде. Тын да алмый тыңлап бетергәч, сорау бирдем һәм оятлы булдым. «Тарас Шевченконың «Катерина» дигән поэмасы бу, балачактан йөрәктә калган әсәр. Беренче тапкыр сугыш вакытында ике баласы белән бездә яшәп алган украин хатынынnan ишеткәнем бар иде. Соңрак үзеннән-үзе телгә күчте», – диде укытучым һәм 60 яшен түгәрәкләп килүче шәкертенә карап: «Табып укы син аны!» – дип, чәенә үрелде.



ХУҖАНБЕРДИЕВА Чулпан

Казан дәүләт университеты,
Казан дәүләт университеты аспирантурасы

Кияүдә, кызы бар

Карьера:
Түбән Кама шәһәрендәге 35 нче лицейның югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «ТР иң яхшы укытучысы – 2011, 2012, 2013, 2014, 2015»

Тормыш шигаре: «Сүз белән түгел, эш белән»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

## Үзебезнеке!

Яз җитә. Табигать белән бергә күңел дә җанлана. Нигә әле шатланмаска?! Яраткан гаиләм, әти-әнием, туганнарым исән-сау, эшем бар. Иң мөһиме – ипотекага алынган фатирның бурычын түләп бетердек! Моның нинди зур сөенеч икәнен үзе кичергәннәр генә белә... 2007 елны, бюджет оешмасында эшләүчеләр буларак, ипотекага фатир алган идек. «Җан биргәнгә – җүн бирә», диләр, менә бит, исән булгач, тау кебек тоелган бурычларның да бер очына чыктык... Фатир үзебезнеке хәзер! Безнең кебекләрне йортлы-җирле итү юлларын тапкан хөкүмәтебезгә ничек рәхмәтле булмыйсың?!


## Һөнәри үсештә стимул кәтә

ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов: «Укытучы 7 ел эчендә югары категория ала һәм... аннан соңгы 40-45 елда аның үсешкә бернинди омтылышы да булмый», – диде. Чыннан да, биш елга бер, категорияңне раслап, аттестация үтсәң дә, тагын тыныч кына эшлисең. Быел исә педагогларның һөнәри үсеше системасы камилләштерeләчәк: югары категорияле укытучылар өчен ике баскыч булдырыла. Үз дәрәҗәсен раслаган педагоглар быелдан ук югары категория өчен өстәп түләнелә торган 40 процентка тагын өстәмә матди ярдәм дә алачак.


## Хиҗаблы... балерина

14 яшьлек Стефани Курлоу (Сидней, Австралия) кечкенәдән балерина булу турында хыялланган. Әмма аның гаиләсе 2010 елда ислам динен кабул итә. Ә балет сәхнәсендә хиҗаб кигән биюче әле булганы юк... Кыз үзенең карарында нык: ул бу өлкәдә яңа тәртипләр кертергә, беренче мөселман балеринасы булырга җыена. «Дингә, милләтенә, тән төсенә карамыйча кешеләрнең сәнгать тирәсендә берләшүен телим», – ди ул. Балеринага уку өчен елына 10 мең доллар акча җыярга кирәк аңа хәзер. Стефани өметен өзми.

сөендерде









көендерде

сөендерде







көендерде

сөендерде



көендерде

## Шартлар нигә бер түгел?

Рус мәктәпләрендә укучы рус балалары өчен үткәрелә торган олимпиаданың республика этабыннан кайттык. Укучым – 9 нчы сыйныфтан Елена Андрющенко (әтисе – украин, әнисе – рус) җиңүче булды. Ләкин бу җиңү безгә ничек бирелгәнен үзебез генә беләбез... Ә Арча, Азнакай, Мамадыш, Саба кебек татар районнары туу турындагы таныклыгына әти-әнисе рус (мари, чуаш, әрмән, әзәрбайҗан) милләтеннән дип язылган, әмма татар мохитендә берничә ел тәрбияләнгән, өстәвенә, татар мәктәбендә белем алучы укучыларны алып килә...

## Җиңүчеләргә җитәргә ерак шул...

Бала табу һәм тәрбияләү өчен иң уңай шартлар тудырылган илләр рейтингы ачыкланды. Быелгы сораштыруда 16 меңнән артык кеше катнашкан, 60 тан артык илгә бәя бирелгән. Иң беренче урында – Швеция. Аннан – Дания, Канада, Нидерланд, Австралия. Кеше хокуклары, керемнәр күләме, куркынычсызлык, мәгариф һәм сәламәтлек саклау системасының гаиләгә уңай мөнәсәбәттә булуы күз алдында тотылган. Кызганыч, Россия бу исемлектә нибары 38 нче урында...

## Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла...

Канаданың Пикеринг шәһәрендә яшәүче 14 яшьлек кыз, өйдән пычак алып килеп, мәктәп вестибюлендә иртән тирә-юнендәгеләргә ташланган. Яшүсмер алты сыйныфташын һәм ике укытучысын яраларга өлгергән. Япь-яшь кыз баланың нигә бу адымга барганын әлегә беркем дә белми икән... Мондый хәбәрләр ишеткәндә, йөрәккә шом керә. Балаларга бүген ни булды? Нигә шуның кадәр кансыз алар хәзер? Аларны тәрбияләгәндә кайда, нинди ялгышлар җибәрдек? Океан артындагы хәлләр турында сүз барса да, ул бит барыбызга да кагыла.

PRESSA.RU

# ЯШЕН КАЙТАВАЗЫ





Рəсимə
ГАРИФУЛЛИНА

**ТƏРƏЗƏГƏ КАРЛЫ ЯҢГЫР СЫЛАНА. КҮЗ ЯШЕ СЫМАН! ТАБИГАТЬТƏ НИ КӨЗ, НИ КЫШ ТҮГЕЛ. СУФИЯНЫҢ ДА КҮҢЕЛЕНДƏ НИ КӨЗ, НИ КЫШ ТҮГЕЛ. ИРТƏГƏ УЛ УНИКЕ ЕЛ ГОМЕР ИТКƏН, БАЛА БАККАН ЙОРТЫННАН КИТƏЧƏК. КИТƏРГƏ МƏҖБҮР...**

Син бик бəхетле булырга тиеш идең... Əлеге эчке аваз əрнү хисен көчəйтə, нəрсəнедер үзгəртергə яки үзенə үзгəрергə өнди. «Бик бəхетле буласы килгəн иде», – дип җавап кайтара аңа Суфия, сүзсез генə.

Бəхетле булып карады ул. Бəхет кошын кулларына алды. Аның пар канаты – бəхет кошы бар иде. Бар иде... Үзе белəн бергə уйнап үскəн, балалар йортында иң якын кешесе булган Ваня иде ул.

...Суфия үзе бу йортта əнисез калгач яши башлады. Бик каты яшен яшьнəп, күк күкрəп яңгыр килде ул көнне. Яшен уклары пыяланы урталай ярып узды. Чылтырап тəрəзə өлгесе коелды, əнисе кайтканны көтеп, тəрəзə төбендə утырган Суфия да идəнгə мəтəлеп төште. Шуннан башкасын хəтерлəми. Яшен суккан əнисенең гəүдəсен өйгə алып кайткач кына, күршелəре аңсыз кызны хастаханəгə озатканнар. Кул-аяклары пыялага киселеп, шактый кан югалтырга өлгергəн бала яшəү белəн үлем арасында байтак җан тартышкан.

Аңына килгəч, бик озак əнисе килеп алганны көтте əле ул. Палата ишегеннəн бер дə күзен алмады. Ишек ачылыр да, əнисе елмаеп килеп керер дип көтте. «Əнием килмəс инде, балам, көтмə!» – дигəнче өметлəнде ул.

Хастаханәдән туры балалар йортына китерделәр. Биредә беренче мәртәбә Яңа елны каршылаган төнне, салют ата башлагач, кыз тагын аңын югалтып егылды. Дөбердәгән тавыштан курка торган булып калды. Әнисен югалткан көндәге яшеннең кайтавазы гомерлеккә калды.

– Әтием кайда? – дип пышылдады кыз, күзләрен ачкач. Әмма аның бу соравына берәү дә җавап бирә алмады. Саташа дип уйладылар. Ә чынында, саташу аралаш әтисен төшендә күрде ул. Үзен алырга килгән дип шатланды. Аңы буталды.

Әнисен, туган авылын, бергә уйнап йөргән дусларын бик сагынды. Әмма аның янына килүче дә, хәлен белүче кеше дә булмады. Туган йорт дигән төшенчә дә еллар арасында югалып, хәтердән җуела барды.

Ваняның сыйныф ишегеннән килеп кергәне хәзер дә күз алдында. Укулар башланган гына иде әле. Һәр парта саен берәр бала. Укытучы Фекла апалары «Әлифба»ны өйрәтә башлады. Көн саен яңа хәреф, көн саен бер яңалык. Бүген алар «Б» хәрефен өйрәнәләр.

– Ба-ба, – дип ачылган авызлар ябылырга өлгермәде, ишектә мәктәп директоры күренде.

– Бүген сезгә тагын бер дус алып килдем. Аңа үзегезнең арада урын табарга кирәк булыр, – дип, ишек артыннан башы марля белән бәйләнгән малайны чакырып кертте.

– Бездә инде аңа утырырга аерым парта да калмады, – диде Фекла апалары.

– Зыян юк, үзеңә кайсы кыз ныграк ошый, шуның янына утыр, Ваня! – диде директор абый, елмаеп.

Сыйныфка кергәннән бирле күзен күтәреп карарга да кыенсынган малай, урта рәттәге, Суфия утырган икенче партаны сайлады.

– Ваня, все будет хорошо! – диде директор русчалатып. – Ваня татарча авыр сөйләшә, булышырсыз, балалар!

Директор чыгып киткәч, беркавым барысы берьюлы шаулашып алдылар.

– Дәресне дәвам итәбез, тынычланыгыз! – дип боерды укытучы.

Әти-әнисе юл фаҗигасендә һәлак булган икән Ваняның. Ике ятим бер партада утырып укый башладылар.

Соңыннан сөйләделәр: Ваня үзе дә әҗәл белән күзгә-күз очрашкан. Әти-әнисен җирләгәндә аңсыз яткан.

Сыйныфташлары белән тиз дуслашты малай. Татарча сөйләшергә дә бик тиз өйрәнде, иң яхшы укучыларның берсе. Монда тәрбияләнүче балаларның кайберләре янына туганнары, әти-әниләре килеп йөри. Суфия белән Ваня янына гына килүче юк. Алай да балаларны тәрбиягә алырга теләк белдерүчеләр арасында аларны сайлаучылар да бар. Тик Ваня белән Суфия бер-берсеннән аерылмаска дип сүз куештылар. Ваняны алырга теләүчеләр аеруча күп.

– Мин сине калдырып китмим, Софочка, борчылма! – дип тынычландыра аны малай.

– Бертуганнарны гына аерырга ярамый, – дип дәгъвалашып та карадылар. Әмма балалар йорты директоры бу ике баланы аерса, канатлары каерыласын, аларның тома ятимгә әйләнәсен аңлый торган педагог иде.

Тора-бара бу ике баланың дуслыгы мәхәббәткә әверелде. Суфиядан аермалы буларак, Ваняның әти-әнисеннән калган ике бүлмәле фатиры бар иде. Унсигез яшьләре тулуга алар өйләнештеләр дә шунда яши башладылар. Икесе дә читтән торып институтка укырга керделәр. Кыз укытучы, егет инженер һөнәрен сайлады. Суфия балалар бакчасына, Ваня хәрби заводка эшкә урнашты. Аз гына күрешмичә торсалар да, сагынышалар, бер-берсен күз карашыннан да аңлыйлар иде.

– Миннән дә бәхетлерәк кем бар? – дип, әллә үз бәхетенә үзе күз тидерде Суфия, әллә Ходай бәхетләрен гомерсез итеп яраткан иде, бәхетсезлек көтмәгәндә килде.

Шартлау тавышыннан бөтен шәһәр «дерт» итте. Тагын шартлау! Суфия куркуыннан чак кына аңын югалтмады. Балаларны йоклатырга йөргән җиреннән сыгылып төште.

Тагын шартлау! И Ходаем, тагын ни булды икән?

Саклык чараларын үтәмәү аркасында, Ваня эшли торган хәрби заводтагы шартлаудан хәбәрдар түгел иде әле ул. Тик алай да ниндидер шом бар иде йөрәктә.

...Шартлаудан соң исән калганнарның да күбесе авыр хәлдә хастаханәләргә озатылды. Тәннәре, йөзләре пешеп танымаслык булган эшчеләренең кем булуын авырлык белән генә белә алдылар. Шашар дәрәҗәгә җиткән, әмма өметен өзмәгән Суфия үлем белән тарткалашучы кешеләр арасыннан бик озак эзләде сөеклесен. Ваняның яртылаш янган таныклыгын гына табып бирделәр аңа.

## *Ә инсан үзенең киләчәк язмышыннан һаман да бихәбәр...*

Ирен югалтудан аңгыраеп калган яшь хатынны хастаханәгә салдылар. Акылына җиңеллек килүдән табиблар гына коткарып калды аны. Терелеп чыкканда күзләрендә нур уйнап торган элеккеге Суфия түгел, күз төпләре күгәргән, карашын моң-сагыш баскан, вакытыннан алда олыгайган бер ханымга әйләнгән иде ул.

Инде бөтенләйгә ияләште дигәндә генә бәхет кошы кулдан ычкына да, башкаларны ымсындырыр өчен очып китә. Суфия да кошын очырды. Ире белән бергә яшәгән йортта үз-үзенә урын таба алмады, исәнлегенә өметен югалтып, Татарстанга юл алды. Исәбе – туган авылына кайтып, әнисе каберен зиярәт кылу иде. Бәлки, әле әтисе турында мәгълүмат таба алыр.

Укытырга юллама алып кайтты Суфия авылга. Яңа ел җитеп килсә дә, мәктәптә эш бар иде аңа. Инглиз теленнән укытучы табылганга мәктәп директоры бер сөенсә, күрше авылдан килеп балалар укытып йөрүче мөгаллимә ханым икенче сөенде.

Суфия туып-үскән нигез сагындагы алама өй тәмам искереп җиргә сеңгән иде. Шуңа күрә ул ялгыз яшәүче Гайниҗамал карчыкка фатирга керде.

PRESSA.RU



– Гел болай өйдә бикләнеп утырма, бүген клубка чыгабыз, – дип, күрше кызы Гөлкәй үзе белән кичке уенга чакырды.

Клубка килеп керүгә таныш йөзне күреп башы әйләнеп китте Суфияның.

– Егылам хәзер, – дип Гөлкәйне култыклап алды. Аннары:

– Ваня, – дип кычкырып җибәрде. Тик тавышы чыкмады, бугазына төер тыгылды.

– Тынычлан, безнең авылга нинди Ваня килсен! – диде шаккаткан Гөлкәй.

– Әнә, Ваня, үзе генә басып тора, күрмисеңмени?

– Юләрләнмә, безнең Вәлиулла ич ул!

Ул арада Ваня-Вәлиулла биергә чакырып, тыпырдап Суфия каршына килеп тә басты.

– Эч пошырып йөрмә әле, татарча бии белми ул, – дип, Гөлкәй аңа аркылы төште. Әмма Суфия, сихерләнгән сыман, ир-егетнең каршына атылып чыкты. Култыклашып әйләнгәндә:

– Мин сине Гайниләр капка төбендә көтәм, – дип пышылдады ир Суфияның колагына.

Йөрәге, очып китәргә талпынган кош сыман, аңа буйсынмыйча:

*Бәхет кошын тотып кала алганнар бик сирәк.*

– Әйдә, әйдә, Гайниләр капка төбендә көтәләр, – дип ярсып типте.

– Аның белән бер кыз да биергә чыкмый. Ике балалы ир бит ул, – диде Гөлкәй, Суфияның күзләрендә кабынган алгысауны күреп.

– Ул минем Ваням төсле...

– Бу сиңа шәһәр түгел, авылда бөтен нәрсә күз алдында, кеше көлдереп йөрисе булма!

Суфия Гөлкәйне аңларлык та, тыңларлык та хәлдә түгел иде.

– Балалары белән хатыны клубка ияреп килмәгән бит.

– Балалары ияреп йөрерлек түгел, берсе бишектә, икенчесе гарип. Хатыны икенче баласын тапканда үлде. Сиңа шул хатын эзләүче дуадак ир кирәкме?

Гайниләр капка турыннан узганда кызлар каршына чыкты ир. Суфияны беләгеннән эләктереп алды.

– Кая ашыга бу асыл кош?

– Үрелмә Суфияга, сиңа дигән асыл кош тумаган әле.

– Мин синең белән сөйләшмим, Гөлкәй, Суфия үзе хәл итсен, – диде ир.

– Ул синең кем икәнеңне дә белми, мин аны синең белән калдырмыйм.

– Кем икәнемне үзем аңлатырмын.

– Авылда сине кызлар түгел, хатыннар да янына якын җибәрми, шәһәр кызы кирәк булдымыни?

– Миннән түгел, минем ике баламнан куркасыз бит сез барыгыз да.

– Суфияга кирәк дип белдеңме әллә ул балаларыңны?

– Әниләре үлгәнгә ул ятимнәрнең ни гаебе бар соң? Ярата идем мин Сәрияне.

– Әйдә, Суфия, юкка вакыт уздырып, суык туңдырып тормыйк! – дип, Гөлкәй аны ирексезләп үзе артыннан ияртте.

Вәлиулланың:

– Минем Сәриям төсле син, минем сөягем, – дип кычкырганы ишетелеп калды.

Суфияны икенче көнне үк урлап алып кайтты ул. Тик бергә яши башлауга бер-бер артлы үлем-җитем булды гаиләдә. Башта Вәлиулланың гарип баласын, аннары әнисен җирләделәр.

– Киленне килештермәде нигез, – дип чыш-пыш килде авыл халкы. – Нигезгә азан кычкыртырга кирәк.

Шулай эшләделәр дә. Әллә азанның файдасы тиде, әллә әҗәлләр килеп беткән иде, тормыш үз эзенә төште. Көн артыннан – көн, ел артыннан ел узды. Узган гомер яшьлекне дә ияртеп алып китә торды. Вәлиулланың бишектәге сабые, Суфияның алдыннан төшмичә, «әни» дип үсте.

– Агач әни бит ул, синеке түгел, – дип баланы котыртучылар да табылды. Әмма аңа карап кына баланың да, ананың да арасы суынмады. Илсурны үз баласыдай күреп яратты, тәрбияләде хатын.

Үзгәртеп кору касәфәте колхозларның тамырын корытканнан бирле, авылдашлары белән читкә чыгып, акча эшләп кайта Вәлиулла. Суфия мәктәптә укыта, Илсур инде бишенче сыйныфта укый.

Сиздерергә теләмәсә дә, хатынның үзенә карата салкынлыгын яши башлауга тойды Вәлиулла. Хатыны төннәрен Ваня исемен әйтеп саташа. Моны ишетеп, ирнең җене ката. Көндезләрен дә тиктомалдан сагышка чума. Вәлиуллага карата битараф. Суфияның йөрәгеннән Ваня атлы ирне алып ташларга күп тырышты ул. Усал сүз белән дә, кул белән дә «тәрбияләп» карады. Суфия кочагында җылы тапмаган Вәлиулла аны читтән, эшкә чыгып киткән җиреннән эзли башлады. Әле бер, әле икенче хатын белән очрашты һәм үзенә иш булырдайны тапты да. Ике ирдән аерылган, бала бәхете күрмәгән, ир-ат назына сусаган Гашия иде ул. Суфияның да өметләре акланмады. Ваняны онытттыра алмады Вәлиулла. Тышкы кыяфәте аңа охшаса да, холкы бөтенләй башка: тупас, дорфа сүзле, пырдымсыз. Иркәләүләре дә йөрәккә ятышсыз, ясалма.

Соңгы баруында килешеп алган эшләрен тәмамлап кайтып китәр көннәре җиткәч:

– Малаеңны чит хатын кулында интектермә, монда алып кил, бергә яшик! – диде Гашия Вәлиуллага.

– Чит итми ул аны. Бишектән үк үз баласыдай иркәләп үстерде.

– Әтисен яратмаганны баласын гына яратмас инде, икейөзләнәдер...

– Ялгышасың, ихлас кеше Суфия. Мин бер күрүдән ярататтым аны, әмма үземне яраттыра алмадым. Йөрәк ярасы бик тирәндә. Дәвалый алырмын дип өметләндем, булдыра алмадым. Эч серләре җиде йозак белән бикләнгән.

– Илсурны кунакка чакыр алайса, шуннан ияләшеп китмәсме.

– Мин үземнең сиңа китүемне аларга әйтмәдем дә бит әле.

– Берочтан әйтеп тә килерсең...

Суфия үзе дә ире белән ике арадагы мөнәсәбәтнең көннән-көн суына баруын тоя, алга таба болай яшәп булмавын аңлый иде. Җитмәсә, соңгы вакытта Ваня төшенә бик еш керә. Һаман бертөсле төш күрә: «Кайт, көтәм!» – дип Суфияны чакыра. Тик чыраен аермачык төсмерли алмый интегә. Ваня төсле дә үзе, ул да түгел сыман. «Ваня!» – дип кычкыра-кычкыра, җан-фәрманга аңа таба йөгерә башлый, шартлау тавышы ишетелә дә, шабыр тиргә батып, сискәнеп уяна. Нигә кайт дип чакыра ул аны? Унөч ел узды бит инде.

Төшләрен ничек юрарга белмәгәч, Гайниҗамал карчыкка сөйләп күрсәтте Суфия.

– Әллә мин дә үләм микән?

– Төшеңдә күргән кешеңне эзлә, балам, ул исән булырга тиеш, – дип, бөтенләй фикерен чуалтты карчык.

– Эзләмәдем түгел, эзләдем, күптән җир куенында бит ул, – дип елап җибәрде Суфия. Гайниҗамал карчык бераз эндәшмичә уйланып утырды да:

– Беренче күрешкән көннән үк әтиең турында сөйлисем килеп йөрим, кыймыйм гына, – дип, авыр сулап куйды. – Аны эзләп гомереңне бушка уздырырсың дип куркам. Чөнки дөресен миннән башка берәү дә белми. Вәлиулланың мәрхүмә хатыны Сәриянең атасы Заһретдин иде ул. Урыны җәннәттә булсын! Әниең Гыйльмениса белән бик яратыштылар, өйләнешергә өлгермәделәр. Сәриянең бабасы Габделхак әтиең Заһретдин белән дуслар иде. Беркөнне Заһретдинне эчертеп исереткән дә, кызы Нәгыймәне ат чанасына салып җибәргән. Заһретдин иртән айныса, Нәгыймә өйләрендә коймак пешереп йөри ди.

Ирсез бала тапканын белдермәс өчен читкә чыгып китте әниең. Минем сеңелләремдә яшәде. «Иремнән аерылдым», – дип, кире авылга кайтканда сиңа бер генә яшь иде әле. Аның кызы икәнлегеңне Заһретдингә дә сиздермәде. «Җә кешегә ишетелер, балам оятлы булыр», – дип синең өчен курыкты. Үзең дә белмичә сеңлең баласын үстерәсең. Шуңа да бик яратасыңдыр Илсурны, җан тартмаса да, кан тарта шул...

Вәлиулла сәфәрдән кайтып кергәндә, Суфия Гайниҗамал карчыктан ишеткәннәрен аңына сеңдерергә дә өлгермәгән иде әле.

– Юлда ачыккансыңдыр, ашым пешкән, ризыгым әзер, табынга уз, – дип каршылады ул ирен.

– Ашың кайнардыр да, йөрәгең салкын шул синең, – диде ир төксе генә.

– Мин аерылам синнән, Суфия, баланы да алып китәм.

– Үзең кит, баланы бирмим.

– Ничек бирмисең, ул минем малай бит...

– Минеке дә. Китәргә үзе дә риза булмас.

Вәлиулла башта шаркылдап көлеп җибәрде, аннары хатынның күзләрендә яшь күреп:

– Елама, мин уемнан барыбер кире кайтмыйм! Илсурга: «Кунакка барабыз», – диярмен. Балага кем булса да, бер, берәү дә үз әнисе булмас! Без әйләнеп кайтканчы син өйне бушатырсың! – диде.

«Сәрия – минем сеңлем, аның баласы миңа чит була алмый, үз каным», – дип карышасы килде. Тик, серне чишсә, әнисенең рухын рәнҗетүдән куркып, тыелып калды.

Баладан аерылу йөрәген каерып алу белән бер иде Суфияга.

– Әнием, елама, без озак тормабыз, мин сине бик-бик сагынырмын! Каникуллар беткәнче үк кайтып та җитәрмен, – дип юатты аны Илсур, муеныннан кысып кочаклаган килеш битләреннән үбә-үбә.

Тәрәзәгә сылап яуган карлы яңгырга кушылып, тәкъдиренә әрнеп, атна буе елады Суфия. Атна буе кире әйләнеп кайтырлар дип өметләнде. Тик ишек шакучы булмады. Көннәр санаулы иде, каникуллар тәмамланыр вакыт та җитте. Вәлиулла яшь хатынын ияртеп кайтып та төшәр. Юлга җыенырга кирәк. Бүген аның монда соңгы төне. Тик кая барыр?

Өзелгән өметне ялгарга теләгәндәй, ишек шакыдылар. Кем булыр төнгә каршы? Әллә кайттылармы?

*Читтән карап торганда тату, нык тормышлы гаилә. Тик йөрәкләрендә нинди хисләр кайнаганын үзләре генә белә.*

Ашыгыч телеграмма!

Илсурга бер-бер хәл булгандыр дип куркынган хатын, телеграмманың үзе үскән балалар йортыннан икәнен белгәч, җиңел сулап куйды. Җанга рәхәт бер җылылык йөгерде. Очрашуга чакырганнар. Хәер, аның башка барыр җире юк та инде...

Йорт ачкычын күршеләрендә калдырып, иртә таңнан юлга кузгалды Суфия. Башта бәхилләшер өчен юл буендагы зиратка сугылды. Әтисе Заһретдиннең каберен эзләп тапты. Әнисеннән ерак түгел генә җирләгәннәр икән. Сеңлесе Сәрия дә әтисе янәшәсендә генә. Әнисенең кабер чардуганын сыйпады.

Миңа гомер биргән әнием, Суфия исемле кызың барлыгын да белмичә якты дөньядан китеп барган әтием, урыныгыз җәннәттә булсын! Сеңлем Сәрия, син дә тыныч ят! Туганым икәнеңне дә белмичә, синең улыңны үстердем. Аңа әни булдым, бик яраттым үзен. Тәкъдир шулай язгандыр. Миңа рәнҗеп ятма! Сезгә хәер-догада торырмын.

Күңеленә килгән уйларын кычкырып әйтмәде, сүзсез генә дога калды.

...Суфия утырган поезд Урал якларына юл алды. Бу сәфәрнең югалган бәхетенә янәдән илтүче юлның башы икәнен дә, еллар буе госпитальләрдә дәваланып, кабаттан «кеше» булган Ванясы белән балалар йортында табышасын да белми ул әлегә.

PRESSA.RU



*Казан кичләре*

*Хәсән Туфан шигыре*
*Сара Садыйкова музыкасы*

*Кил әле, Иделнең җиләс җиле,*
*Юлларга чәчәкләр сип әле.*
*Ак булып, саф булып истә калсын*
*Казанның кадерле кичләре.*

*Туган ил чакырган зур юлларга*
*Китәрбез таңнарда без моннан.*
*Озатып калырсың безне, Казан,*
*Баласын очырган кош сыман.*

*Яшәрбез туган җир туфрагында,*
*Кырларда, Иделдә-диңгездә.*
*Исән-сау булсыннар балалар, дип,*
*Хәерле юл телә, Ил, безгә.*

*Иделгә сузылган айлы юлдан*
*Тын гына, моң гына җыр ага.*
*Сагынырбыз, дуслар, бу кичләрне*
*Чәчләргә чал кергән чорда да.*

*Ал гөлләр сибегез безнең юлга,*
*Иделнең иртәнге җилләре.*
*Мәңгегә, гомергә истә калсын*
*Казанның кадерле кичләре.*

# КАЗАННЫҢ КАДЕРЛЕ КИЧЛӘРЕ

Бу җырны кайларда гына җырларга туры килмәде! Ерак-ераклардан Казанга кайтып килгәндә, поезд тәгәрмәчләре тукылдавына кушылып, авыз эченнән генә шушы җырны көйлим. Нииндидер күтәренкелек тә, сагыну да, яшьлеккә хас ашкыну да бар анда. Озакламый Казанга кайтып төшәсемне күз алдыма китерәм. Хатыным Рәзилә белән дә поездда, менә шушы җыр яңа гына чыккан көннәрдә танышкан идек... Шуның белән дә кадерле әле ул миңа.

Ә инде Җир шарының әллә кайдагы Африка кыйтгасында, Тунис, Гыйрак, Сенегал кебек дәүләтләрдә Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән концертлар куеп йөргәндә үзебезнең «Арча»ны сузып җибәреп (үзем Арчаныкы булгач соң! – *Ш. Ә.*), йөрәк ярсуын басам. Юк, «Казан кичләре» ныграк туры килә бугай: «Исән-сау йөрсеннәр балалар, дип, / Хәерле юл телә, Ил, безгә...» Өчәр айга гастрольләргә чыгып китәбез.

Дөньяның ерак илләренә барып җитәбез. Венгрия, Чехословакия, Италия, Финляндия, Төркия, Японияләр... Ләкин безнең Казан барысыннан да матуррак, ягымлырак, яктырак сыман. Минем өчен «Казан кичләре» сагыну җыры ул, Казаныбызга мәдхия кебек. Концертларда «Казан кичләре»н җырлаганда, залның да минем дулкынга кучүен, җырга кушылуын тою күңелгә рәхәтлек бирә.

«Казан кичләре»н күп җырчылар җырлады. Хәзерге җырчылар да аны бик теләп үз репертуарына ала. Ә ул җырны иң беренче башкаручы мин идем! Авылдан чыгып китеп, профтехучилищега укырга кердем, слесарь һөнәрен үзләштереп чыктым. Заводта эшләгәндә Сара Садыйкова җитәкләгән М. Горький исемендәге үзешчәннәр клубындагы халык хоры мине магнит кебек тарта башлады. Кичләрен гел шунда чыгып чабам. Шулкадәр күп халык йөри иде анда! Сара апа үзе усал, үзе күңелле кеше иде. Ни уйлый, шуны маңгаеңа бәреп әйтә! Сүгеп тә ташлый, мактап та куя. Бик дус идек аның белән. (Сара апа тәкъдиме белән 1963 елда Казан музыка училищесына укырга кердем. Аны тәмамлагач, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә килдем. Тормышымда чын мәгънәсендә остазым булды ул. – *Ш. Ә.*) Минем җырлавымны ярата иде. Ул вакытта кесә телефоннары юк, кайчак айлар буе да гастрольләрдән кайтып кермибез. Сара апаның: «Мин сине эзләп таба алмыйм, кайда йөрисең син?» – дип язган хатларын да алырга туры килгәләде. «Өч кенә җырчы бар минем өчен, Илһам Шакиров, Рафаэль Ильясов, берсе – син!» – дип, мине үсендереп тә җибәрә иде ул. Әле дә хәтерлим, 1972 ел иде. Сара апа, үзе пианинода уйнап, үзе җырлап, безгә өр-яңа җыр тыңлатты: «Казан кичләре»! Шигыре – Хәсән Туфаннныкы, ди! Шундук чал чәчле шагыйрь күз алдына килеп басты. Казан белән саубуллашып, ерак-еракларга киткәндә аның йөрәгендә дә сагыш, ярату, өмет, хыял уты дөрләгәндер, күңел кылларын чиртеп алгандыр. Карашы Иделгә сузылган айлы юлны, ал гөлләрне, кичке Казанны сөеп үткәндер. Сара апа шагыйрьнең менә шул халәтен сиземләп көйгә салган. Сүзләре дә, көе дә күңелләрне айкый, хыял канатында әллә кайларга очыра, кабат-кабат тыңлыйсы килә! Сара апа үзе дә илһамланып, хисләнеп җырлый. Без, сихерләнгәдәй, аңа кушылабыз, отып каласыбыз килә. «Казан кичләре» синең җыр булыр, Шамил!» – диде Сара апа. Исемдә, Фәхри абый Насретдинов: «Сара аны миңа бирәм дигән иде бит», – дип, миңа үпкәләп тә йөрде әле. Мин дә үҗәт: «Ул бит үзе кулыма тоттырды», – дим... Исмай ага Шәмсетдинов радиода тавыш режиссеры булып эшли иде. Аңа барып яздык. Җыр бик популяр булып китте. Аны яшьләр, студентлар җыры дип тә йөртә башладылар.

Тагын бер матур хатирә. Нәкъ шул елларда Г. Камал театрында Батулланың «Өчәү юлга чыктык» драмасын куярга әзерләнәләр иде. Төп рольләрне әле яңа гына Ленинградтан укып кайткан яшь артистлар башкарачак, диләр... Спектакль куелып бетә язганда да музыкаль өлеше әле хәл ителмәгән була. Төп рольдә уйнаучы Шамил Бариев бер көнне репетициягә гитарасын алып килә. Тәнәфес вакытында ул гитара кылларына чиртә-чиртә... «Казан кичләре»н җырлый. Куела торган бу пьеса да яшьләр турында. Геройлар – әле яңа гына диплом алган яшь укытучылар, журналистлар. Алар бергә укыган дусларын, университетны, Казанны калдырып, эшкә китәчәкләр. Казанны ташлап китү авыр, шул ук вакытта күңел яңа җирләргә дә ашкына. «Казан кичләре» җыры, әйтерсең, нәкъ менә шушы хыялый, романтик җаннар өчен махсус язылган! «Менә шушы җыр кирәк иде безгә!» дип, спектакльнең режиссеры Празат Исәнбәт Сара Садыйкова музыкасын спектакльнең увертюрасы, лейтмотивы итеп билгеләгән дип сөйләделәр... Спектакльдән соң тамашачылар урам буйлап «Казан кичләре» җырлап кайттылар. Студентлар төзелеш отрядларына, экспедицияләргә киткәндә дә, «Ягымлы яз» фестивальләрендә дә гел «Казан кичләре» яңгырады.

Шамил ӘХМӘТҖАНОВ,
җырчы, Татарстанның
халык артисты.



■ Шамил Әхмәтҗанов *(сулдан икенче)* иҗатташ дуслары белән.

PRESSA.RU



# 16+ ХАТЫН-КЫЗ – ҺАВА!



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

**Раил САДРИЕВ,**
**Буа дәүләт драма театры директоры, режиссер, конферансье;**
**өйләнгән;**
**улы бар;**
**гаилә стажы — 28 ел.**



**1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Йөзенә, бигрәк тә күзенә. Рәссам (буш вакытларда картиналар иҗат итәм), иҗат кешесе буларак, ямьсез йөзләр булмый, дип саныйм, ә менә нурлы күзләр сирәгрәк очрый. Хатыным Эльмирада да шул нур җәлеп итте.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Хыянәттән гайре барысын да гафу итеп була, дип уйлый идем. Озак еллар балабыз булмады безнең. Тикшерелмәгән табиб калмагандыр. Икегез дә саусәламәт, диләр, ә тансык сабый һаман юк... Мин инде килешә дә башлаган идем бугай. Тик хатынымда әни булу теләге шулкадәр зур иде ки, ниһаять, безгә дә Ходай шундый бәхетне бирде. Шуннан соң минем тормыш кыйммәтләрем үзгәрде: ана булган хатынның бөтен тискәре сыйфатларын гафу итәргә мөмкин.

**3 Ә нәрсә өчен Сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Ирне санга санамаган, битараф хатынны.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...**

– Әйе, без өйдә – ир, эштә – ат. Ат кебек эшләп кайтканыңны пөхтә җыештырылган өйдә тәмле аш белән көтеп алучы илһамландыручың булса гына, ир булып була.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Минем әти белән әни (мәрхүмә) гомер буе бер-берсенә «дус» дип эндәштеләр. Бик тату пар иде алар. Әни өчен әти бердәнбер дус та, сердәш тә булды. Ә әтинең, районда эшләгән җитәкченең, аралашу даирәсе киңрәк булганга, дуслары күбрәк иде, билгеле, әмма сердәше шулай ук әни булды кебек. Йокларга яткач та озак вакыт сөйләшеп ятулары хәтердә. Ир белән хатын арасында андый якынлык сирәк очрыйдыр ул. Үз гаиләмә килгәндә, без – ир белән хатын.

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?**

– Хәтерләмичә?! 1988 елны Толымбайда Яңа ел каршылагач, Эльмираны Буага озата киттем. Җәяүләп. Төнге юл... Тулган ай... Бөтен дөнья көмеш нурда коена... Мәхәббәттән баш әйләнгән! Суыкны да сизмибез. Урманга җитәрәк япан кырда: «Чык миңа кияүгә», – дидем. Риза булды. 8 километр җәяү илтеп куйдым. Очраша башлавыбызга ике айлап вакыт үткән иде. Май аенда өйләнештек. 21 яшьтә.

**7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?**

– Моны Зигмунд Фрейд әллә кайчан исбатлаган бит инде! Булачак хатынымда әнидәге турылыкны, тугрылыкны, ирне санлау кебек сыйфатларны күрмәсәм, өйләнмәгән булыр идем. Ә идеаль вариант – хатын-кыз һава кебек булырга тиеш: ул үзе күренми, әмма аннан башка яшәү мөмкин түгел. Тик моны яши-яши генә аңлыйсың.

**8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Төрле гаилә модельләре бар бит. Кайбер ирләр авторитар әниләр тәрбиясеннән туп-туры шундый ук хатыннар кулына күчә. Алар башканы белми, аларга шулай уңайлы. Хатын-кыз таба, хатын-кыз дөнья арбасын тарта. Ә болар ияреп баручылар, кушканны гына эшләп йөрүчеләр. Мин «подкаблучник» түгел. Берара хатыным күбрәк хезмәт хакы ала иде – совет акчасы белән 190 сум. Ә үземне ир итеп хис итү өчен миңа бөтен яклап өстен булу мөһим, мал табуда – аеруча. Шуңа күрә ул чор минем өчен акчаны тагын да күбрәк эшләргә, хатынны «узарга» стимул булды.

**9 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Уңай карыйм. Хисләрәк кеше тизрәк белдерә мәхәббәтен. Безне кем ярата, без шуны яратабыз, диләр бит. Ничек кенә карасак та, хатын-кыз үзенә ошаган ир-атка симпатиясен беренче булып белдерә. Минем дә шулай. Эльмираның, сүз башлап: «Сезнең тавышыгыз Высоцкийныкына охшаган», – дип әйтүе минем өчен гашыйклыкка «яшел ут» булды. Яратуыңны яшереп, үзе сизсен, дип йөрү заманалары артта калды. Бүгенге яшәешнең темплары бик югары, җәмгыятьтәге процессларга тизләште – соңга калуың бар. Ә замана яшьләре бу нисбәттән бөтенләй баш ватмый. Моны җиткән егет әтисе буларак әйтәм.

**10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санныйсыз?**

– Кыяфәт, буй-сын, үз-үзенә ышану, дәрәҗә.

**11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?**

– Эчке дөньяма игътибар көтәм.

**12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.**

– Мәзәк. Диварда игълан: «Өйләнергә телим. Чибәрләрнең бимазаламавын сорыйм. Тарта алмыйм». Чибәрләрне үз янында тоту өчен акча кирәк, көчле һәм акыллы хатын-кыз янында үзеңнең ахмаклыгың ачыграк күренә, дип курка ир-атның байтагы. Юк, курыкмыйм. Хатын-кызның чибәрлеге дә, көчлелеге дә безне, ирләрне, яхшырак эшләргә, күбрәк белергә, үз өстеңдә эшләргә дәртләндерә.

**13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?**

– Кояш белән Ай кебек... Ир-ат чынбарлыкны объектив кабул итә, хатын-кыз – хисләр аша. Логикасы да шуннан килеп чыга: хатын-кыз тоемлауларына карап нәтиҗә чыгара, шуңа үзе генә ышанып калмый, сине дә ышандырырга тырыша. Килешмәсәң, үпкәли.

**14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Михалков әйткәнчә, һәр хатын – Ходай биргән бүләк – бөтен кимчелекләре һәм уңай сыйфатлары белән, ә минеке – укытучы да әле. Ә мин – мәңгелек укучы. Ходай миңа зур сабак бирергә ниятләгән бугай – укытучылар белән чорнаган: әти-әни укытучылар, туганнар, инде хатын да... Ә укытучылар – аерым категория кешеләр: тәнкыйтьләргә яраталар, үзләрен тәнкыйтьли башласаң, син тәнкыйтьне күтәрә белмисең, диләр. Канатланып, хыялларны тормышка ашырам дип йөргәндә, тәнкыйть ишеткәч, сөмсерең коела, эшкә дәрт сүнә. Без, ирләргә, хатыннарыбызның рухландыручы булуы бик мөһим шул.

**15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...**

– Сугар идем, – булды кызган чаклар, / Сугып кына кеше үзгәрми. / Тоз-борычлап берне әйтер идем – / Сүз ярасы китми, төзәлми. / Инде тагын нишләргә соң, диеп, / Аранымы әллә өзәргә? – / Галәм киңлегеннән дәшә акыл: / Яшим икән – кирәк түзәргә!

Шагыйрь Илдус Гыйләҗевнең бу шигырь юлларына күп ир-атлар ярсуы сыйгандыр. Тик хаклыгыңны исбатлаудан мәгънә юк, хатын-кыз барыбер үз сүзен бирми. Вакыты белән хәйләгә күчәргә туры килә: ризалашкан булам, ләкин үземчә эшлим. Бүтән планетадан булган хатын-кыз янында ир-ат безнең хөкүмәт кебек булырга тиеш: хаталарны танымаска, вәгъдә иткәнне эшләмәскә. Ә чынлап әйткәндә, юл куймый мөмкин түгел. Шулай булмаса, гаиләне саклап булмый. 28 ел яшәгәннән соң мин аерылышуның 8 ел яшәгәнгә караганда тизрәк булырга мөмкинлеген аңладым. Сират күперен кичкән кебек бик авыр вакытларым булды, хатыным аларга түзде, терәгем булды. Шундый сынаулардан соң мөнәсәбәтләр цементлангандыр, дип уйлый идем. Ә хәзер юк кына аңлашылмаучылыкларның да кайтарып булмас-тай нәтиҗәгә китерүен аңлый барам. Ир-ат белән хатын-кыз мөнәсәбәте, күпме генә яшәсәң дә, бертуктаусыз хезмәт сорый.

Тормышта төрле этаплар була. Без бүген Эльмира белән шуларның чираттагысын кичерәбез – улыбыз урта мәктәпне тәмамлагач, хатын да Казанга күченде: синең гастрольдән кайтуыңны кайда көтсәм дә бер түгелме, өчебез өч тарафта яшәгәнче, ичмасам, бала белән бергә булырбыз, ди. Минем дә эшем башкала белән бәйле. Өч йортка шулай яшәп яткан көннәр: Буада, Казанда, туган авылым Толымбайда.

**16 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.**

– Әйткәнемчә, хатын – укытучы кеше, мәктәп эше – тавык чүпләп бетерә алмаслык. Шулай да кайткан төшемә тәмле ризыклар пешереп куярга тырыша. Пешмәсә дә, трагедия ясамыйм, кафега барам – үз кафеларыма – анда һәрчак тәмле ризык көтә. Үзем генә булсам да, ачтан үлмәячәкмен – тиз генә тамак ялгарлык нәрсә өлгертеп ашыйм. Инде менә вакыты булып та диванда кырын ятса... андыйны кичерә алмыйм – «тозлысы» да булачак, «борычлысы» да. Гомумән, эшсезләрне яратмыйм. Төш вакытында черем итеп алучыларны да аңламыйм. Үзем барлык максатларымны тормышка ашырырга вакыт җиткерә алмаганга, аны ничек шулай бушка әрәм итәргә мөмкинлегенә аптырыйм! Бәлки, сәламәтлек өчен кирәктер дә...

**17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

– Башта бездә дә булгалады ул хәлләр. Мөмкинлек булганда, көтәсең. Түземлек төкәнгәч, калдырып китә идем. Биш ел эчендә өйрәнде тагын – минуты белән чыгып баса.


Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU





# БАХМАЛЬ







Фото: дизайнер Нилуфәр Абдуваәлиева архивыннан

**Татарларның милли киемнәрендә һәрчак «шәрыкча» җете чәчәкле тукымалар, катлаулы һәм бай бизәкләр төшерелгән баш киемнәре, төрледән-төрле аяк киемнәре, сәнгать югарылыгындагы зәркән бизәнү әйберләре, бер-берсен тулыландырып һәм үзара яраклашып, кабатланмас халык иҗаты үрнәкләрен тудырган.**

Халыкның бигрәк тә шәһәрдә яшәүче таза тормышлы катлавына урта гасырларда бәрхет, атлас, әдрәс, бикасаб, бахмаль, бинарес кебек шәрык тукымалары үтеп керә башлый. Бу тукымалар – тотрыклы мул тормыш, зирәклек, байлык символы. Шәрык тукымалары, грузин шигърияте яки борынгы грек мифлары кебек үк, халыкның кабатланмас бай мирасын чагылдырган. Тукымаларның бәһасе алтынга, кыйммәтле асылташларга тиңләштерелгән. Хакимияттә утыручылар, югары даирә кешеләре ефәк, парча, бәрхет, бахмаль тукымадан тегелгән киемнәрдән йөргән. Кемнең кайсы катлаудан булуын, үзенчәлеген ассызыклап күрсәткән алар. Бүгенге көндә незберек зәвыклы кешеләр шәрык осталарының сәнгать әсәрләренә торырлык кулдан тукылган тукымаларын өр-яңадан ачтылар. Тукыманың һәр метрын әзерләүгә киткән вакыт һәм сарыф ителгән көчне тукучының җанын, иҗат ялкынын, гасырлар зирәклеген бармак очларыннан күчереп төшергән тылсымлы бизәкләре белән чагыштырырлыкмыни?!

«Бахмаль» яки кулдан эшләнгән вельвет – «икат» бизәкле йөнтәс ефәк тукыма – бары патшаларныкы гына саналган. «Икат» бахмаль Төркестанда узган гасырның 1900–1907 елларында тукылган. Күбесенчә югары катлау кешеләре – патшалар, ханнар арасында дәрәҗәле йөргән. Кул хезмәте күп керү һәм шактый ефәк тотылу аркасында бик кыйммәт торган, сатуга да сирәк чыккан. Татарның билгеле кешеләре, сәүдәгәрләр бу затлы тукымадан биһуш калып, кыйммәтле, затлы бүләк сыйфатында хәләл җефетләрен сөендергәннәр.

Бахмаль тукыманы җитештерү технологиясе совет чорында юкка чыга. Бары 1990 елларда гына Үзбәкстанда ата-баба һөнәрен дәвам итүче тукучылар гаиләсендә тукыма әзерләү технологиясе могҗиза булып яңадан торгызыла.

Атлас, әдрәс, зандона, алоча. Ачык төстәге зиннәтле бу тукымалар эссе Шәрыкны гына әсир итеп калмый, тыенкы, салкын Көнбатыш та соклана аларга. Сокланмый мөмкин дә түгел!

Шактый катлаулы, бары кул хезмәте белән генә башкарыла торган туку – аерым төсләргә аралаштырып манып бару өчен бер тотам җепне чорнап бәйләү ул.

Бахмаль – бәйрәмнәрдә генә киелә торган кыйммәтле киемнәр өчен кулланылган тукыма төре. Аны Бохарада гына җитештергәннәр. Ә Бохара ханлыгы гомер-гомергә сәнгать әсәрләре дәрәҗәсендәге әйберләре белән дан тоткан. Туку, текстиль дә шуңа караган. Әлеге тукымадан тегелгән киемнәр бөтен Үзәк Азиядә дәрәҗәле саналган.

Тукыманың йөнтәс ефәгенә бик күп ефәк китә, ә аның нигезен ефәк һәм мамык тәшкил итә. Шуңа күрә бахмальне «ефәк бәрхет» дип тә йөртәләр. Кулдан тукылган 100 процентлы ефәк бахмаль була алмый, аның составында мамык та бар. Бу җитештерү технологиясе мөмкинлекләре белән бәйле. 100 процентлы ефәк бәрхетне итальян һәм немец станоклары гына чыгара. Ләкин бу инде кулдан тукылган тукыма була алмый. Үзбәкләр 100 процентлы ефәк бәрхетне җитештерми, җиһазларының



андый куәте юк, тукымага мамык та катнаштырыла. Бахмаль кебек кулдан тукыла торган катлаулы тукыманы җитештерү күп хезмәт сорый, үзе бик кыйбатка төшә, әмма ихтыяҗ зур аңарга. Урта Азиядә бүген 100 процентлы бахмаль җитештерүгә йөз тотканнар. Казан, Татарстан хатын-кызларына элеккеге сылу кызларыбыз кебек әлеге үзенчәлекле тукымадан ясалган аксессуарлар белән көязләнеп йөрергә җай чыга дигән сүз бу.

Алар барысы да кайчандыр Бөек ефәк юлы аша безнең Казан ханлыгына китерелгән. Әбиләребезнең әбиләре зиннәтле шәрык ефәгенә, бәрхетенә төренеп һәм аларга үзләреннән дә милли бизәкле чигүләребезне өстәп, татар халкының гамәли сәнгать үсешенә уңай мохит тудырганнар.

Рәмзия КАШАПОВА


**«ЭЛЬ-СТУДИО»**

**дизайнерлык остаханәсе тәкъдим иткән калфак, хәситә, камзул, кечкенә сумкаларны, кулдан ясалган бизәнү әйберләрен, актуаль төсләре белән генә түгел, югары сыйфаты, модалы һәм кабатланмас рәсемнәре, көннән-көн киңрәк колач ала барган заманча милли стиле белән дә аерылып торган киемнәрне түбәндәге адрес буенча сайлап алырга була:**
**Казан, Каюм Насыйри урамы, 40.**
**Телефон: 89372891054.**



РЕКЛАМА

PRESSA.RU

# МЕЗОТЕРАПИЯ: ЗЫЯНМЫ, ФАЙДАМЫ?



**Гомер-гомергә хатын-кыз матур күренергә омтылган. Бу бүген дә шулай, киләчәктә дә шулай булачак. Хәзер бит тиресен яшәртүнең бик күп заманча ысуллары уйлап табылган. Табиб-дерматокосметолог Лилия ГАВРИЛОВА безгә шушы күптөрле чараларның иң уңышлыларын сайларга ярдәм итәр.**

Яшь барган саен, тире сула, нәфислеген югалта, ничек кенә теләсәк тә, ул инде яшь чактагы кебек матур күренми. Тиренең сулуы, җыерчыклар пәйда булу – табигый хәл. Ә бит хәзерге медицинада картаюны кичектерә торган чаралар да бар. Шуларның берсе – мезотерапия.

Мезотерапия – биттәге косметик җитешсезлекләрне дәвалый торган ысул. Хәер, бит тиресе генә түгел, тән тиресе дә картая. Шул чагында да мезотерапия ярдәмгә килә. Аның ярдәмендә тәндәге төрле туткылларны, тимгелләрне бетерәләр, чәч коелуын туктаталар. Артык симерүдән, целлюлиттан да булыша ул. Бу ысул ярдәмендә хәтта яшүсмерләрнең бетчәләрен дә дәвалыйлар. Монысы бигрәк тә мөһим, чөнки косметология өлкәсендә кулланылучы күпчелек чаралар яшь тирене дәвалау өчен бармый.

Мезотерапия ярдәмендә дәвалаганда тире астына җибәрелүче коктейльнең составы һәр очрак өчен аерым була. Һәр препаратның организмга тәэсирен, аларның күләмен, кая кадарга кирәген фәкать табиб кына билгели. Мезотерапия ысулы белән тән тиресенә кирәк кадәр генә витаминнар, дарулар, эласти, коллаген матдәләре, макро һәм микро элементлар, микропептидлар кертелә.

Тире астына ясала торган инъекцияләр – хирургия ярдәменнән башка гына тирене яшәртү, матурлыкны, яшьлекне шактыйга озайту чарасы ул. Косметология өлкәсендә мезотерапияне, гадәттә, 25 яшьтән өлкәнрәкләр өчен кулланалар. Бу ысулның җитди кимчелекләре дә, зарары да юк.

**Мезотерапияне кайчан кулланырга ярамый:**

- бит тиресендә үлекле ялкынсыну булганда;
- герпес азып киткәндә;
- йөкле ханымнарга;
- бала имезүчеләргә;
- мезококтейль составына кергән берәр препаратка аллергия булганда.

**! Мезотерапия белән шөгыльләнүче оешманың медицина хезмәте күрсәтү өчен Сәламәтлек саклау министрлыгыннан бирелгән лицензиясе булырга тиеш.** Клиникалар базасында эшләүче мезотерапевтлар ышанычлы. Күпчелек квалификацияле табиблар санаторийларда, хастаханәләрдә, пластик хирургия үзәкләрендә эшли. Кайчандыр клиникада эшләп, хәзер эстетика өлкәсенә күчкән табиблар, мезотерапиягә өйрәнгәннән соң, искиткеч яхшы нәтиҗәгә ирешәләр.

**! Кычкырып торган тышкы рекламага ышанмагыз.** Әгәр дә сезне инжекторлар (мезотерапия өчен махсус пистолетлар) белән кызыктыралар икән, димәк, бу оешмада мезотерапиянең асылын аңлап бетермиләр. Заманча җиһазлардан битәр, бу өлкәдә табибның тәҗрибәсе мөһимрәк.

**! Эшкә керешкәнче, табиб башта нинди препарат кадарга җыенуын, ни өчен шушы препаратны сайлавын, аның ни рәвешле тәэсир итүен аңлатырга тиеш.** Тәҗрибәле табиб препаратның нинди зарары булу ихтималын да, андый очракта нишләргә кирәген дә аңлатыр. Үз эшен белеп башкарган кеше нинди дарулар белән эшләвен яшерми, һәм кайсы даруны нинди күләмдә кулланганын журналга теркәп куя.

**! Белгечнең кайда укуы белән кызыксыныгыз.** Дипломына күз салыгыз. Ул дөрестән дә табиб булырга тиеш. Табиб никадәр тәҗрибәлерәк, куллары никадәр «йомшаграк» булса, көтелмәгән күңелсезлекләр дә азрак булачак.

**! Нинди өзлегүләр килеп чыгу ихтималын белешегез.** Берни булмаячак, дип ышандыралар икән, мезотерапияне алар бик начар белә дигән сүз. Даруларның кайсысының да берникадәр тискәре сыйфаты була. Кагыйдә буларак, дару никадәр көчле булса, зарары да күбрәк.

**! Инъекцияләр ясау өчен рәсми теркәлү узган даруларны гына кулланырга ярый.** Хәтта законлы дарулар арасында да ясалма булганнары, сыйфатсызлары очрый, законсызлары турында инде әйтеп тә торасы юк.

**! Инъекция ясарга керешкәнче, әлеге даруга карата сездә аллергия булу-булмавы ачыкланырга тиеш.** Аны проба ясап ачыклыйлар. Әгәр дә инде сездән аллергия турында сорап та карамыйлар икән, бу сагайтырга тиеш!

Мезотерапия — матурлык салоннарында һәм клиникаларда иң еш кулланылучы чараларның берсе. Популяр методика турында халыкта әллә никадәр имеш-мимешләр дә йөри. Аларның кайсы чын, кайсы уйдырма-ялган гына соң?

## *Бу кызык.*

Эстетик медицинага мезотерапия методикасы гериатрлардан күчте (гериатр – «өлкәннәр» табибы. Ул өлкән һәм олы яшьтәге кешеләрне дәвалау белән шөгыльләнә). Өч тармаклы нерв ялкынсынганда, нерв тирәли прокаин кадап чыксаң (аны блокада ясау дип тә йөртәләр), бит тиресенең сизелерлек шомаруын, җыерчыкларның язылуын күрә алар. Менә шуннан соң инде бу методиканы тирене яшәртү өчен дә куллана башлыйлар.

### *Беренче миф*

Мезотерапия белән карт тирене генә дәвалыйлар.

Бу дөрес түгел. Югарыда әйтелгәнчә, төрле витаминнар белән баетылган инъекцияләрне яшүсмерләргә дә кадыйлар. Тагын бер мөһим әйберне онытмагыз: тиренең картаюы инде 25-30 яшьләрдә үк күренә башлый. Нәкъ менә шушы чорда мезотерапия белән дәвалана башласаң яхшы. Косметология өлкәсендәге иң «миһербанлы» процедуралардан санала ул.

### *Икенче миф*

Препаратларның дозасы артып китү куркынычы бар.

Мезотерпия белән дәвалаганда организмга керткән препаратларның дозасы артып китү куркынычы бөтенләй дә юк. Ник дисәгез, процедуралар атна-ун көнгә бер генә ясала, һәм бер кадаганда препарат бары тик бер генә дозада кулланыла. Гадәти дәва чаралары белән чагыштырганда, бу ысулның бавыр-бөерләргә зыяны бик күпкә азрак.

### *Өченче миф*

Уколлардан соң үз хәленә кайту өчен тирегә берничә көн вакыт кирәк. Процедура үзе дә бик авырттыра торган.

Без бит операциядән соң калган җөйне өзлегү дип атамыйбыз. Ул җөй ялкынсынса, үкләп шешсә, канаса – менә ул чакта өзлегү булыр иде. Мезотерапиядән соң тиренең беразшешенеп китүе – методика үзенчәлеге. Бер-ике көннән бетә ул. Әмма бу шешенүне дә булдырмый калырга мөмкин һәм хәтта кирәк тә. Моның өчен авыртуны баса, канны туктата торган дарулар кулланалар.

### *Дүртенче миф.*

Тора-бара мизотерапиягә күнегәләр.

Косметологиядә мин белгән бер генә методика да организмның күнегүенә китерми. Монысы инде – чынлап та миф.

PRESSA.RU



**Бизәүче, тарихчы Нурзия ханым — белеме буенча этнолог. Егерме елдан артык шәһәребезнең Яңа Савин районындагы Балалар иҗаты үзәгендә сәнгать студиясен җитәкли. Татар халкының декоратив һәм сынлы сәнгатен өйрәнү буенча авторлык программасы булдырып, милли чигешләрне, нәкыш-бизәкләрне өйрәтүне мәгариф системасына кертергә тырышып йөрүчеләрнең берсе генә түгел, беренчесе дә ул. Балалар өчен аның «Әбиемнең сандыгы», «Тылсымлы бизәк», «Тылсымлы энә», «Татар сынлы сәнгате дәресләре» һәм башка исемдәге китаплары бар. Киләчәк буыннар борынгы үрнәкләрне, борынгы сәнгатьне онытмасын дип җан атып йөрүче Нурзия ханым бүген журнал укучыларыбызны күләмле чәчәк чигәргә өйрәтә.**






Мастер-классны Нурзия СЕРГЕЕВА үткәрә.

# КҮЛӘМЛЕ яки 3D ЧИГҮ







***Кирәк:***

- төрле төстәге мулине (секциялəп буялганын сайласагыз яхшырак);
- мулине төсенә ярашлы бәз тукыма (укучыларга ачыграк күренсен өчен без ак төстәге бәз кулландык);
- озынча пыяла сәйлән (стеклярус);
- чигү энәсе;
- киерге.

***Эш барышы:***

■ бәз тукымага гади карандаш белән аерым-аерым чәчәк таҗлары ясыйбыз. Араларын шактый ерак калдырыгыз, соңыннан бу таҗларны аерым-аерым кисәсе дә була. Шундый биш-алты таҗ кирәк булыр. Табигатьтә чәчәк таҗлары барысы бертигез зурлыкта булмый, бер-икесен зуррак, бер-икесен чак кына кечерәк итегез.

■ Чигү энәсенә җеп саплап, һәр таҗны ике яклы шома чигү белән чигәбез. Ике яклы дигәнебез – чигү җебе таҗның уң ягын да, сул ягын да капласын. Бер яклы итеп, уң яктан гына чиксәң дә була, шулай да ике яклысы күркәмрәк килеп чыга.

■ Таҗларны чигеп бетергәч, кечкенә кайчы белән һәркайсын аерым-аерым кисәбез. Тукыманы төбеннән үк кисәргә тырышыгыз, шул ук вакытта чигү җебен дә эләктермәскә кирәк.








■ Хәзер безгә тукыма читен капларга кирәк, югыйсә чиккән чәчәгебез пөхтә күренмәс. Моның өчен энәгә чәчәк таҗыннан чак кына үзгә җеп саплап, таҗ кырыйларын тыгыз җөй белән типчеп чыгабыз (русча аны «обметочный» диләр). Беренче каттан гына җөегез тыгыз килеп чыкмаса, икенче кат типчергә мөмкин.

■ Һәрбер таҗ әзер булгач, чәчәкне җыябыз. Иң элек зуррак ике таҗны бер-берсенә тегеп куябыз. Аннары шуңа бер-бер артлы башка таҗлар беркетелә. Өске якка кечерәк таҗлар куела. Таҗ яфракларын кабарынкырак итү өчен аларны бераз җыерыбрак беркетсәң яхшы. Чәчәкнең серкәчләре җепкә тезелгән пыяла сәйләннәрдән ясала.

■ Әзер чәчәкне шома чигү белән чигелгән янчыкка беркетәбез. Соңыннан бу янчыкта кипкән үләннәр сакланачак. Төрле чигешләрне бергә кулланып, әнә шулай кызыклы композиция тудырырга була. Теләгән кеше аны брошка итеп түшенә кадап та йөри ала. Түшкә булмаса, башлыкка, шарф читенә... Кая гына беркетсәгез дә, бик күркәм булачак.


*Яна бәйге!*



# ӘНИЛӘР ҺӘМ НӘНИЛӘР!

«Сөембикә» журналы «Салават күпере» белән берлектә Сезнең өчен тагын бер бәйге игълан итә. Хәзер сез яраткан журналларыгызны балаларыгыз белән бергәләшеп укый һәм безнең өр-яңа гаилә рецептлары бәйгесендә катнаша аласыз!

■ Балагыз белән бергәләшеп аның иң яраткан ризыгын пешерегез.

■ Һәр әзерләү этабын язып һәм фотога төшереп барыгыз (фотода бергә булсагыз – яхшырак).

■ Фотоларны һәм рецептны «Сөембикә» һәм «Салават күпере» журналлары адресына җибәрегез (хатта исем-фамилия, яшегез, яшәү урыны һәм элемтә өчен телефоннарны язу һәм журналларга 2016 елның икенче яртыеллыгына квитанция күчермәсен беркетү зарури).

Иң шәп рецепт авторларын белер өчен 5 апрель көнне salavatkupere.com һәм syuyumbike.ru сайтларында онлайн тавыш бирү башлана.

Тавышларны кушу нәтиҗәсендә, 30 май көнне җиңүче билгеләнә. Тантаналы рәвештә бүләкләү 1 июнь көнне булачак.

Уңышлар сезгә, әниләр һәм нәниләр!

+0

РЕКЛАМА

PRESSA.RU



# БҮЛӘККӘ ТОРТ ТҮГЕЛ, ТАРТ!

**«Хатын-кыз галәме»нең кунагы — Татарстанның атказанган артисты Минвәли ГАБДУЛЛИН. Лаеш районының Имәнкискә авылында туып-үскән егет, артист булам дип хыялланып йөрмәсә дә, мәктәпне тәмамлагач, туп-туры Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтына юл тота. Язмыш дими ни дисең, ул елны аларның курсын Марсель Сәлимҗанов һәм Фәрит Бикчәнтәев кабул итә. Матур гәүдәле чибәр егетне студент вакытында ук Камал театрында куелган спектакльләргә чакыралар. 1995 елдан — Минвәли Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә. Бүген ул «Сөембикә» журналы укучыларына француз кухнясында бик тә популяр булган ачык бәлеш — тарт пешерергә өйрәтә. Кадерле ир-егетләребез! Бәйрәм көнендә яраткан хатын-кызларыгызны сөендерим дисәгез, тарт әзерли аласыз. Тәмле булуы өстенә, бик матур да күренә әле ул.**




***Кирәк:***

(камыр өчен)
- 150 г атланмай;
- 250 г он;
- 1 йомырка;
- 1 аш кашыгы салкын сөт;
- яртышар чәй кашыгы тоз һәм шикәр.

***(эчлек өчен):***

- 500 г фарш;
- 2 баш суган;
- 150 г яшел борчак (без катырылганын кулландык);
- 150 г кызыл, сары һәм яшел борыч (катырылган булса да ярый);
- 250 г кибет каймагы;
- 2 йомырка;
- тәменчә тоз, борыч.











***Эш барышы:***

■ әле генә суыткычтан алган атланмайны угычтан уып, он белән катнаштырабыз, шунда ук 1 йомырка сытабыз. Тоз белән шикәр комын да кушып, барысын бергә болгатабыз. Онлы валчык хасил булды. Шушы валчыкны куна тактасына бушатып, бер аш кашыгы бик салкын сөт өстибез һәм камыр үзләнгәнче кул белән әвәлибез.

■ Әзер камырны целлофан капка тыгып, суыткычка куеп торабыз, ярты сәгать «ял итсен».

■ Ул арада фаршка тоз-борыч кушып, яхшылап болгатабыз да, әстерхан чикләвеге зурлыгындагы чумарлар әвәләп, үсемлек мае салынган табада кыздырып алабыз. Ике ягы да кызарган чумарларны тәлинкәгә күчереп, бушаган табада суган кыздырабыз.

■ Орлыкларыннан арындырылган борычны юып, артык эре итмичә, шакмаклап турыйбыз. Яшел борчакны исә бүлмә температурасында бераз гына эретеп алабыз.

■ Камырны таба зурлыгына җиткәнче юкартып җәябез. Таба читеннән чыгып калганын кисеп алабыз. Төбе чәнечке белән берничә урыннан тишкәләнгән камыр өстенә пергамент кәгазе каплап, берәр төрле коры ярма (борчак яки фасоль булса, яхшырак. Ярма бозылыр дип курыкмагыз, аңа берни дә булмый) салабыз. Бу – камыр күпереп менмәсен өчен кирәк.

■ Әүвәл мичне 190 градуска кадәр җылытып, камырны 15 минут чамасы пешерәбез. Аннары, кәгазен алып, тагын 5 минут чамасы мичтә тотабыз.

■ Табаны мичтән алып, камыр өстенә башта кыздырылган суганны салабыз. Аның өстенә ит чумарларын тезәбез. Ит араларына яшел борчак сибәбез, борыч шакмакларын тезеп чыгабыз.

■ Каймакны бер савытка бушатып, 2 йомырка сытабыз. Тәменчә тоз белән борыч салгач, бертөрле генә сыеклык хасил булганчы яхшылап туглыйбыз.

■ Тарт өстенә йомыркалы каймакны агызып, тагын 30-35 минутка мичкә тыгабыз.

■ Тәмле дә, матур да, туклыклы да бәлеш була бу. Ашларыгыз тәмле, бәйрәмнәрегез ямьле булсын!



PRESSA.RU



**Никтер бу үсемлекне бездә бик киң кулланмыйлар. Югыйсә кешегә генә түгел, үзе үскән туфракка да файдасы бар аның. Сельдерейны кәбестә белән янәшә утыртсаң, аның исенә кәбестә күбәләге килми икән, ә тамырлары арасында җир суалчаннары оя корырга ярата.**



# СЕЛЬДЕРЕЙ ҮСТЕРӘБЕЗ

Сельдерей өч төрле була: яфрак өчен үстерелгәне, сабак өчен үстерелгәне һәм тамыразык буларак кулланыла торганы. Әгәр дә сату өчен булмаса, яфрак өчен генә аны аерым утыртасы да юк. Аштәмләткеч сыйфатында тамыр сельдерейның хуш исле яфракларын кулланып була.

Сельдерей озак тишелүче яшелчә. Өстәвенә, орлыклары да вак. Шуңа да аны безнең җирлектә уҗымга чәчеп кенә үстерәләр. Орлыкларны февраль ахыры, март башларында саерак киң савытларга чәчәләр. Туфракка күмдермиләр, өстеннән юка гына итеп ком бөркергә була. Беренче шытымнар ун көннән күренә башлый. Инде ике чын яфрагы чыккач, уҗымнарны 200 мл стаканнарга күчерергә кирәк (моның өчен бер кулланылышлы пластик стаканнар бик кулай).

Көннәр җылытып, кыраулар куркынычы беткәч, уҗымнарны түтәлгә чыгарып утырталар. Кайбер сортлар дүрт градуска кадәрге кыrauларга да түзә. Рәт араларын 30-35 см, үсемлекләр арасын 20 см калдырсаң әйбәт. Сельдерей иркенлек ярата. Тамыр сельдереен үстергәндә төп максат – йомры, эре тамыразык алу. Моның өчен әледән-әле кырый сабакларын өзгәләп торырга кирәк. Бу үсемлек август ахыры – сентябрь башында котырып үсеп китүчән, сабакларын да шул вакытта ешрак өзәләр. Яңгырдан соң төбен йомшартып, вакытында суын сипсәң, күзен сез шалкан шикелле эре, хуш исле тамырлар казып алырсыз. Сельдерей тамырын октябрь ахыры, ноябрь башларында казып алалар. Кышын алар бик яхшы саклана. Аны кишер, суган белән кыздырып ашларга кушалар. Ризыкка хуш ис, үзенчәлекле тәм бирә ул.

Сабак сельдереен үстерү өчен исә шактый тырышырга кирәк. Уҗымнарны үстерү, түтәлләргә күчерү эше тамыр сельдереен үстергәндәгечә. Бер генә үзенчәлеге: түтәлгә күчергәндә сабак сельдереен 10 см тирәнлектәге канауларга утырталар. Сабакларның озынлыгы 30-35 см булгач, аларны бергә бәйләп куялар. Әле бу гына җитми, өзеп алырга ике атна кала, яфрак очлары гына күренеп торырлык итеп сабакларны кәгазь белән дә төрәсе була. Сабаклар аксыл, сусыл булсын өчен эшлиләр моны. Кемдер балчык белән генә күмеп куя. Хәзер кайбер сортларны каплау ихтыяҗы юк, алар үзеннән-үзе агара. Сабак өчен үстергән сельдерейны кырауларга кадәр җыеп алырга кирәк. Суыткычта ике ай чамасы саклана әле ул.

Сельдерей сабагын ашларга, салатларга кушалар. Бер салат рецептын сезгә дә тәкъдим итәбез. Аның өчен 3 сельдерей сабагы, 2 әчкелтем-төчкелтем алма, 1 уч әстерхан чикләвеге, 2-3 аш кашыгы кибет каймагы, тәменчә тоз кирәк.

Сельдерей сабагын һәм төше алынып, кабыгы әрчелгән алманы шакмаклап турыйбыз (саламлап турасаң да була). Чикләвекне бераз ваклыйбыз. Барысын бергә катыштырып, тәменчә тоз сибәбез, каймак кушып болгатабыз. Теләгән кеше бераз салат яфрагы да куша ала.


**КУЧКАР.** Нәкъ менә шушы айда холкыгызның иң көчле яклары ачылачак. Сез тормышыгызның чын хуҗасы. Нәрсәнедер хәл итү, җитди мәсьәләләрне чишү өчен яхшы вакыт. Үзегез белән булган хәлләргә фәкать сез генә җаваплы.


**ҮГЕЗБОЗАУ.** Ныклык, үҗәтлек күрсәтергә туры килер. Кышкы йокыдан уянып, бар көчегезне салып эшләр вакыт. Үз сүзегездә нык торырга тырышыгыз, шул чакта уңышка ирешерсез. Күптәннән кул җитми торган эшләрне җиңел генә башкарып куярга җай чыгар.


**ИГЕЗӘКЛӘР.** Акча, табыш ягыннан бу ай бик уңышлы булырга охшап тора. Хаклы булуыгызны расларга кирәк булуы мөмкин, бигрәк тә 28-30 майда туучыларга кагыла бу. Яңа техника сатып алмый торыгыз, бу айда алган әйбернең ватылу ихтималы зур.


**КЫСЛА.** Яңа эшләр планлаштырсагыз, ахыры яхшы төгәлләнер. Эш алыштыру өчен дә уңай вакыт. Үз алдыгызга куйган максатларны яңадан ачыкларга туры килер. Бюрократия киртәләрен җиңеп чыгар өчен моннан да яхшырак вакытны табуы кыен.


**АРЫСЛАН.** Көчегез артуын тоярсыз. Нindидер яңа эшкә алыну теләге туар. Яңа һөнәр, һичьюгы берәр чит тел үзләштерү өчен яхшы ай. Тормышыгызда мөһим урын алып торган зур эшләрне бу айга ниятләсәгез, үкенмәссез.


**СӨМБЕЛӘ.** Апрельдә сезне акча мәсьәләсе генә борчыр. Ай уртасында максатларыгызга ирешүдә «яшел коридор» ачылачак, талантыгызны, сәләтегезне күрерләр. Нинди дә булса яңа эшкә өйрәнү өчен яхшы вакыт.


**БИЗМӘН.** Беренче урынга шәхси проблемалар һәм эшлекле мөнәсәбәтләр чыгар. Сезне кемдер сыный, аның ышанычын казана алсагыз, хезмәт баскычында югарырак үрләр яуларсыз. Тирә-юньдәгеләрнең, аеруча иргетләрнең киңәшенә колак салсагыз, отарсыз.


**ЧАЯН.** Тормышыгызда бик күп яңалык, кызыклы вакыйгалар көтелә. Яңа кешеләр белән танышырсыз, яңа идеяләр белән яшәрсез. Моның кадәр яңалыктан туеп китүегез дә ихтимал. Кечкенә генә низаглардан да сакланыгыз, алар, зураеп, чын дошманлыкка әйләнүе мөмкин.


**УКЧЫ.** Беренче карашка бер дә кирәкмәгән эшләр белән шөгыльләнәсез кебек тоелса да, нәкъ менә шулар аркылы үзегезне күрсәтү форсаты чыгар. Көтелмәгән күңелле хәлләргә тарырсыз, яңа мөмкинлекләр ачылачак.


**КӘҖӘМӨГЕЗ.** Киеренкерәк чор көтелә. Узган айда борчыган мәсьәләләр бу айда да бимазалар. Әлегә зур әйберләр һәм әҗәт алмагыз. Булган акчаларыгызны ераграк яшерергә тырышыгыз, югалту ихтималы бар.


**СУКОЯР.** Тиз һәм җитез булуыгыз соралыр. Күңелегезне һәртөрле яңалыкка әзер тотыгыз. Үзгәрешләр бездән сорап тормый, шуңа күрә аларны җиңел кабул итәргә тырышыгыз. Уйламаган җирдән ярдәм ирешер.


**БАЛЫК.** Файдалы элемтәләр урнаштыру өчен моннан да яхшырак вакытны табуыгыз икеле. Хыялыгызны тормышка ашырырга ярдәм итәрдәй кеше белән танышырсыз. Ул акча белән дә, киңәш белән дә булышыр. Әмма нәтиҗәсен тиз көтмәгез.

## Март та кабынган йолдызлар

### Татарстан



**Зәйнәп ХӘЙРУЛЛИНА** (22.03.1916–15.08.2010) – **музыка белгече, атказанган сәнгать эшлеклесе.**
Пермь шәһәрендә туа. Казан педагогика училищесын тәмамлап, немец теле укытучысы белгечлеге ала. 1932–1958 елларда Татарстан радиосында диктор, мөхәррир, әдәбият-сәнгать тапшырулары җитәкчесе булып эшли. 1950–55 елларда Казан дәүләт консерваториясенең музыка теориясе-композиторлык факультетында ирекле тыңлаучы булып йөри. 1944–1976 еллардан – Татар дәүләт филармониясендә. Берара Казан телевидениесе студиясенең директоры булып тора. 1962–1973 елларда Татарстан композиторлар берлегенең җаваплы сәркатибе вазыйфасын башкара. Татар тамашачысына шул чорлардагы күп кенә концертларны алып баручы буларак таныш. Татар музыкасын, җыр-музыка тарихын өйрәнүгә күп көч куйган шәхес.

### Россия



**Ирина Алферова** (13.03.1951) – **Россиянең халык артисты.**
Новосибирскида туып-үсә. Мәктәптән соң Мәскәү театр институтына укырга керә. Институттан соң аны берьюлы берничә театр эшкә чакыра. Алферова исә киноны сайлый, Василий Ордынский төшергән «Хождение по мукам» киноэпопеясендә Даша роленә алына. 1976 елда Ленин комсомолы исемендәге театрга эшкә урнаша. Монда булачак ире Александр Абдуловны очрата. Икесе бергә уйнаган «С любимыми не расставайтесь», «Предчувствие любви» фильмнарын тамашачы яратып кабул итә.

### Чит илләр



**Лайза Миннелли** (12.03.1946) – **актриса, җырчы.**
Әнисе – актриса Джуди Гарленд, әтисе исә режиссер Винсент Миннелли. Әнисе төп рольне башкарган «Старым добрым летом» фильмында уйнаганда аңа нибары 3 яшь була. 17 яшеннән әнисе белән бергә җырлар яздыра. Актриса булып танылудан әүвәл, җырчы булып таныла. Кинодагы беренче уңышын 1972 елда яулый: «Кабаре» мюзиклының киноверсиясендә җырчы Салли Боулз ролен башкара.
Бу роль аны «Оскар»лы да итә. 1976 елда әтисе төшергән «Дело времени» фильмында уйный. Ә 2010 елда «Секс в большом городе 2» фильмында үз-үзен уйнаган роле иң начар башкарылган роль буларак бәяләнеп, «Алтын кура җиләге» («Золотая малина») номинациясенә лаек дип табыла.

PRESSA.RU







# РӘСЕМ ХАНБИКӘСЕ

Лениногорскида ул күптән үз кеше инде. Олысы-кечесе аны «безнең рәссам!» дип йөртә. Тамара Ивановна Самойлова картиналарында – шул як, шул төбәк (Бәкер таулары, камышлы күлләре, көрткә чумган кышкы авыл), аның уңган-булган кешеләре (Ирина, Дамиралар), кашкарыйлар, сиреньнәр, хәтта сары көнбагыш чәчәкләре дә вазада ничек матур икән... Эчкерсезлек, күңел җылысы, җиңеллек, табигыйлек бөркелә алардан. Яратып кына шулай язып, тасвирлап була! Тамара Ивановна безнең якларны яраткан, димәк. Дөнья күреп, илләр гизеп, иҗатының нәкъ егәрле, чәчәк аткан чорында килеп төпләнгән ул нефтьчеләр шәһәренә. Калинин өлкәсенең Кимры шәһәрендә хәрбиләр гаиләсендә туган кыз кечкенәдән үк бу дөньяны алсу-зәңгәр төсләргә манып, хыялындагы әкияти тылсымны, якты нурны кушып, матур сурәтләр төшергән: күкләре аяз, офыклары киң, һәр рәсемдә кояш, чәчәкләр... 1964 елда Иваново сәнгать-педагогика көллиятен «бишле»гә генә тәмамлый. Аннары – Германиягә китүләр, хәрби частьта рәссам булып эшләү, «Советский патриот» газетасы белән хезмәттәшлек итүләр, Бранд шәһәрендә шәхси күргәзмәсе ачылу... Соңрак Киевтагы югары авиация училищесында да рәссам булып эшләп ала ул.

Тамара Самойлова 1974 елдан Лениногорскида. Чын-чынлап җитлеккән, абруй казанган рәссам булып өлгерүе дә шушы шәһәр белән бәйле. Ул инде СССР, Россия, Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы, Шамил Бикчурин исемендәге премия лауреаты, нефть төбәге рәссамнары арасында үзенә бер урын алып торучы талант иясе. Тамара Самойлова – киңкырлы рәссам: график та, монументаль әсәрләр дә иҗат итә, ташлар кырлау остасы да. Картиналары республика, төбәк күргәзмәләрендә катнаша. Лирик пейзажлар, җете натюрмортлар, төгәл күзәтүләр аша геройларының төс-кыяфәтен генә түгел, эчке кичерешләрен дә психолог кебек оста ачып салган портретлар күңелгә үтеп керәләр.

«Тормыш миңа үз эшем белән шөгыльләнү бәхетен бүләк итте, – ди Тамара Ивановна. – Бу чир дә, газап та, һәм бернәрсәгә алыштыргысыз иҗат ләззәте дә. Гүзәл табигатьне, яхшы күңелле кешеләрне, көчле һәм тирән хисләрне яратам».


Күптән түгел бөтен нефть төбәгендә мәдәни вакыйгага әйләнгән шәхси күргәзмәсе исеме белән үк җанга ятышлы иде: чөнки ул Илһамга, Хыялга багышланган! Аны «Рәсемнәр ханбикәсе» дип атадылар. «Картиналары әйбәт энергетикага төрелгән», – дип бәяләделәр. Кара, чыннан да шулай бит! Натюрмортларына карыйсың да авторын күрәсе килә башлый. Бу кәбестә, кыярларны, суган, кишер, чөгендерләрне бакчасында ул үзе үстергәндер, әлбәттә, үзедер. Күр инде монысын! Слива, йөзем, кавын, грушалар куелган өстәлне... үзебездә үскән кызыл миләшләр ничек бизи! Сары, кызгылт кипкән чәчәкләре тәрәзәдән яңгыр чирткән көзге кичләрдә, һичшиксез, җылытадыр... Балачактан бик тә таныш кечкенә авыл өйләре, ак карга чумып уйланып утыралар, ак көрткә күмелгән урамнар, моржалардан ак төтен күтәрелә... Ак, рәхәт дөнья! Бәкернең гүзәл табигате, таулары, камышлы күлләре тагын... Матур! Ә портретларындагы хатын-кызлар үзләре гади, үзләре сөйкемле. Әнә «Ирина Никаноровна». Монысы – Лиля. Рәссамның остаханәсенә килгәннәр. Без дә килдек менә. Һәм яратып китәбез...

Эльмира ЗАКИРОВА









Көнбагышлар.

Пионнар.
Лилия – минем остаханәмдә.
Ирина Никаноровна.
Натюрморт.

**ТАМАРА САМОЙЛОВА**

PRESSA.RU

# КОТЛАУЛАР



Әбүбәкер Усман улы АКҖЕГЕТОВ,
«Пенза өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы, «КАТАУ» компанияләр төркеме директорлар советы рәисе

*Хөрмәтле ханымнар һәм туташлар!*
*Халыкара хатын-кызлар көне белән ихластан тәбрик итәм Сезне! Һәрчак шат, көләч, мөлаем булыгыз! Уңышларыгыз, ачышларыгыз, күркәм эшләрегез, изге гамәлләрегез белән сокландырып торыгыз! Әниләр сабырлыгын, хатын-кыз зирәклеген, кызлар сылулыгын саклап, һәр яктан гүзәл булып калыгыз! Без Сезне яратабыз!*



Илдус Ядкарь улы
ДӘҮЛӘТОВ,
ҖЧҖ «Алга» агрохолдингы директоры,
Оренбург законнар чыгару җыены депутаты

*Кадерле һәм сөйкемле хатын-кызларыбыз! Сезне 8 Март – яз тулы, наз тулы бәйрәм белән котлыйм!*
*Җылы хисләребез, изге теләкләребез сезгә соклану һәм ярату булып барып ирешсен! Күз карашларыгызны һәр көн чәчәкләр иркәләсен, матур сүзләр иссендерсен, көтелмәгән сөенечләрдән дөньягыз ямьләнсен!*

«Сөембикә» журналы – бәйрәмгә иң әйбәт бүләк
Язылу индексы: 73002 (РФ регионнарында), П2204 (Татарстан буенча)